

Калын караңгылык эчендә беренче шәм...

Җәмал Вәлиди



Бертуган Бубыйларның әниләре Бәдрелбәнат Иманкол кызы.
1917 ел.



Гобәйдулла Бубый һәм җәмәгате Нәсимә.



Мөхлисә Бубый.
Фото Р. Үтәбай-Кәриминең шәхси архивында саклана.



Габдулла Бубый.
Сарапул. 1912 ел.



Гобәйдулла Бубый, хатыны Нәсимә һәм уллары Фидаи белән Зыяи.
Сарапул. 1912 ел, 29 май.
Фото КДУ Фәнни китапханәсенен Сирәк һәм кульязма китаплар бүлегендә саклана.



Габдулла Бубый, хатыны Хөснефатыйма, кызлары Галия һәм Ситдыйка.
Сарапул. 1912 ел, 29 май.




Габәйдулла Бубый *(соңгы рәттә уңнан беренче)* Бөтенрусия мөселманнарының 2 нче съездында катнашучылар арасында. С.-Петербург. 1906 ел, гыйнвар.



Диния нәзарәте хезмәткәрләре һәм кунаклар. Икенче рәттә сулдан беренче Мөхлисә Бубый, Җиһангир Абызгилдин, Зыяэтдин Камали, Ризаэтдин Фәхретдин, Кәшшафетдин Тәрҗемани, Габдулла Сөләймани.

Уфа, 1926 ел.

Фото ТФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Кульязмалар һәм текстология бүлеге каршындагы Мирасханә фондларында саклана. 81 ф., 1 тасв., 67 эш.



*Утырганнар (сулдан уңга):* Габдрахман Әхмәрев, Гомәр Дәүләтъяров, Һади Максуди, Ниязмөхәммәт Сөләйманов.
*Басканнар:* Йосыф Акчура, Габдулла Бубый, Лотфый Исхакый, Харис Фәйзи.



*Утырганнар (сулдан икенче):* Габдулла Бубый, Тимерша Соловьев, Исмәгыйль Гаспринский, Мидхәт Әхмәрев.
Түбән Новгород. 1906 ел.



*1 нче рәттә (сулдан уңга):* Гобәйдулла Бубыйның уллары Зыяи һәм Фидаи, Габдулла Бубый кызлары Галия һәм Ситдыйка.
*2 нче рәттә (сулдан дүртенче):* Нәсимә Бубый, Хөснефатыйма Бубый, Нажия Бигашева.
*3 нче рәттә (сулдан өченче):* Гобәйдулла Бубый, Габдулла Бубый, Кыйвам Бигашев. Сарапул. 1912 ел, 29 май.



Икенче рәттә сулдан дүртенче Габдулла Бубый.
Троицки. 1918 ел.
Фото Н. Таировның шәхси архивында саклана.



Голжа татар кызлары мәктәбенең беренче чыгарылышыннан бер төркем.
*Утырганнар:* Хөснефатыйма һәм Габдулла Бубыйлар.
*Басканнар (сулдан):* Мөнирә Вахит, Хәдичә Хәсәнова, Маһи Мохтарова,
Мәликә Хәсәнева, Мәмдуха Мохтарова.
Голжа (Кытай), 1917 ел.



Гобәйдулла һәм Нәсимә Бубыйлар.
*Фото артында:* "Сөекле якын карендәшем Харис Фәйзи абзыйга хатирә булсын өчен тәкъдим итәм. Нәсимә Бубый", - дип язылган. 1929 ел, 10 апрель.
Фото КДУ Фәнни китапханәсенең Сирәк һәм кульязма китаплар бүлегендә саклана.



Бертуган Бубыйларның йорты һәм кызлар мәдрәсәсе (дарелмөгаллимат).
Иж-Бубый авылы. 1908-1910 еллар.



Мөхәммәджан хажи йорты.
Иж-Бубый. 1999 ел.



Бертуган Бубыйлар йорты.
Иж-Бубый. 1999 ел.



Бертуган Бубыйлар исемендәге Иж-Бубый мәктәбе.
1999 ел.



Иж-Бубый авылы күренеше.
1999 ел.



1895 елда Мөхәммәджан бай төзеткән мәчет бинасы.
Иж-Бубый. 1999 ел.





Габдулла Бубый һәм әнисе Бәдрелбәнат Иманкол кызына
куелган кабер ташы.
Иж-Бубый авылы зираты. 1999 ел.

РУХИ ЯҢАРЫШ ФОНДЫ
ФОНД ДУХОВНОГО ВОЗРОЖДЕНИЯ
RUHIAT РУХИЯТ
ТАТНЕФТЬ

# Бертуган БУБЫЙЛАР
# һәм
# Иж-Бубый мәдрәсәсе

Тарихи-документаль җыентык

Казан
«Рухият» нәшрияты
1999

УДК 9 (с46)
ББК 63.3 (2 Рос. Тат.)
Б 42

Фәнни мөхәррир
Миркасыйм Госманов
тарих фәннәре докторы,
Татарстан Фәннәр академиясе академигы

Төзүчеләр
Раиф Мәрданов, Рамил Миңнуллин, Сөләйман Рәхимов

Бизәлеш рәссамы
Шамил Насыйров

Б 42. Бертуган Бубыйлар һәм Иж-Бубый мәдрәсәсе:
Тарихи-документаль җыентык.-Казан: Рухият, 1999. - 240 б.

ISBN 589706-012-6

Җыентыкта XX йөз башында төрки-татар һәм мөселман халыкларының иҗтимагый фикер үсеше һәм мәгариф тарихында шөһрәт казанган бертуган Бубыйлар һәм Иж-Бубый мәдрәсәсенә караган документаль чыганаклар һәм материаллар туплап бирелде.

Китап милли тарихыбыз белән кызыксынучы киң катлау укучыларга тәкъдим ителә.

Китапта КДУ Фәнни китапханәсе Сирәк һәм кульязма китаплар бүлегенең Шәрык секторы, Татарстан Милли архивы, Киров өлкәсе дәүләт архивы, Башкортостан Республикасының Куркынычсызлык министрлыгы архивы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты архивы, Иж-Бубый авылы музее, вакытлы матбугат һәм Р.Үтәбай-Кәрими, Н.Таиров шәхси архивларындагы материаллар файдаланылды.

Төсле фотолар - Ш.Насыйров.

ББК 63.3 (2 Рос. Тат.)
УДК 9 (с46)

ISBN 589706-012-6

© «Рухият» нәшрияты, 1999

# Калын караңгылык эчендә беренче шәм...

Татар халкы тарихы күренекле шәхесләргә, әдипләргә һәм галимнәргә гаҗәеп бай. Милли-мәдәни күгебездә Г.Курсавый, Ш.Мәрҗани, Х.Фәезханов, К.Насыйри, Р.Фәхретдин, Ф.Кәримиләр кебек йолдызлар арасында бертуган Габдулла, Гобәйдулла һәм Мөхлисә Бубыйларның да исемнәре балкый. Бубыйларның мәртәбәле эшчәнлекләре Иж-Бубый мәдрәсәсе белән тыгыз бәйләнгән.

Татар уку йортларыннан Казанда "Мөхәммәдия", Оренбургта "Хөсәения", Уфада "Галия", Иж-Бубый мәдрәсәләре XX гасыр башында укыту-тәрбия һәм эчке тәртипләре белән алдынгылыкка ирешеп, бөтен Русиядә дан-шөһрәт казанганнар.

Татар мәдрәсәләренең роле фәндә бүгенге көнгәчә төрле яклап өйрәнелеп, тиешенчә бәяләнеп бетмәгән дисәк тә, ялгыш булмас. Мәдрәсәләр тарихы уку-язуга, гыйлемгә өйрәтү, тәрбия бирү, милли һәм дини хисләр тәрбияләү, авыр елларда да халкыбызның милләт буларак сакланып калуы һ.б. хосусиятләрне үз эченә алган иксез-чиксез дәрья ул.

Татар мәдрәсәләренең хәле матди һәм мәгънәви җәһәттән тулаем җитәкче-хуҗаларының эш-гамәлләреннән аерылгысыз булганга, аларның белем, тырышлык һәм фидакярлекләре никадәр камил булса, мәдрәсә дә шул нисбәттә камил булып, чын гыйлем учагына әверелгән.

Бубый мәдрәсәсенең, бертуган Бубыйларның эшчәнлекләре фәнни хезмәтләрдә беркадәр өйрәнелде, тикшерелде һәм бәяләнде. Әлеге шәхесләрне һәм аларның күркәм хезмәтләрен халыкка танытуда Җ.Вәлиди, А.Рөстәмева, М.Мәһдиев, А.Мәхмүтова, Р.Үтәбай-Кәрими, М.Рәхимкулова, Р.Хәлиуллина,

шулай ук Иж-Бубый авылы җәмәгатьчелеге зур тырышлык куйдылар.

Бу җыентыкка Габдулла Бубыйның "Бубый мәдрәсәсенең кыска тарихы" дип исемләнгән кульязмасының күчермәсе урнаштырылды.

Г. Бубый кульязмасы бүгенге графикага күчерелде һәм, теле, җөмлә төзелешләре сакланган хәлдә, бүгенге укучы өчен аңлаешсыз гарәп, фарсы сүзләре, борынгы татар-төрки грамматик формалары җиңеләйтелеп бирелде. Дәрес атамалары нигездә үзгәрешсез сакланды һәм текст ахырында тәрҗемәләре белән аерым туплап күрсәтелде.

Кульязманың Бубый чорына караган беренче өлеше бернинди кыскартуларсыз күчерелде. Ә икенче өлеше, ягъни Голҗа һәм Троицки чорларын тасвирлаганы өлешчә, сайланма рәвештә тәкъдим ителә. Г. Бубый язмасында даталар һ.б. саннар сүзләр белән язылган, без исә аларны саннар белән генә бирүне мәгъкуль күрдек. Кульязма күчермәсенең ахырында шушы хезмәткә кагылышлы архив һ.б. фактик мәгълүматларга нигезләнгән искәрмәләр һәм аңлатмалар урнаштырылды.

Танылган мәгърифәтче һәм ислам тарихында бердәнбер хатын-кыз казыя Мөхлисә Бубыйның тууына 130 ел тулу уңаеннан нәшер ителгән бу китапка М.Бубыйның 1906-1925 елларда матбугатта басылган кайбер мәкаләләре укучылар игътибарына тәкъдим ителде.

XX йөз башында күренекле җәмәгать эшлеклесе буларак танылган милләтпәрвәр шәхес, Дәүләт Думасы әгъзасы Садретдин Максудиның Думада панисламизм турында сөйләгән чыгышын да бу җыентыкка кертүне кирәкле таптык. Беренчедән, анда Бубый хәлләре турында шактый сүз әйтелә, һәм шуның нәтиҗәсендә Бубый мәдрәсәсе туздырылуын, империядәге мөселманнарга кагылышлы башка сәяси вакыйгалар арасындагы урынын күзалларга мөмкин. Икенчедән, тагын да мөһимрәге, бу чыгышында С. Максуди "панисламизм"ны никадәр мәкерле ялган, кара гаеп буларак Русия мөселманнарына тагылуын фаш итә. Менә шуны аңлап-белеп китү бүгенге көндә замандашларыбыз өчен дә гаять зарур. Чөнки патша хөкүмәтенең "панисламизм" дип аталган мәкерле уйдырмасы яшәүчән булып чыкты. 1930 нчы елларда күпме милләттәшләребез, әдипләребез, галимнәребез шул уйдырмага нигезләнеп, "панисламист", "пантюркист", "милләтче" дип гаепләнеп юк ителделәр. Аннан соңгы фәнни хезмәтләрдә дә бу ярлыклар яшәп килде. Бубый мәдрәсәсе, аның җитәкчеләре турында язганда да шул сәбәпле бик сакланып кына эш иттеләр.

Садрый Максудиның бу чыгышы үз вакытында рус һәм татар матбугатында дөнья күргән. "Вакыт" газетасы бу материалны "Русия мөселманнары арасында панисламизм фикеренең юклыгы хакында Государственная Дума мөнбәреннән сөйләнгән нотык" дип аерым брошюра рәвешендә бастырып, 955 нче санына (1912 ел) кушымта буларак үз укучыларына тараткан. Җыентыктагы нотык тексты исә "Йолдыз" газетасының 809—812 нче саннарыннан алынды.

Иж-Бубый авылы, мәдрәсәсе һәм бертуган Бубыйлар турында тулырак мәгълүмат бирү максатында архив һәм матбугат материаллары туплап урнаштырылды. Заманында бөтен Русия мөселманнарын, аеруча Идел-Урал татарларын тетрәндергән Бубыйларны хөкем итү эшеннән өземтәләр һәм Мөхлисә Бубыйның 1937 елда нахакка гаепләнеп хөкем ителүе һәм атып үтерелүе, 1960 елда акланы турында архив документлары бирелде. Библиография өлешендә Габдулла Бубый кульязмаларының археограф-галим Альберт Фәтхи тарафыннан эшләнгән тәфсилле тасвирламасы, Габдулла һәм Гобәйдулла Бубыйларның басылып чыккан хезмәтләре, Бубыйлар һәм мәдрәсә хакында мәкаләләр исемлеге кертелде.

Җыентыкны хәзерләүдә язма һәм фотоматериаллар белән ярдәм күрсәткән Татарстан Милли архивы, Киров өлкәсе дәүләт архивы, Казан дәүләт университетының Фәнни китапханәсе хезмәткәрләренә һәм Иж-Бубый музее җитәкчесе Рәмзия ханым Хәлиуллинага, Диләрә ханым Абдуллинага, Равил ага Үтәбай-Кәримигә, Наил әфәнде Таировка олуг рәхмәтләребезне белдерәбез.

Китапка нигез итеп 1991 елда аз тираж белән нәшер ителгән "Бубый мәдрәсәсе тарихы" җыентыгы алынды. Үз вакытында ул җыентык Иж-Бубый музее өчен кулланма буларак хәзерләнгән һәм тиражы да чикләнгән иде.

Раиф Мәрданов, Рамил Миңнуллин, Сөләйман Рәхимов.

بسم الله الرحمن الرحيم

أعوذ بالله من الشيطان الرجيم

# Мәгариф тарихыбыз каһарманнары

XX гасыр башында татар әдәбиятының титаны Фатыйх Мөхәммәдзариф улы Әмирхан "Икенче адым" дигән мәкалә язып чыга. Татар халкының тәрәкъкыят юлында беренче адымы дип җәдит мәкәлләрен атап, ул: "Әле берничә ел гына элек татар хатын-кызлары өчен урта мәктәпләр матур, әмма ерак хыял гына иде... шау-шулы җыелышларда гади халык кына түгел, хәтта аксөякләр вәкилләре арасында да татар хатын-кызлары өчен милли мәктәпләр ачуга каршы чыгарга тартынмаганнар иде. Әмма вакыт һәм милләт аңы ул караңгы елларны артта калдырды", – дип язды.

Бу матур, әмма ерак хыялны чынга ашыру өчен, "милләт аңы"ннан тыш, тагын нинди киртәләрне җимерергә кирәк булды соң?

Мәгълүм ки, татарларда халык мәгарифен үстерү мәсьәләсе 1905 нче елгы революция чорында ук кискен куела. Укытучылар әзерләү кирәклеге мәсьәләсе дә шул вакытта ук күтәрелә. Бигрәк тә хатын-кызларны укыту, алар арасыннан укытучы-мөгаллимәләр әзерләү өлкәсендә ул җитди төс ала.

Патша хөкүмәте мөселман хатын-кызларына белем бирү турында кайгыртмаган. Шуңа күрә хатын-кызлар өчен беренче уку йортлары бары тик аерым кешеләр тарафыннан гына ачылган. Русларда мондый уку йортлары XIX гасырның икенче яртысында, татарларда исә хатын-кызлар мәктәпләре илле ел соңрак, ягъни XX гасыр башларында барлыкка килә. Татар хатын-кызлары өчен мәктәпләрнең иң беренчесе – элеккеге Вятка губернасы Иж-Бубый авылында Мөхлисә Бубый тарафыннан ачыла. Дөрес, бу рәсми дәүләт рөхсәте белән ачылган мәктәп булмаганлыктан, Мөхлисә ханымга, максатына ирешү өчен, бик күп каршылыкларны җимерергә туры килә. Ул –

заманында зур гыйлемле, алдынгы карашлы, батыр йөрәкле һәм тәвәккәл татар галимә-хатыннарының берсе булып, аеруча мәшһүр Бубый хатын-кызлар мәдрәсәсенең мөдире һәм мөгаллимәсе буларак, Русиядә яшәүче төрки халыклары арасында дан казанды.

Мөхлисә абыстай 1869 елда Вятка губернасы, Сарапул өязе, Әгерже волостендагы Иж-Бубый авылында хәлле крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Әтисе Габделгаллэм (вафаты 1909 елда), әнисе Бәдрелбанат (1919 елда үлә) Нигъматуллалар, заманасының укый-яза белә торган кешеләрннән булып, татар теленнән тыш гарәп, фарсы вә төрек телләрен яхшы белгәннәр: газиз балалары Мөхлисә, Габдулла, Гобәйдуллаларга дөньяви фәннәрдән һәм төрле телләрдән нигезле гыйлем-мәгълүмат биргәннәр.

Тал чыбыктай зифа Мөхлисәне бик яшьли бер имамга кияүгә бирәләр. Бер баласы булгач (кызы Мөнҗия), иреннән аерылып кайта да, нәкъ менә энеләре укыткан вә җитәкчелек-рәһбәрлек кылган мәдрәсәдә кызлар сыйныфлары ачып, мөдирә булып, төрле фәннәрдән укыта башлый. Сыйныф бүлмәләре укыту-күрсәтмә әсбаплар һәм башка кирәк-яраклар белән әйбәт җиһазланган була. Мөхлисә абыстай мәктәбендә рус теле, татар теле-әдәбияты, арифметика, география, тарих, табигать белеме, рәсем, матур язу һәм ислам дине сабагы укытыла. Үз вакытында алдынгы уку йорты исәпләнгән бу мәдрәсәдә Себердән, Зайсаннан, Ташкенттан, Пржевальскидан, Пишпәктән (Бишкәк) һәм башка ерак җирләрдән килеп укучы хатын-кызлар күп булган. Татар мәгариф тарихында эз калдырган РСФСР мәктәпләренең атказанган укытучысы Сара ханым Габбасия, Казан шәһәреннән Мәрьям ханым Зәйнетдин, Зәйнәб Максудия, мәшһүр мәгърифәтче, татар басма язуы өчен күп хезмәтләр күрсәткән, дәреслекләр язып калдырган Мөхәммәд әфәнде Идрисинең кызы — бүгенге көндә Мәскәүдә яшәүче Рабига ханым Идриси һәм башкалар Мөхлисә абыстайдан тәгълим-тәрбия, гыйлем эстәгәннәр.

Оренбург шәһәрендә татар халкының мәдәнияте-тарихы өлкәсендә күзәтүләр, тикшеренү-эзләнүләр алып баручы мөхтәрәмә Мәдинә ханым Рәхимколия язмаларының берсендә: "Аналы-кызлы Маһруй бинте Ибраһим вә Фатыйма бинте Гомәр, ирләреннән рөхсәт алып, һәркайсы икешәр-өчәр баласы белән Башкортстанның Слак (хәзерге Әлшәй районы) һәм Олы Кәркәле (хәзерге Миякә районы) авылларыннан 1909-1911 нче елларда Бубый мәдрәсәсенә укырга киләләр. Күкрәк балаларын карар өчен өлкәнрәк кызларын үзләре белән алып барганнар. Баерак укучы кызларга калфак энҗеләр, камзул чигеп, тереклек

өчен азмы-күпме акча юнәтеп, Мөхлисә ханым мәдрәсәсендә төпле белем алганнар," — дип яза. Хак, бу фикер белән килешмәскә һич мөмкин түгел.

1910-1911 нче елларда патша хакимиятләре татар җәдит мәктәп-мәдрәсәләрен аяусыз рәвештә яптыралар. 1912 елның 21 январендә Бубый мәдрәсәсе дә тар-мар ителеп, күп китап вә кулъязмаларны җыеп, урамда яндырып, мөгаллим-мөгаллимәләрне кайсысын кулга алып, кайсысын сөргенгә җибәреп, укучыларны тараталар. Ләкин хакимият искелеккә каршы чыгуларны, исламга реформа ясауны яклауларны туктата алмый. Галимҗан Баруди, Габдулла Бубый кебек яңача уку-укыту ысулларын яклаучыларның Ишми ишан һәм аның иярченнәренә каршы көрәшүе генә дә моңа мисал. Мәдрәсәсе туздырылып, сөргенгә җибәрелгән Габдулла Бубыйның 1914 елда язган бер хатында шундый юллар бар: "Бу сугышлар соңында Русиядә зур бер хөррият була калса, — мөгаен, булачак, — безгә укытырга мәктәпләр ачарга ирек бирелсә, әлбәттә, биреләчәк, — Бубый мәктәпләрен ачарга имкян табылса, — шөбһә юк, табылачак, — ул вакытта мин монда бер көн дә тормамын, кайтырмын, Бубыйдагы ирләр мәктәбен түгел, кызлар мәктәбен ачармын, шунда русчаны да мөкәммәл кертеп, кызларны һәм мөгаллимә, һәм учительница итеп чыгарырга иҗтиһад кылырмын".

Шушы фаҗигале хәлләрдән соң, 1911 елда ук, Мөхлисә ханым Троицкий шәһәрендә (хәзерге Чиләбе өлкәсендә) Габделвәли (мәшһүр Ф. Аит, атаклы скрипач Мөхәммәд Яушның әтисе) Яушварисларында хезмәт итүче Габдрахман Әхмәр ачкан кызлар урта мәктәбендә укыта башлый. Төрле фәннәрдән сабак-дәрес бирә. Соңыннан бу мәктәп Яушевлар исеменә күчә. Мөгаллимә-галимә Мөхлисә Бубыйның шөһрәте бөтен киң Русиягә тарала.

1917 елның маенда, Мәскәү каласында, Бөтенрусия мөселманнарының корылтаенда Мөхлисә ханымны Уфа шәһәрендә җирләшкән мөселманнарның Үзәк Диния нәзарәтенә казыя итеп сайлыйлар.

Ул Уфада башта Аксаков урамында абыйсы Гобәйдулла Бубыйның өендә, түбәнге катта яши. (Бу йорт берничә ел элек кенә сүтелде). Олуг галимебез Ризаэтдин бине Фәхретдин җитәкчелегендә (әйтергә кирәк, ул Мөхлисә ханымга гомере буе бөек хөрмәт тойгысы саклаган), хатын-кызлар арасында, зур оештыру, аңлату эшләре алып барып, җаны-тәне белән халыкка тәрбия бирү диңгезенә чума, ул вакытта (1924-1927 елларда) Уфада нәшер ителгән "Ислам мәҗәлләсе" битләрендә мәкаләләрен бастыра, тәгълим-тәрбия өлкәсендә Фәхрелбанат

Сөләймания (казый Габдулла Сөләйманинең әнисе), Гайшә абыстай (Җиһангир Абызгилдинның хатыны), Багбостан ханым, Ләбибә Хөсәен, Фатыйма Аитларның уңай тәҗрибәләрен дәвам иттерә. Мөхлисә абыстайның исем-шәрифе — Русия мөселманнары арасыннан шытып-калкып чыккан дөньяда беренче һәм иң соңгы бердәнбер казыя-хатын буларак аеручы дикъкатькә лаек. Шәхес шөһрәте чорында, 1937 елда, нигезсез гаепләнеп, кулга алына, төрмәдә гомере өзелә. Хәзер акланган.

Үз кызы Мөнҗия белән бер яшьлек ятимә кызны (Нажияне), күз карасыдай асрап үстерә, икесенә дә югары белем-мәгълүмат алырга ярдәм итә. Бик яшьли, фаҗигале рәвештә вафат булган Мөнҗия Троицкий шәһәрендә укытучылык эше белән шөгыльләнә. Нажия исә соңгы елларын Ташкентта яшәп, шунда вафат булды.

Шулай итеп, Русиядә мөселман хатын-кызлары өчен беренче уку йортларын нигезләгән, шуларда нәтиҗәле хезмәт иткән, татар һәм башка төрки халыкларның милли мәдәнияте өчен авыр көрәш елларын кичергән Мөхлисә ханым Бубыйның исеме һич кенә дә онытылырга, тарих тузаннары эчендә күмелеп калырга тиеш түгел.

Әйе, татар халкының мәгарифен үстерүгә зур өлеш керткән галим-педагоглар аз түгел. Агалы-энеле Бубыйлар әнә шундыйлар. Кыскача гына бу асыл затлар тормышын, эшчәнлеген күздән кичерик.

Гобәйдулла Бубый-Фәйзи (1866—1938) урта белемне Иж-Бубыйда ала. Париж университетының табигать белеме факультетын уңышлы бетереп, мәшһүр галим Паскальнең дөньяга таклы лабораториясендә практика уза.* Төскә-буйга чибәр, күркәм холыклы һәм сәләтле татар егетен Парижда калырга димлиләр. Әмма ул: "Мине газиз Ватаным, сөекле халкым көтә, мин туган илемдә хезмәт итәргә тиеш", — ди.

Иж-Бубыйда, мәдрәсәдә укытучы булып эшли ул, күп дәреслекләр яза. Мәсәлән, аның ике кисәктән гыйбарәт "Кыйраәте фәнния" (физика) китабы 1909 елдан 1917 елга кадәр күп мәртәбәләр басылган һәм мәктәпләрдә Октябрь революциясеннән соң да киң кулланылышта булган. 1898 —1915 нче елларда Гобәйдулла Бубыйның география дәреслекләре ("Мохтасар җәгъръфия", "Җәгъръфия гомумия") дөнья күрә. Дәреслекләрендә шәкертләргә ул атамаларның ике төрле вариантын тәкъдим иткән: Мисыр-Египет, Фәс-Марокко, Шам-Дамаск, Гыйрак-Месопотамия, Алман-Германия, Идел-Волга

* Бу фактны раслый торган документлар табылмады (төз. иск.)

һ.б. Әйтергә кирәк, Гобәйдулла татар, рус, төрек, гарәп, фарсы, француз, үзбәк телләрен су кебек эчкән.

1912 елда Иж-Бубый мәдрәсәсе ябылгач, киң илебезнең төрле мәктәпләрендә физика һәм география укыта, берничә ел Уфада гомер кичерә. 1924-1926 елларда Казан шәһәреннән якын гына урында урнашкан авыл хуҗалыгы техникумында директор булып эшли (шушы елларда мәкалә авторларыннан Р. Үтәбәй-Кәриминең әтисе Гобәйдулла Бубыйдан сабак ала, аның якты хатирәсен ул гомере буе изге ядкарь итеп күңелендә саклады). 1927-1930 елларда исә Үзбәкстанның Коканд шәһәрендә мәктәп директоры сыйфатында хезмәт итә. Соңгы елларын Ленинградта яши. Хатыны озак еллар Иж-Бубый мәдрәсәсендә һәм башка мәктәпләрдә татар теле-әдәбияты дәресләрен алып бара. Нәсимә апа Бөек Ватан сугышыннан соң Ленинград каласында вафат була. Уллары — Фидаи (1906—1932) Ленинград политехник институтында укый. 1924-1925 елларда Берлин шәһәрендә белемен камилләштерә. Бик яшьли, хәтта өйләнмәстән, 1932 елда Коканд шәһәрендә үлә. Зыяи (1908-1941) — төсле металлар буенча инженер, Ленинград политехник институтын тәмамлый. Бөек Ватан сугышының тәүге көннәрендә үк, Балтик буе фронтында, батырларча һәлак була.

Габдулла Бубый (1871—1922) — Бәйрут университетының фәлсәфә факультетын тәмамлаган,* татар, рус, гарәп, төрек, фарсы, француз һәм уйгыр телләрен мөкәммәл белгән. Иж-Бубыйга кайту белән ирләр һәм кызлар мәдрәсәләренә нигез салган, аларда алдынгы ысуллар кертүгә ирешкән, рус теле-әдәбияты өйрәнүне булдырган. Шәкертләр Уфа, Пермь, Казан вә башка геберналардан агылганнар мәдрәсәгә. Кышларын ирләр мәдрәсәсендә 200 гә якын шәкерт булса, кызлар мәдрәсәсендә исә бу сан 300 гә барып җиткән. Укучылар түләүсез торак белән тәэмин ителеп, ярлы шәкертләр уку өчен түләүдән дә азат ителгәннәр. 1907 елда, мәсәлән, кызлар мәктәп-мәдрәсәсендә барысы 7 класс булып, 3 — рус-татар, 4 русча эш итә торган сыйныфлар булган.

Мәдрәсә бөтен төрки-мөселман дөньясында зур абруй казанган. 1905 елгы беренче рус революциясе чорында, мәсәлән, башка урыннардагы мәдрәсәләрнең бик күп шәкертләренең бирегә күчеп килүләре югарыдагы фикернең ачык дәлиле булса кирәк. Анда укыган шәкертләрнең күбесе соңыннан мәшһүр мәгърифәтче-педагоглар, күренекле дәүләт һәм партия эшлеклеләре, 1917 елда революция солдатлары, гражданнар сугышы батырлары булып җитештеләр. Алар Габдулла Бубыйның соңгы

---

* Бу фактны раслаучы документлар табылмады. (төз. иск.)

көннәренә кадәр аңа тирән ихтирам сакладылар, аның белән хат алышу яисә күрешеп киңәшләр алуны үзләренең изге бурычлары санадылар.

1912 ел башында мәдрәсә рәхимсез туздырылып ябылгач, мәктәп җитәкчеләре, шул исәптән мөхтәрәм Габдулла әфәнде дә кулга алынып, Сарапул өязе төрмәсенә ябыла. 1913 елда төрмәдән азат ителгәч, Габдулла Бубый һәм аның хатыны Хөснифатыйма (1884—1941) Шәркый Төркестанның Голҗа шәһәренә сөреләләр.* Алар монда да ирләр һәм кыз балалар өчен мәдрәсәләр ачалар. Кичләрен уйгыр, казакъ, кыргыз, үзбәк халкы арасында наданлыкка каршы чын мәгънәсендә көрәш җәелдерәләр, аларның аң-белемгә күзләрен ачарга ярдәм итәләр. Күчереш һәм чыгарылыш имтиханнарын бөтен халык катнашында үткәреп, соңыннан үзләре тәэсирле чыгышлар ясыйлар. Хөснифатыйма ханымның кызлар мәдрәсәсе имтиханыннан соң ясаган чыгышларының берсе (әйтеп үтик, ул ялкынлы оратор булган), мәсәлән, ул вакыттагы Якуб Хәлили мөхәррирлеге вә наширлегендә чыгып килгән "Сөембикә" мәҗәлләсенең 1914 елгы 1 август санында да дөнья күргән.

1917 елгы февраль революциясеннән соң Бубыйлар Русиягә кайту бәхетенә ирешәләр. Халык Голҗадан аларны хөрмәтләп, зурлап озатып кала. Шәһәр капкасын чыккан урында озату шәрәфенә зур җыелыш оештырылып, биредә ирләр һәм кызлар мәктәпләренең шәкертләре, мөгаллим-хәлфәләре катнаша, күз яшьләре белән Габдулла һәм Хөснифатыйма Бубыйларның хезмәтләренә зур бәһа бирелә. Гаиләне чик буена кадәр махсус рәвештә атлы гаскәрләр озатып килә. Кыска гына вакытка алар Ташкентка тукталалар. Алдынгы фикерле татар һәм үзбәк зыялылары аларны биредә калырга, ике кан-кардәш халык бәхете өчен хезмәт итәргә өндиләр. Әмма ләкин табиблар, табигый шартларның килешмәве сәбәпле, Габдулла Бубыйга (тамак авыруы) Русия тарафларына кайтырга мәслихәт бирәләр. Шул нигездә алар яңадан Уралда — Троицкий шәһәренә килеп төпләнәләр, чөнки анда бу вакытта Мөхлисә абыстай кызлар мәдрәсәсенең мөдирәсе булып хезмәт итә. Ул исә үз вазифасын, бер дә күңелен таратмастан, укымышлы газиз абыйсына тапшыра. Габдулла бер ел мәдрәсәнең мөдире сыйфатында эшли, язучылык, фәнни эш белән шөгыльләнә: төрле телләр өйрәнү-укыту буенча методик кулланмалар төзи, русның атаклы сатира остасы М.Е. Салтыков-Щедрин әсәрләрен тәрҗемә итә, үзе дә сатира жанрында хикәяләр яза.

---

* Хакыйкатьтә чарасызлыктан китәргә мәҗбүр булганнар (төз. иск.)

Габдулла Бубый 51 яшендә дөнья куя. Билгеле ки, бу ихлас һәм туктаусыз хезмәт, патша хакимиятләренең өзлексез эзәрлекләүләренең аның сәламәтлегенә тискәре йогынты ясау нәтиҗәсе иде. Шул да мәгълүм булсын, заманасында Казан шәһәренең Черек күл төбәгендә Габдулла Бубый исемен йөрткән урам булып, Сталинның шәхес культы елларында ул башка исемгә алмаштырылды.

Хөснифатыйма Гыйззәтулла кызы Октябрь инкыйлабыннан соң да, 1929 елга кадәр Иж-Бубый мәктәбендә башлангыч сыйныфлырда укытты. Бөтенсоюз Үзәк Башкарма комитеты һәм РСФСР Халык комиссарлары Советы карары нигезендә ул гомер юлдашы Габдулла Бубыйның хезмәтләре өчен, вафатына кадәр (Казан шәһәрендә), персональ дәүләт пенсиясе белән тәэмин ителде.

Хуш, инде бу асыл затның балалары тәрҗемәи хәлләренә күз атыйк.

Галия Габдулла кызы — 1902 елда туган, Казанда медицина институтын тәмамлаган. 1924-25 елларда, ике ел дәвамында, Берлин шәһәрендә, 50 татар шәкерте арасында, белемен камилләштергән. Ул - медицина фәннәре кандидаты буларак, Мәскәүдә медицина институтында һәм клиникада эшләде. 1978 елда Мәскәүдә вафат булды. Аның кызы Газия Зариф кызы Акчурина (1928 елда туган) — медицина фәннәре кандидаты, атаклы окулист, Мәскәүдә гомер сөрмәктә.

Ситдика Габдулла кызы — 1909 елда туган, 1931 елда Казан университетын, шунда ук 1934 елда аспирантура тәмамлаган. Үсемлекләрне саклауның экологик факторлары темасына диссертация яклаганнан соң (1936) Ленинградта яши. Бөек Ватан сугышы елларында Татарстанның Кайбыч районында колхозларда агроном булып хезмәт итә — тыйнаклыгы, гадилеге, киңәш-табыш бирүгә осталыгы аркасында дәһшәтле елларда халык арасында зур абруй казана. Өлкән буын кешеләре аны хәзер дә хөрмәтләп телгә алалар, хәер, ул үзе дә гомеренең авырлыкларын халкы арасында үткәреп бу елларын сагынып яши. Сугыштан соң ул яңадан Ленинградта, Бөтенсоюз үсемлекләрне саклау системасында өлкән фәнни хезмәткәр булып 35 ел хезмәт итте, 30 дан артык фәнни хезмәт язды. Аның кызы — Нелли Реновна Вассер, 1938 елгы, медицина фәннәре кандидаты, микробиолог, 35 тән артык басма фәнни хезмәте бар; улы - Генрих Ренович Вассер — 1939 елда туган, инженер-конструктор, Ленинград шәһәрендә яшиләр.

Фаикъ Габдулла улы — 1918 елда туган, инженер-авиатор. Бөек Ватан сугышында катнаша, инженер-полковник дәрәҗәсенә ирешә, Габдулла Бубый гаиләсендә иң сәләтле,

атасы шикелле искиткеч эшлекле һәм үз сүзендә нык торучы адәм иде. Сугыштан соң, озак еллар, Польшада хезмәт итә. Соңыннан Минскига күчә, шунда 66 яшьтә, 1984 елда дөнья куя. Улы Әнвәр Минскида яши.

Әйе, Нигъмәтуллин — Бубыйларның халкыбыз тарихында хезмәтләре ифрат зур. Алар һәрвакыт үз Ватанының һәм халкының тугрылыклы уллары һәм кызлары, халкыбызның мөкатдәс мәгарифе, фәне, рухи мәдәниятен гәүдәләндерүче шәхесләр булдылар. Алар мисалында килер буыннар бер нәрсәне сабак итеп алырга тиеш — беркайда да, беркайчан да, — авыр, гадәттән кыен, әмма ләззәтле хезмәттән гайре даншөһрәт тә, гомумән, бернәрсә дә бирелмәгән, бирелми һәм бирелмәячәк.

Мәкаләбезне тәмамлап шуны әйтәсе килә: яшьләребез тарихыбызны әтрафлы рәвештә өйрәнсеннәр, нигезле белсеннәр иде. Без, инде өлкән буын вәкилләре, яшь буынның милли тарихыбызга, үтмешебезгә битарафлыгын да, җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнүгә тырышлык күрсәтмәүләрен дә күреп, сизеп, адым саен тоеп, әйтергә кирәк, тирән борчылып гомер кичерәбез.

Равил Үтәбай-Кәрими,
СССР Фәннәр Академиясенең
Шәрыкне өйрәнүчеләрнең
Бөтенсоюз ассоциациясе әгъзасы,

Мәдинә Рәхимкулова,
СССР География җәмгыятенең әгъзасы.
"Кызыл таң". 1990. - 5, 6 июнь.

Габдулла Бубый

# Бубый мәдрәсәсенең кыска тарихы*

Бубый мәдрәсәсе Русия мөселманнарының инкыйлаб вакытында, ягъни аларның искелектән яңалыкка әйләнү гомерендә, мөселманнар арасында бик мөһим бер урын тотканлыктан, бу көн бөтен Русия мөселманнары арасында шөһрәте бик зур булса да, аның бина кылынган җире Вятка губернасы, Сарапул өязе вә шул Сарапулдан илле чакрым шәрыктә, бик кече, бары бер мәхәлләле Бубый авылыдыр. Бу авыл Кама суының көнбатышында Бубый исемле бер сунның ике тарафында утырмыш, вә шул сунның исеме белән Бубый дип аталмыштыр. Бу су, өстенә хөкүмәт тарафыннан "Ижевский завод"[1] исемендә зур бер мылтык һәм шрапнель фабрикасы салыну сәбәпле шөһрәт тапкан Иж суына, вә бу Иж үзе Кама суына коядыр. Бубый авылы Ижевский заводның кырык биш чакрым көньягында. Бүген ир, хатын һәм балалардан гыйбарәт Бубыйның бар халкы 1200 җан чамасында хисапланмактадыр.

Бубыйның төп халкы чирмеш ыругыннан булып, алар, күчеп килгән мөселманнар күбәя башлагачтын, тирә-яккә таралмышлар вә дүрт-биш өйле калганнары 1905 елгы дин хөрриятеннән соң мөселман булмышлардыр.

Бубыйга мөселманнардан иң элек күчеп килгән адәмнәр, Казан губернасы Кара Дуган авылыннан, Сөләйман вә Габдулла исемендә ике кеше булмыштыр. Боларның туган вә үлгән вакытлары һәм Бубыйга тәгаен генә кайчан килүләре мәгълүм булмаса да, Бубыйга килеп утырулары якынча 1730 нчы елларда булырга кирәк. Бу елларда, Бубыйда мәктәп вә мәдрәсә бар-

---

* Кулъязма КДУ Фәнни китапханәсе Сирәк һәм кулъязма китаплар бүлегендә 207т.(э.№2653) шифры белән саклана.

лыгы бер дә мәгълүм түгел. Алай да шул тарихтан күпме-азмы соң, мәгълүм түгел, Бубыйда бик бәләкәй вә манарасыз бер мәсҗиднең барлыгын сөйләгән кешеләр бар.

Менә монысы Бубыйның беренче мәсҗиде. Икенче мәсҗиде шул мәсҗидне сүтеп, аның урынына Бубый байларыннан Мөхәммәдсадыйк Гайса углы белән Габдулла Әхмәди углы тарафыннан бина кылынмыш иде. Бу мәсҗид яхшы гына зур, манаралы, вә тышыннан такта белән каплатылмыш иде. Ләкин соңрак Бубый халкы күбәеп, җомгаларда, гаетләрдә сыймай башлагачтын, шул ук Бубый байларыннан Мөхәммәджан Әхмәджан углы[2] сигез мең сум чыгым тотып, кырык ике аршин буе, уналты аршин иңе бик зур вә бик килешле, менә хәзерге өченче мәсҗидне салды вә Мөхәммәдсадыйк Гайса углының хәтере өчен иске мәсҗиднең юан нарат бүрәнәләреннән яңа мәсҗиднең идән вә түшәмнәрен ярдырды. Бу мәсҗид 1895 елда салынды вә 1900 елда тышыннан такта белән каплатылды. Бу мәсҗиднең бинасы бик яхшы, тәрәзәләре бик зур, түшәмнәре бик биек вә бар идәннәренә яшел постау җәелмештер. Бу мәсҗиднең һәрбер чыгымы бүгендә дә шул Мөхәммәджан Әхмәджан углы кесәсеннән тотылмакта, вә һәрбер җире иң камил суләттә каралмактадыр.

Менә Бубый белән андагы мәсҗидләрнең кыскача гына тарихы шушыннан гыйбарәттер. Минем бу урында максатым, Бубый мәдрәсәсенең тарихын сөйләү булганлыктан, мин бу язуымда Бубыйның башка эшләренә тәфсиллек бирмичә, өстән-өстән генә узуны мәслихәт күрдем, вә бу кадәресен дә, безнең мәктәп вә мәдрәсәләр белән мәсҗидләремез берсенә-берсе бик нык бәйләнеп йөргәнлектән, Бубый мәдрәсәсенең әхвален белергә бер юл булсын диеп кенә яздым. Ләкин безнең татар мәктәп вә мәдрәсәләренең имамнарга бигрәк зур бәйләнешләре бар. Хәтта имамнар үз мәхәлләләрендәге мәктәп вә мәдрәсәләрнең рухлары, вә ислах белән ислах юклыкның зур бер үлчәүләредер. Шуңар күрә һәрбер мәдрәсәнең хәлен яхшы белү шул мәдрәсә янындагы имамның хәлен яхшы белүдән башка мөмкин түгел. Шуның өчен мин, бу урында Бубый мәдрәсәсенең тарихы яхшы беленсен диеп, Бубый имамнары хакында да бераз мәгълүмат биреп китүемне зарур күрдем. Инде мин Бубыйның беренче имамыннан керешәм, вә шул вакыттагы мәктәп вә мәдрәсәләрне дә бергә сөйләп барам чөнки безнең татарларда бит, мәдрәсә-имам, имам һәм мәдрәсә, болар арасында ул кадәр күп аерма түгел, аз гына бер аерма да юк.

Бубыйның беренче имамы Юлдаш бине Бигем бине Дәүләткилдедер. Бубыйда вафат, ләкин кайчан туганы, кайчан

үлгәне һәм мәктәбенең барлыгы-юклыгы, укытуы-укытмавы, берсе дә мәгълүм түгел. Фәкать 1143/1730 елда үз кулы белән язган "Шәйхе Мансур", "Мәдхе Мәүла Җәлалетдин" исемле ике китабы күренә. Язуы кагыйдә белән булмаса да, яхшы. Ләкин бу китапларны кайда вә кайсы хәзрәт мәдрәсәсендә язганлыгы мәгълүм түгел.

Бубыйда икенче имам Хәлиулла бине Госмандыр. Кайдан килгәне, кайда вә кайчан туып, кайчан вафат булганы, мәктәбенең барлыгы-юклыгы, укытуы-укытмавы — берсе дә мәгълүм түгел. Ләкин Габделкәрим исемле углын мөдәррис булу кадәрле укытуыннан, гыйлемгә, укытуга дәрте барлыгы аңлашыла. Шушы Габделкәрим белән Ишбулды исемле угыллaverыннан аның бүген дә нәселләре бар.

Бубыйның өченче имамы, шушы Хәлиулла хәзрәт углы Габделкәрим хәзрәттер. Кайчан тууы, кайда укуы мәгълүм булмаса да, Бубыйда мөдәррис булып дәрес әйтүе, шәкерте күп булып, күп муллалар чыгуы вә бик картаеп, 1240/1825 нче елларда, вафат булуы — болары мәгълүм. Бәс, әгәр Габделкәрим хәзрәт утызларда имам булып, җитмешләрдә вафат булса, Бубыйда имамнар чыга торган мәдрәсәнең, ягъни заманына иң мөһим саналган бер дини мәдрәсәнең (без белгәнчә) иң элек салынуы 1200/1785 елның ахырына туры киләдер. Димәк ки, безне төрмәгә ябып, Бубый мәктәбенең ябылуына, ягъни 1329/1911 елга кадәр, бу мәктәп 130 еллар чамасы дәвам иткән вә Бубыйның аз-аз алга атлавы да шул заманнан башланган буладыр.

Бубыйда дүртенче имам, безнең атабызның атасы Нигъмәтулла Монасыйб углыдыр[3]. Тумышы Казан губернасы Бәрәскә авылында[4]. Кайчан туганлыгы мәгълүм түгел. Вафаты 1845 нче еллар тирәсендә булып, Бубыйда җирләнгән. Иң элек Бәрәскәдә мулла Ибраһим Бикчәнтәй углыннан[5] һәм шул мулла Ибраһимның углы мулла Габдеррәхимнән укып, аннан соң Мәчкәрәнең[6] дамелла Габдулла бине Яхъя[7] хозурында белем алган.

Ошбу безнең бабабыз Нигъмәтулла, үз гасырында Мәчкәрәдә гыйлем вә зиһенлелек белән, ягъни мантыйк, кәлям вә ысулдан фикер йөртү, бәхәстә осталык белән шөһрәт тапкан дүрт шәкертнең берседер. Үз кулы белән язган "Тәүзих", "Гакаид", "Мулла Җәлал", "Ахунд Йосыф" вә "Мулла Касыйм" читләрендә үзенең фикерләре вә кайбер гарәпчә язмалары бар.

Ошбу Нигъмәтулла бабай, Мәчкәрәдә шәкерт вакытында, ни мөнәсәбәт беләндер, Бубыйга кунакка килгән вакытында, шул заман Бубыйда хатыйб вә мөдәррис булган Габделкәрим хәзрәт, аның гыйлем вә зирәклеген яратып, Бубыйга үз янына



Габдулла Бубыйның кулъязмасы.

имамлыкка сайлаткан, Газизә[8] исемле кызын биргән һәм мәдрәсәсен дә аның кулына тапшырган.

Нигъмәтулла бабайны белгән кешеләр, бик шаян сүзле, ләкин бик намуслы, вә һичкемнең хәтеренә караучан түгел иде, дип сөйләйләр. Бервакыт ул мәдрәсәдә чагында, Мәҗкәрә дамелланы чәйгә чакырган. Чәй янына куелган бик симез ат итен, дамелланың "бу ни ите?" дип соравына, "чучка ите бу, дамелла" диеп җавап биргән. Дамелла аңар каршы, "Шаярма, ахмак нәрсә! Күп шаярасың!"нан башканы әйтмәгән. Менә бу вакыйга да, аның дамелла белән дә һәрвакыт шаяруын күрсәтәдер һәм Бубыйда имам булгач, ул вакыт Бубыйның иң беренче байларыннан вә икенче мәсҗиднең байларыннан Мөхәммәдсадыйк Гайса углы белән Габдулла Әхмәди углының, комиссар[9] белән бергә исерткеч эчеп утырган җирләренә шәкертләре белән барып кереп, өстәл өстендәге шешә вә стаканнарны көл итүе, аның һичкем, хәтта байлар хәтеренә дә карамавын, бик ачык күз алдына куя торган бер вакыйгадыр. Менә бу ике бай, Нигъмәтулла бабайга мәхәббәт вә ихласлары шул дәрәҗәдә булган, алар аның тарафыннан бу кадәр эшләр күрсәләр дә, комиссар хөкемгә бирәм дип бик чабаланса да, алар бу эшне хөкемгә бирдермәгәннәр, ялынып-ялварып булса да комиссарны ваз кичтергәннәр.

Менә шушы Нигъмәтулла бабай Бубыйга имам булгач, Габделкәрим хәзрәт урынында укыта башлаган һәм мәдрәсәсенә күп муллалар җыелып, шәкертләр җыелып байтак муллалар чыккалаган.

Нигъмәтулла бабайның өч углы, берничә кызы үссәләр дә, күбесеннән балалары булмыйча, ялгыз безнең атабыз Габделгаллән[10] белән тутасы (Алабуга өязе Сокман авылында[11] Шаһмөхәммәд Габид углына бирелгән иде) Зәйнәбтән нәселләре таралган.

Угылларының берсе вә иң зурысы Гобәйдулладыр. Атасы мәдрәсәсендә укып, гадәттән тыш зирәк булганга, бик яшь көенчә бик күп нәрсәләр белсә дә, имамлыкны ихтыяр итмичә, "имам булып ике тиен садака көтеп торыр хәлем юк, үзем баеп үзем бирсәм иде" дип сәүдә юлына кергән һәм сату белән Төркестан вә Бохара тарафларына китеп бер кайтуында бик сәламәт вә бик күп файдалар белән кайтса да, атасы вафаты соңында, икенче кайтуында Гәйнә илендә[12] башкортлар тарафыннан, муенына бау салып, чана артыннан сөйрәтеп, бик вәхши бер сурәттә шәһид кылынган.

Угылларының тагын берсе вә иң кечесе Габдулладыр. Атасының вафаты вакытында ялгыз җиде-сигез яшьләрендә булып, язу таныр кадәреннән артык табигый укый алмаган, вә атала-

рыннан соң тормышлары бик тараеп китkəнгə, абзасы Габделгалләм (безнең атабыз) барган җиргə укырга да бара алмаган, бəлки ихтыярсыз, иң элек өяз сатучыларына ат башына малайлыкка кергəн, аннан соң вак мал белəн үзе сату итəргə тотынган, вə шуннан тапкан файдасы белəн өйлəрен дə караган һəм абзасы Габделгаллəмнең укуына да ярдəм иткəн, вə шул көенчə үзе һаман русча вə татарча өйрəнергə, укырга тырышкан, вə гадəттəн тыш зирəк булуы сəбəпле, русча уку-язуда осталыкка ия булган. Сатуга йөргəн вакытында поплардан русча газеталар алып чыгып, иптəшлəренə һəм фатир хуҗасы русларга укып-сөйлəп йөрүен, шул вакыт аның белəн бергə сату иткəн кешелəр һəммəсе сөйлəп яталар.

Менə бу Габдулла абзыйның сатуга йөрүе 1855нче еллар тирəсендə булып, ул вакыт татарча газеталарның эзе дə юк, татарлар арасында газетаның исеме дə ишетелмəс, ул вакыт татарлардан түгел, руслардан да газета укучы, хəтта юньлəп язу танучы да күренмəс иде. Менə шундый бер вакытта бер авыл татарының, үзе мулла баласы да булсын, русча газеталарны укып аңлавы, вə шуңа һəвəслəнеп, поплардан алып булса да укырга тырышуы мəгълүм, игътибарыбызны җəлеп итəчəк бер вакыйгадыр. Ихтимал, шул газеталар уку əсəредер, шушы Габдулла абзый егерме яшьлəрендə, сатуларын ташлап яңадан мəдрəсəгə кереп укырга тотынган, ул заман безнең татар дамеллаларында кая күренү, хəтта исеме дə ишетелмəгəн география укытырга да тырышкан һəм Эстəрлебашта[13] булгач, гарəпчə сарыф вə нəхүлəрне, фарсыча укытуны куеп, татарча укытып, гарəпчə белем бирүне реформалаштыру юлында да зур бер адым атламыштыр. Габдулла абзыйның гарəпчə сарыф вə нəхүне татар телендə язган китабы, менə хəзер дə минем алдымда ята. Дөрес, бу китапның тəртибе бүген язылган китаплар кебек үк түгел. Лəкин кайсы эшнең башта ук тəртипле булганы бар? Татар муллалары географияне хəрам диюлəре, татарча хат язуны бик зур бер гаеп санаулары, вə гарəпчə сарыф-нəхүне фарсыча уку һəм укытуны фарыз күрүлəре өстен бер заманда, сарыф белəн нəхүне татарча язып укытуны, бик бəлəкəй бер батырлык вə əһəмиятсез бер нəрсə диеп əйтергə инсанлы бер адəм һичбер вакытта риза булмас.

Габдулла абзый, безнең атабыз Габделгаллəм укып Бубыйга имам булып мəктəп ачып укыта башлагач, иң элек шул мəктəптə өч ел укыган, вə туктаусыз тырышлыгы вə гадəттəн тыш зирəклеге аркасында шушы аз вакыт эчендə голуме гарəбиядəн, мантыйк, кəлям, ысуле фикъһ, тəфсир вə хəдистəн бик күп мəгълүмат алган, аннан соң Казан Габделкəрим хəзрəт[14] мəдрəсəсендə берəр ел торып, шуннан Хиҗазга[15]

юнәлгән. Габделкәрим хәзрәтнең, шул бер ел эчендә дә Габдулла абзыйга ихласы вә мәхәббәте бик зур утырган булырга кирәк ки, хәтта угылларын да сабак өйрәтергә аның кулына биргән һәм иске хәлфәләрнең көнләшүләре сәбәпле, ахырында бу мәктәптән тиз чыгып китәргә мәҗбүр булган. Бу мәдрәсәдән чыгып киткән вакытта аның бер дә акчасы булмаганга, вак-төяк сатулар итештереп, Кырымга, аннан Истанбулга вә беркавым Анатуль[16] авылларында йөргәч, Каһирәгә, ниһаять хаҗга барып, җиде ел тәмам булганда Эстәрлебаш авылына кайткан.

Ул вакыт Эстәрлебаш имамнары Тукаев Нигъмәтулла хәзрәт[17] угыллары Харис[18] вә Харрас[19] ишаннар Габдулла абзыйның гыйлем вә зирәклеген белеп, үз тәрбияләрендәге мәдрәсәгә аны мөдәррис иткәннәр, вә ниһаять бөтен хәлфәләр вә хәзрәт угыллары аның дәресенә утырганнар. Габдулла абзый менә шушы кайтудан Эстәрлебашта калып йорт салган, хатын алган, ләкин ике кызыннан башка бер баласы да булмаган, вә озак заман дәрес әйткәч, Бубыйның Мөхәммәджан хаҗи Әхмәджан углы белән хаҗга барып хаҗ кылгач, Мәдинәдә вафат вә "Җәннәтел-бакыйг"да[20] җирләнгән.

Габдулла абзыйны күреп беләм, зур гәүдәле, зур сакаллы, бик йомшак вә бик сабыр табигатьтле иде. Безгә кунакка килгән вакытында да кулыннан китап, каләм төшермәс, һәрвакыт карар, язар иде. Язган китаплары: "Зөбдәтел-әсрарга шәрех", "Әсраре тәсауыф", "Шәрхе тәүзих", "Хәлли мөшкилят", "Җамигыр-рөмуз", "Татарча мөфассаль кавагыйде гарәбия", "Татарча сарфы гарәби". Ләкин боларның һичберсе басылмаган.

Нигъмәтулла бабайның уртанчы углы – безнең атабыз Габделгалләм. Туган елы 1834 елда. Атасы исән вакытта аның мәдрәсәсендә, атасыннан бик яшьләй ятим калгач, Такта Алачык авылында[21] ишан Фазлулла Фәйзулла углында (бу мәдрәсәгә аны югарыда исеме әйтелгән, мәсҗидне төзетүче Мөхәммәдсадыйк Гайса углы алып барган). Аннан соң Алабуга өязе Тирсә[22] карьясендә, шул Фазлулла хәзрәтнең кияве Мансуров Ягъкуб Нигъмәтулла углы[23] мәдрәсәсендә укып, 1857 елда Бубыйда имам вә мөдәррис булган. Ләкин мөдәррислеге, эш вә мәдрәсә белән булып, рәсми түгел иде. Чөнки ул заман казыйлар, имамлык вә мөдәррислек кебек һәрбер дәрәҗәне ришвәт бәрабәренә сатканга күрә вә безнең атабыз бер тарафтан фәкыйрь булганга, вә икенче яктан шул Тирсә авылында зур милек вә сарайлар хуҗасы Сәлимгәрәй мөфтигә[24] ышанганга, казыйларга[25] акча бирмәгәнгә, казыйлар да аңар тиешле булган мөдәррислек дәрәҗәсен бирмичә, фәкать имам вә мөгаллим кылганнар. Әгәр Сәлимгәрәй мөфти атабызга белеш булмыйча,

бер кешесен, бу шәкертне имтихан кылыгыз, дип Собраниегә[26] җибәрмәгән булса, ихтимал казыйларыбызның атабызны имтихан кылмаенча куып кына чыгарган булырлар иде. Мөфтинең кешесе, "мөфти хәзрәт бу шәкертне имтихан кылырга куша" дип барып әйткәчтен, казыйларның бик кәефләре киткәнен, "мөфти кушкач кылырбыз шул инде" диеп мырылдашканнарын, атабыз үзе Собраниенең шул бозык хәленә борчылып һәрвакыт сөйләй торган иде.

Безнең атабыз Габделгалләм, Бубыйга имамлыкка приговор җыя[27] башлагачтын, ул вакыт Бубыйда бер үзе имам булган Габделкәрим хәзрәт углы Җәмалетдин мулла, халыкны котыртып бик күп каршылыклар ясаган, вә мөмкин кадәр янына имам итмәскә тырышкан. Хәлбуки безнең атабызның анасы Газизә, Җәмалетдин мулла белән бертуган кардәшләр иде. Әгәр югарыда исеме телгә алынган икенче мәсҗидне төзетүче Мөхәммәдсадыйк Гайса углы безнең атабыз өчен тырышмаса, комиссарлар һәм старшиналар белән белеш булып аларны майламаган булса, безнең атабыз Бубыйга һичбер имам була алмас, вә бу шөһрәт тапкан Бубый мәдрәсәсе дә мәйданга чыкмас иде. Бәс, милләтебезгә бик зур хезмәтләр кылган бу мәдрәсәнең абруеннан бер өлеше, хәтта зур бер өлеше, шушы Мөхәммәдсадыйк Гайса углына барып терәләдер.

Бубыйның бишенче имамы менә шушы Габделкәрим хәзрәт углы Җәлалетдин мулладыр[28]. Башта ул безнең Нигъмәтулла бабай өстенә имам булып, аның белән бәрабәр торганнар, вә аның вафаты соңында бер ялгызы имамлык кылган. Туган елы 1222/1807 елда булып, 1287/1870 елда вафат вә Бубыйда җирләнгән. Надан вә гыйлемгә дәртсез булганга, Нигъмәтулла бабайдан соң мәдрәсәләрне бетергән вә балаларны укытмыйча, Бубыйны бик аяныч бер хәлгә куйган. Ихтимал шуны сизептер, Габделкәрим хәзрәт, үз кызын бирә-бирә безнең Нигъмәтулла бабайны үз янына имамлыкка алган, вә мәдрәсәне дә аның идарәсенә тапшырган.

Бәс, безнең атабыз Габделгалләм, Бубыйның алтынчы имамы буладыр. Имам булган елында ук ул Минзәлә өязе Чебенле авылында[29] имам вә мөдәррис Иманкол Мәхмүд углының[30], галимә вә гарәпчә белән фарсычадан да яхшы ук хәбәрдар Бәдрелбәнат исемле кызын никахлаган һәм вафатына кадәр шуның белән, бер хатын белән яшәгән.

Менә Бубыйның тәрәккый вә бәхет көне, шушы безнең атабызның Бубыйга имам булган көненнән башлана. Чөнки шул көннән, атабыз бер тарафтан ирләрне, вә анабыз икенче тарафтан кызларны укыта башлаганнар вә шулай итеп Бубыйны фән вә мәгариф нуры белән яктыртырга тотынганнар. Без-

нең атабыз Бубыйга имам булган чакта, унөч ел элек мәдрәсәләр тәмам беткән вә шәкертләр тәмам таралган булганга, Бубый буп-буш вә гыйлемнән, укудан бернәрсә юк иде. Әмма безнең атабыз имам булып җиткәч тә, остазы Ягъкуб хәзрәт[31] тә бераз шәкерт биреп вә тирә-яктан да байтак шәкертләр җыелып укулар башланган, ләкин салынган мәдрәсә булмаганга, дәресләрне Гәрәй Мөхәммәдрәхим углының өендә укытып торылган.

Укуга сусаган халык, Бубыйда шәкертләр күренгәч тә, фәрештә күргән кебек сөенеп, шунда ук мәдрәсә салу исәбенә кергәннәр. Ул вакыт Бубыйның иң бае вә бүгенге мәдрәсәнең төзетүчесе Мөхәммәдҗан хаҗиның атасы Әхмәдҗан Әхмәди углы заманына күрә ару гына бер мәдрәсә салдырган. Ләкин бер куркак адәм булганга Җәлалетдин мулланың гариза вә котыртуы буенча комиссарлар вә старшиналар "кем салды, нигә салдыгыз?" дип сораштыра башлагачтын, минем җавап биреп йөрер хәлем юк дип, мәдрәсәне яңадан сүтеп аткан вә шулай итеп атабызның да, шәкертләрнең дә эчләренә ут салган вә үзе дә бичара, надан вә ахмаклыгы сәбәпле, милләт алдында бик зур гөнаһлы булып калган.

Менә шушы тәмам кысылып беткән вә бөтенләй аптырап калган бер вакытта, атабыз белән шәкертләрнең ярдәменә, тагын шул югарыда исеме узган Мөхәммәдсадыйк Гайса углы килгән. Мәдрәсәнең милләт дошманнары золымы астында болай харап булуын күреп, Мөхәммәдсадыйк әфәнденең милли хисләре кузгалып мәйданга атылган вә үз кесәсеннән чыгым тотып, тугыз аршинлы бер мәктәп салып куйган. Менә шуннан соң Җәлалетдин мулла, безнең атабызга бигрәк каты дошманлык кылырга вә үз тарафдары кешеләрне мәдрәсәгә каршы котырта башлаган һәм шул вакыттан башлап Бубый халкы да, берсе мәдрәсә вә уку, икенчесе искелек вә наданлык тарафдары булып, ике төркемгә аерылган, һәм бу каршылыклар вә бу дошманлыклар Бубый мәктәбе хөкүмәт әмере белән ябылганга кадәр дәвам кылды вә бүген дә дәвам кыладыр.

Шушы вакытларда һәм аннан соң да, шушы Мөхәммәдсадыйк әфәнденең, атабыз белән шәкертләрне һәм мәктәп вә мәдрәсәне яклау юлында кылган тырышлык вә ярдәмнәре һичбер вакыт онытылачак түгел. Җәлалетдин мулла тарафыннан бер гариза бирелдә исә аңар каршы торучы, тикшерүгә килгән комиссарлар белән старшиналарны майлап вә җайлап кайтарып җибәрүче, вә шул мулланың котыртуы белән мәдрәсә шәкертләрен кыйнарга килеп күсәкләр белән тәрәзәләрне ваткан кайбер кабахәтләрне тотып хөкемгә бирүче, һәммәсе шул Мөхәммәдсадыйк әфәнде булды. Һәм тугыз ар-

шинлы бер мәктәп кенә шәкертләргә бик тыгыз булганлыктан, шушы Мөхәммәдсадыйк әфәнде икенче җәйдә, ягъни 1858 елда, унбер аршинлы тагын бер мәктәп салдырган, вә 1859 елда шул ике мәктәпнең арасын тугыз аршинлы бүрәнә белән берләштереп ашханә иткән. Ләкин моннан соң Мөхәммәдсадыйк әфәнденең байлыгы кимегәнлектән, мәктәпкә матди ярдәм кылудан гаҗиз калган, вә шуңа күрә 1860 елда өченче бер мәктәпне ул түгел, бәлки югарыда әйтелгән беренче мәктәбен сүтеп алган Әхмәдҗан Әхмәди углы салдырган, вә шулай итеп иске йөз каралыгын юарга ирешкән. Мөхәммәдсадыйк әфәнде һәрбер төрле чиновниклар белән мөнәсәбәттә булганга, хәтта исправник булсын, губернатор булсын, узып барган вакытларында аңар кереп йөрүләреннән аның мәдрәсәне яклавы, мәдрәсәне ябудан вә сүтүдән коткару юлында бик зур файдалар ясаган. Бу Мөхәммәдсадыйк әфәнде мин белгәндә дә сәламәт вә һаман шушы мәдрәсәне яклау юлында иде. Мәдрәсә дошманнарының: "Мәдрәсә салдырган булып бөлеп беттек инде", - дигән сүзләренә каршы: "Минем байлыгым мәсҗид, мәдрәсә салмасам да бетәчәк иде. Ичмаса, Аллага шөкер, мәсҗидләр, мәдрәсәләр салып куйдым. Мин менә хәзер шуларны күреп шатланам. Сезнең шатлана торган нәрсәгез бар?" - диеп авызларын яба торган иде. Месценнең ахыр гомерләрендә паралич булып, кулы коруын, Җәлалетдин мулла тарафдарлары мәдрәсә салдыруыннан, Югары Бубый чирмешләре аларның кирәмәтләрендәге изге каен агачын кисүеннән күрә торганнар иде. Мәрхүм туксан биш яшендә, вә үлгән вакытында балаларына, һәрвакыт мәдрәсәне яклагыз дип васыять әйтеп, 1897 елда Алланың рәхмәтенә иреште. Без вә бөтен милләт синнән разый Мөхәммәдсадыйк абзый. Аллаһы да синнән разый булсын!

Ошбу Мөхәммәдсадыйк әфәнденең мәдрәсәсе 1877 ел ахырына кадәр дәвам кылды. 1875 елда мәшһүр Мөхәммәдҗан хаҗи Әхмәдҗан углы берьюлы ике мәктәп салдырды. 1881 елда Мөхәммәдсадыйк әфәнде салдырган бик иске вә бик эчергән мәктәпләрне сүттереп, берсе унике вә берсе ун аршинлы тагын ике мәктәп салдырды. Заманына күрә мәдрәсәләр бик иркен вә шәкертләр өчен бик җайлы булды. Менә шушы вакыттан соң мәдрәсә төзелеше һәммәсе Мөхәммәдҗан хаҗиның кесәсеннән сарыф кылына башлады.

Менә Мөхәммәдҗан хаҗиның мәдрәсә белән мөнәсәбәте шушы еллардан башланган кебек, минем дә мәдрәсәгә кереп шәкертлек вә шәкертләр белән мөнәсәбәтем шушы еллардан башланды. Һәм без Бубый мәдрәсәсе ябылганга кадәр, Мөхәммәдҗан хаҗи тышыннан, без эченнән хезмәт иттек. Мин

ул вакытта сигез-ун яшьләрдә булырмын, "Мөхтасарел-викая" белән "Сарфы гарәби"дән кереш укыйдыр идем. Өебез бик таза вә иркен, мәдрәсә бик пычрак вә бик тыгыз булса да, белмим, нигәдер, ихтимал, әткәйнең уйнарга бер дә ирек бирмәвеннәндер, минем җәен-кышын мәдрәсәдән кайтасым килмәс иде.

Мәдрәсә, хәзерге мәсҗидкә ун сажиннан артык ерак булмас иде. Шунлыктан мәдрәсә дошманнары, башлыклары шул вакытта әткәйнең иптәш мулласы вә Бубыйның җиденче имамы Бәдретдин мулла Җәлалетдин углы булган хәлдә[32], мәдрәсәне яптырып, шәкертләрне тарату нияте белән, "мәдрәсә мәсҗидкә бик якын, тәртип вә законга каршы" диеп гариза бирделәр. Ләкин тикшерү вакытында Мөхәммәдсадыйк Гайса углы, мәсҗид белән мәдрәсәнең бер планда икәнлеген күрсәтеп, мәдрәсәнең мәсҗидкә якынлыгы тәртипкә каршы булып чыкмады. Соңыннан аңлашылды, Мөхәммәдсадыйк әфәнде дәгъва эшен бик яхшы белгәннән вә киләчәген уйлаганга, мәсҗидне салдырган вакытта, шуның белән бер планга мәдрәсәне дә керттереп кулына алырга ирешкән булган икән.

Бу мулла Бәдретдиннең туган елы миңа мәгълүм түгел. Әмма укуы Түнтәрдә[33], Шәмсетдин бине Рәхмәтулла[34] мәдрәсәсендә. Атасы Җәлалетдин мулланың вафаты соңында ул, әткәй өстенә имамлыкка кергән, вә шул көннән башлап дошманлыкка тотынган. Дөньяда ошбу Бәдретдин мулла кебек бозык, вөҗдансыз, фетнәче, миллият вә дин хөрмәтен белмәс икенче бер адәм я булыр, я юк. Тирәсенә үзенә муафыйк бар бозыкларны җыйган, шайтанлыкта шайтаннан да уздыруын бөтен янәшә-тирәгә күрсәткән бу бераз дине вә вөҗданы бар һәрбер адәмнән ләгънәт алган иде. Хөкүмәтне дә мәдрәсә өстеннән гариза бирә-бирә аптыратканга, комиссар килеп мәдрәсәнең мәсҗидкә якынлыгы законга каршы түгел диеп игълан кылды, һәм аннан, мәдрәсә хакында икенче мәртәбә гариза бирмәм диеп имза алды, ләкин бу милләт дошманы бозыклыктан һаман туктамады, һәр көн вә һәр сәгать мәдрәсәне бетерү иҗтиһадында булды, бар гомерен шуңар сарыф кылды, вә шул хакта атнага ике вә һич булмаса, бер тапкыр, Бубыйдан илле чакрым җир Сарапулга бармаенча калмады, вә ахырында Сарапулдан мәдрәсә хакында гариза биреп кайтканда хәстәләнеп, өч көннән соң Әбүҗаһилләр, Әбүләһәпләр янына китте[35].

Бәдретдин мулла хакында сөйләгән бу артык каты сүзләрне, ихтимал, тиешсезрәк күрүчеләр дә булыр. Ихтимал, шулайдыр. Ләкин, әгәр сез бу юньсез адәмнең мәдрәсәгә китергән казаларын, шәкертләргә чиктергән бәла вә хәсрәтләрен белсәгез,

күнелегездән ихтыярсыз кубып килгән меңнәрчә ләгънәтләрне сез дә туктата алмас, әйтә бирерсез; яхшы әле, ул вакытта донос модада түгел, аны белгән кеше юк иде. Әгәр бу мәлгун юлны Бәдретдин мулла белсә, Бубый мәдрәсәсе бүгенгә калмас, бәлки моннан утыз-кырык ел элек үк ябылыр иде, вә милләтебез аннан күргән бу кадәр файдалардан бөтенләй мәхрүм калыр иде.

Ул исән вакытта һичбер көн калмады ки, мәдрәсәгә бер бозык мужик кереп шәкертләрне төрле начар сүзләр белән сүкмәгән, яки стражник-фәлән килеп берәр җавап сорамаган. Хәтта шул шакшының ришвәт бирүе сәбәпле, Солтан исемле мөселман бер урядникның, паспортлары юк кырык-илле зур шәкертне, кыш уртасында, чатнама суыкта, үзе төнлә тагы, сарык көтүе кебек җәяү, Бубыйдан биш чакрым җир Әгерҗегә комиссарга алып китүе, вә шунда илтеп бер тәүлек ябып торгызуы, хәзер дә бөтен ямьсез мизгелләре белән күз алдымда тора. Мин ул вакытта мәктәптә, бала идем. Хәлфәләр артыннан елашып калганыбыз исемә төшсә, бүген дә эчләрем пошып, еласым килә башлай.

Безнең татар шулай менә, түрә булдымы, һичшиксез, үз милләтенең зарарына йөри, үз кардәшенең канын эчә. Әгәр стражник татар булмаенча, берәр рус булса, һичшиксез, ул бу эшне эшләмәс иде. Хәтта шул вакыттагы рус комиссар да, Солтанны бу эше өчен бик шелтәләп (башта үзе өйдә юк икән), үзе кайткач та шәкертләрне кайтарып җибәрде. Вә ни сәбәптәндер, Солтан да урынында озак тормады, төшерелде, вә шул хәсрәттән булырга кирәк, үзен-үзе асты, ләкин вакытында күреп бавын кисеп өлгерделәр, максатына ирешмәде. Хәзер Уфада ул, безнең Собраниедә, нинди булса бер урында. Мөхәммәдьяр мөфтинең[36], эштән чыккан кешеләрне шунда, безнең дини идарәгә җыюы, аның үзенә махсус, бик сәер гадәт инде ул.

Шул Бәдретдин мулла исән вакытта, мәдрәсәне бераз төзәттерә башлар хәл юк, шул мулланың котыртуы буенча шунда ук старшина килеп җитәр, вә кемнән сорап саласыз диеп куркытырга тотыныр, хәтта хаҗәтханә сала башласаң да, юлга, яисә бер күршенең милкенә якын диеп стражник чакыртылып, эш туктатылыр иде. Хәтта шул сәбәпле бер язда яз буенча шәкертләр хаҗәтханәсез калып хаҗәтләрен үтәү өчен төнлә күршеләренең бәрәңге бакчаларына кереп йөрергә мәҗбүр булдылар.

Әткәй безнең, русча белмәгәнлегеннән, закон каршында җавапка калудан бик куркыр вә ул вакытның начар старосталары белән начар старшиналары шуннан файдаланып әткәйне

куркытырга бик тырышалар иде. Бер көн әткәй дәрестә иде, Бубыйның бик начар старшинасы, Әхмәди исемле кеше, исереп мәдрәсәгә килеп керде. Үзе маршлап йөри, үзе мәдрәсәне сүттерәм диеп, фәлән итәм диеп әткәйне сүгә. Әткәй мескеннең шул бәдбәхетне: "Әхмәди агай, тукта әле, сабыр ит, менә безгә чәй эчәргә бараек", - диеп йомшак кына телләр белән юмалап маташуы, бүген исемә төшсә дә, кәефемне качыра, шул йөзе караның каберенә барып каберен булса да таптасым килә башлай.

Бәдретдин мулла, болай гариза белән генә мәдрәсәне бетерә алмагачтын, аны яндырып бетерү исәбе белән бер кышта өч мәртәбә ут та салдырып карады. Ләкин вакытында сизелеп, максаты хасил булмады. Шулай да аның көн саен гаризасы, вә әткәйнең көн саен җавабы һаман өзелмәде. Әткәйгә көн саен хәсрәт бер дә туктамады. Шуңар күрә әткәйнең кайбер куркак дуслары аңар мәдрәсәне бөтенләй ябып куярга вә укытудан бөтенләй ваз кичәргә дә киңәш биреп карадылар. Ләкин вакытлыча булса, да Бубыйның күрәчәк көннәре вә милләтебезнең изге сәгатьләре бар ки, атабыз һәм Мөхәммәдсадыйк Гайса углы бу фикергә каршы тордылар, вә мәдрәсәне мәсҗид янынннан хәзерге урынга күчерү белән канәгатьләнделәр.

Бу урын һәрвакыт мәдрәсәгә теләктәш вә кулыннан килгән кадәр һәрбер ярдәмнән кире тормаган Әхмәджан Габделкәрим углының[37] сатып алган урыны иде. Бу урын һәрбер тарафыннан да су белән бүленеп, авыл халкыннан һичкемнең йорты белән тоташ булмаганлыктан, шәкертләр өчен бик җайлы вә бик мәгъкуль иде. Бәс, 1888 елда, Мөхәммәджан хаҗи ялгыз үз чыгымы белән мәдрәсәләрне бу урынга күчереп, кайсын төзәтте вә кайсын бөтенләй яңадан салды, һәм ятьмә белән әйләндереп, яхшы капкалар ясатты. Күчкән елда яз көне су ташуында шәкертләр су аркылы сал белән йөреп бата-чума бик аптыраганга, икенче җәйдә мәдрәсә өчен махсус бик яхшы күпер дә куйдырды. Бүген ул күпер, иске булса да, һаман бар вә һәркем шуннан йөри.

Бубыйның әнә шул шөһрәт тапкан мәдрәсәсе бүген дә шунда, менә шушы Әхмәджан Габделкәрим углы вәкыф кылган урында утыра. Бу урын хәзерендә дә бик зур, үзенең дүрт тарафы су һәм эче вә мәдрәсәләрнең тирә-ягы без тәрбияләп үстергән агачлар, сиреньнәр, акацияләр, тупыллар вә башка агачлар арасында һәм бик зур бер тирәк белән бик ыспай бакчалыктыр. Шуның өчен дә 1908 елда, шул Әхмәджан Габделкәрим углы вафат булгач, аны ихтирам йөзеннән бөтен мәдрәсә шәкерте җеназасына чыктылар, күтәреп илттеләр, вә

кабер янында аның миллəтебезгə иткəн хезмəтлəренə кагылышлы нотыклар сөйлəделəр.

Мин аны менə хəзер дə рəхмəт белəн искə аламын, вə бөтен миллəт тə аны мəңгелек искə алачактыр. Рəхмəт Əхмəджан абзый! Син үз кулыңнан килгəн һичбер хезмəтеңне миллəтеңнəн кызганмадың! Оҗмахлар кебек урыныңны мəдрəсəгə биреп шəкертлəрне, миллəтеңне шатландырдың! Без вə бөтен миллəт синнəн разыйбыз. Аллаһы да синнəн разый булсын! Урыныңны оҗмахта сөекле бəндəлəре белəн бəрабəр итсен!

Мəдрəсə бу яңа урынга күчкəчтен, шəкертлəр начар вə əдəпсезлəрнең ызгышуыннан тынычласалар да, Бəдретдин мулланың дəгъва вə гаризалары һаман бетмəде, дəвам кылды. Көн саен бер дəгъва вə көн саен бер вак эш табып торды. Хəтта əткəйне, мəдрəсəдə акча ясата диеп күрсəтеп, мəдрəсəлəрне һəм безнең йортларны тентетте: апрельнең ахыры иде. Без, шəкертлəр белəн сабакта, əткəйнең дəресендə идек. Бер дə сизмəстəн Сарапул комиссары егерме биш-утыз стражник белəн килеп мəдрəсəне дə, безнең өйне дə чолгап алды. Шəкертлəр кайсы кайда булса, аны шунда тотып алдылар, тыштан һичкемне чыгармадылар, вə эчтəн һичкемне кертмəделəр. Өс-баш, күлмəк-ыштан, читек балаклары һичберсе калмады, каралды, китаплар, кəгазьлəр актарылды, базларның казылмаган җире калмады, лəкин бер гармун белəн тəмəкедəн башка бер нəрсə дə табылмады. Бер дə булмаган вə искə кермəгəн бер нəрсə ничек табылмак кирəк? Моннан соң комиссар доносның ялганлыгына тəмам ышанып, өебезне карамады да, əткəйдəн гафу үтенде вə шул көенчə кайтып китте. Комиссар тəмəкене күргəч: "Бу эшегезне мөфтигə язсам ничек. булыр?" - дигəн иде. Əткəй аңар: "Мөфти үзе дə тарта, бер нəрсə дə булмас", - диеп аны җавапсыз калдырды. Андый тискəре җавапка бик шəп иде ул.

Иң башта бу яңа урынга ике җирдə кара-каршы вə араларында өй алды белəн тугызар аршинлы дүрт мəктəп вə бер ашханə салынды. Вə бу мəктəплəрнең 1895 елга кадəр шул көенчə дəвам итте вə урынында торды, вə Бубый мəдрəсəсен иске хəленнəн чыгарып ислах кылу да шушы мəктəплəр эчендə башланды.

Безнең иске Бубый мəктəбенең читтə шөһрəте булмаса да, шул заман шөһрəт тапкан Түнтəр, Кышкар[38] вə Казан мəдрəсəлəрендə укыла торган һəрбер фəн Бубыйда да укыла, хəтта ул мəдрəсəлəрдə укылмаган, яки бик аз вə җəй көннəрендə каникул вакытларында гына укылган тəфсир вə хəдислəр дə providedбездə дəрескə салына торган иде. Бездə ул вакыт

татар мәктәпләренең һичберендә юк ибтидаия тәртибе[39], табигый, юк иде. Шуның өчен мәдрәсәдә 7-8 ел укып чак язу танырлар, вә бу кадәр вакыт укырга форсаты булмаган фәкыйрь балалар, язу-уку да белмәсләр, шул аналарыннан тума чыгып китәрләр иде. Ләкин башка мәдрәсәләрдәге кебек бездә дә, сарыфтан кереш белән "Шәрхе Габдулла", нәхүдән кавагыйд белән "Гавамил", "Әнмүзәж" һәм "Мулла Җами", мантыйктан "Исагуҗи Ногман" белән, "Шәмсияи Мирсәед" белән һәм "Сөллям казый" белән, кәлямнән гакаид белән һәм "Мулла Җәлал", "Ахунд Йосыф" белән, бәлягатьтән "Тәлхис", фикъһыдан "Мохтасар" белән "Һидая", ысулдан "Зөбдәтел-әсрар" һәм "Тәүзих" белән "Тәлвих", әхлактан "Гайнел-гыйлем" белән "Тарикаи Мөхәммәдия", хәдистән "Мишкятел-мәсабих" белән "Сахихел-Бохари", тәфсирдән "Казый Бәйзави", хисаптан "Хөлясәтел-хисап", фараиздан "Сираҗия" укылыр иде.

Менә ул вакыт Бубый мәдрәсәсенең бар програмы, мәгълүматы шуннан гыйбарәт иде. Бу мәдрәсәдә бидан белән "Шәрхе Габдулла", "Кавагыйд" белән "Гавамил", "Исагуҗи" белән "Ногман", гакаид, "Зөбдәтел-әсрар" белән "Мөхтасарел-викая" укылып бетсәләр дә, башкалары күбесе яртысыннан, хәтта кайберсе башыннан да узылмас иде. Шулай булса да, безнең әткәй башка күп мөдәррисләр кебек кунакка йөреп, шәкертләрне буш калдырмас, уку елы дәвамында башка авылларның һичберсенә кунакка чыкмас, вә дәрес вакытында Бубыйның да туеннан, ягъни никах мәҗлесеннән башка һичбер ашына бармас, һәм башка бик күп мәдрәсә шәкертләре ике-өч көндә, хәтта атнасында бер дәрес белән ятканда, безнең әткәй шәкертләрне көнлек бер дәрестән бер дә куймас, вә шулай була торып үзе мәсҗидтән, биш вакыт намаздан һичбер сәбәп белән калмас, ләкин шәкертләрне, хәтта безне дә мәсҗидкә йөрегез диеп һичбер вакыт көчләмәс иде. Иртән сәгать тугызынчы яртыдан уникегә, төштән соң икедән бишкә һәм кыш көне, көн кыска вакытларда ястүдән соң кереп сәгать тугызларга, уннарга кадәр дәрес белән шөгыльләнер иде. Диндар, бик тәкъва иде. Хәрамнан бик нык куркыр вә һичкемнең хосусый хәлен сөйләп вә тикшереп чуалмас, ваксынмас иде. Хаклыкны сөйләүдә бай, фәкыйрь — һичкемнән куркып тормас, вә хәйлә-фәлән белмәс иде. Хәтта Сәлимгәрәй мөфти, Гәйнә башкортларын солдат бирергә димләп кайтканда безгә кергән икән. Сүз арасында: "Мин падишаһтан бу эшем өчен рәхмәт алдым", - диеп мактануына каршы әткәй аңар: "Динеңне, милләтеңне сатып бик яхшы иткәнсең икән", - диеп, туп-туры гына авызын япкан. Шул һәрбер сүзне туп-туры сөйләгәнлек өчен дә, аның дошманнары бик күп иде. Ләкин алар никадәр

явызлык теләсәләр дә, безнең әткәйгә бер зарар да китерә алмадылар, бәлки үзләре каһәрләнеп вә хурлык, хәсрәт вә газап туфрагына күмелеп беттеләр.

Безнең әткәй имам булган вакытта Бубыйда өч кабак булып, урамнар исерек белән тулы, вә Бубыйның иң ару дигәннәре дә исерешеп урамда йөрерләр, имеш. Әткәй имам булгач та иҗтиһад кылырга тотынып, шул өч кабакның өчесен дә бетерткән, вә акрын-акрын исерекләрне дә һәм тыйган. Шәкерт вакытында да һәм имам булгачтын да башта фәкыйрь булып, аннан соң кайбер нәрсәләр белән сату итеп байлык тапкан, вә 1869 елда хаҗга барып кайткан. Ишаннарны сөймәс, чалманы гарәпләрнең киеме генә диеп, аны киюне савапка санамас, ашап туйгачтын кул күтәреп дога кылып маташмас, өйдә түбәтәен бер дә кимәс, аяк өсте сиюне дөрес дияр иде. Һичбер вакытта фытыр садакасы, зәкят[40] вә фидия[41] алмады. Ахыр гомерләрендә хәдис китапларын, аеруча "Сахихе Бохари"ны һәр вакыт карады. "Ихъяи голумне" вә Шиһаб хәзрәтнең[42] һәрбер әсәрен сөя-сөя укыр, әмма Түнтәр Ишминең[43] китапларын, "ахмак баштан чыккан ахмак сүзләр белән гомеремне әрәм итәр хәлем юк" диеп кулына да тотмас иде. "Тәрҗеман"ны[44] вә башка төрек газеталарын бик яратып укыр, вә грек белән төрек сугышында[45] һөнәр күрсәткән төрек офицерларының рәсемнәрен "Сәрвәтел-фөнүн"[46] журналында күреп елай-елай карар вә дога кылыр иде. Гакылы-фикере һәрвакыт уку вә укытуда иде. Тирә-якка мулла булган берәр шәкерте килсә, иң элекке сүзе — мәктәптән вә авыл балаларының укуларын сорау иде. Укыткан шәкертеннән бик канәгать булыр, вә укытмаганына бик кәефе китеп, аны үгетләү вә укытуга кызыктыру юлында бик әсәрле сүзләр сөйләр иде. Ысуле җәдид[47] хакында муллаларның ике тара булуына бик көенер, вә ысуле җәдидне куәтләү турысында бик күп дәлилләр китерер иде.

1901 елда, фән вә гарәп теле имтиханына тирә-яктан бик күп муллалар килгән иде. Бубый мәктәбендәге уку вә укытуны һәммәсе мактап сөйләүләре соңында, атабызның күзләре яшь белән тулып: "Кайсы муллалар ысуле җәдидне хурлап маташалар. Минемчә, ысуле җәдидчеләр, һәрбер йөз башында бер җәдидче килер, дигән хәдиснең туры килүеннән башка һичбер нәрсә түгел. Болар, иске вә онытылып беткән укыту ысулын яңарталар. Мин Ходайдан шушы ике углым, Гобәйдулла белән Габдулланы да шул җәдидчеләр җөмләсеннән кылуын өмет итәмен", — диеп, бөтен мәҗлестә булучыларны елатты. Әткәбезнең Гобәйдулла исемле бер вә Габдрахман исемле ике углы һәм Гайшә исемле бер кызы сабый вакытларында вафат

булып, үзеннән соң без өчебез генә калдык: мин, Гобәйдулла Мөхәммәдфәйзи[48], Мөхлисә.

Мәрхүм шәкертләрне бик сөяр, вә аларга халык тарафыннан бер сүз әйттерергә дә разый булмас, һәм аларны бик яхшы итәргә тырышыр иде. Ләкин минем күз алдымда, шәкертләрне яхшы итү максатына һичбер җитешә алмады ул. Дөрес, безнең мәдрәсәдә, Түнтәр вә Кышкар мәдрәсәләрендәге кебек хәлфәләрне сабак өйрәнер өчен бер стакан аракыга ялланулар, әфъюн салулар, авылдагы хатын-кыз артыннан йөрүләр — боларның берсе дә юк иде. Ләкин һәркем тәмәке тартыр, бик күбесе һичбер көн аракыдан өзелмәс, унар-унбишәр шәкерт көн саен диярлек, Бубыйга якын чирмеш, ар авылларына барып, төн буенча типтереп кайтыр, тәһарәт белән намазны бик азы тәмамлар, хәтта кайберсе рамазанда рузә дә тотмас иде. Уен кораллары тавышлы вә сизелүчән була торып, әткәйнең сабакка комачау диеп бик каты каршы торуына карамастан, мәдрәсәдә дүрт-биш гармун бер вакытта да өзелмәс, вә әткәй дәрестән чыгып китте исә, шунда ук уйнарга тотынылыр иде. Кайберәүләрне искә алмаганда, сабакка тырышучы һичкем юк, бәлки бар хәлфәләр белән зуррак шәкертләр бергә җыелышып, һәркөн төн буенча кәртле, акчалы уйнарлар иде.

Миңа үзем тәрбияләнгән иске мәдрәсәләрнең бу серләрен ачуы да кыен. Әгәр кадимчеләрнең "иске мәдрәсә шәкертләре динле-диянәтле иде, ысуле җәдид шәкертләре бозылды, дин-тәүфыйк бетте" дип халыкны алдаулары булмаса, мин бу сүзләрне һич ачмас идем.

Менә иске мәдрәсәләрнең иң яхшы вә иң тәүфыйклысы — безнең Бубый мәдрәсәсенең хәле шушы иде. Әмма Кышкар вә Түнтәр кебек начарлык вә бозыклык белән мәшһүр мәдрәсәләрдә бу эшләрнең барысы өстенә, һәркемгә сатлык ике-өч углан да узылмас иде. Иске мәдрәсә шәкертләрендә дин дә бик зәгыйфь иде. Мин үзебезнең иске мәдрәсәбездәге, мулла Җәлалның[49] "Вөҗдәи хәмсә"сен укыган, иң зирәк вә иң аңлы берничә шәкертне беләм, үз араларында ахрысы, галимнәр сүзе хак булырга кирәк дип бик җитди сөйләшә торганнар иде. Бәс, дин вә тәүфыйк тарафыннан караганда, иске мәдрәсә шәкертләрен яңа мәктәп шәкертләреннән, һичбер җәһәттән дә артык санарга мөмкин түгел. Әмма, әгәр без уку һәм гыйлем-тәрбия тарафыннан карасак, яңа шәкертләрнең иске шәкертләргә караганда абруй вә өстенлеге кояштан да ачык күренеп торадыр.

Ихтимал, атабызның саф күңеле шуны бераз сизгән булырга кирәк ки, ысуле җәдидне бер дә каршылыксыз кабул кылды, вә үзе бу ысулны ничек ислах итү юлын белмәгәнлектән,

мәдрәсәдән тәмам ваз кичеп, һәрбер эшне безгә тапшырды, вә сигез ел безнең мәктәп ислахыбызны шатлана-шатлана карап торып, тыныч җан вә тулы шатлык эчендә мәңгелек йортка китте. Ошбу сигез ел эчендә без, мәрхүм атабыз аркасында, исламны инкяр итүчеләрнең ләгънәт вә кяфер дип атауларына бер дә очрамадык. Чөнки ысуле җәдиднең вә мәдрәсәләр ислахының зарурлыгы вә кирәклеге, безнең өчен ул (атабыз) сөйләр, бу хакта һәрбер бәхәсне ул кылыр вә тирә-яктагы һәрбер имамның остазы вә һәрберсеннән гыйлемдә өстен булганга, берсенең дә авызын ачырмас иде.

Кырык елдан бирле фәкать искечә дәрес әйтеп килгән вә искелектән башка һичбер нәрсә күрмәгән бер татар мөдәррисенең, ысуле җәдидне һәммә карталары вә кара такталары белән кабул кылуы, вә бер углын Истанбулда еллык дүрт-биш йөз сум чыгым тотып биш ел "Мәктәбе милкияи шаһанә"дә[50] укытуы вә тәмам кылдыруы, безнең татар мөдәррисләренең хәл вә әхлагын белгән кешеләрне бер дә гаҗәпләндермәслек бер вакыйга түгелдер.

Без менә тәрәккъый дошманнарының кяфер дип атау вә ләгънәтләренә, әткәйнең вафаты соңында килеп очрадык. Ул сәламәт вакытта ишетмәгән яла вә ялган гаепләрне, аның вафаты соңында ишеттек. Ул сәламәт вакытта посып яткан дошманнарның төрле һөҗүмнәренә аннан соң, аның вафаты соңында килеп юлыктык. Ләкин мәрхүм Бубый мәктәбенең дәһшәтле нур чәчкән вакытларын, шул сөенеч вә шатлык вакытларын да күрә алмады, һәм бөтен милләтнең ачынулы вә канлы яшьләре арасында ябылган шушы хәсрәтле көннәренә дә ирешмәде. Дөньяда бөтен максатын күреп үлгән кемнәр генә бар соң? Бичара әткәй дә Бубый мәктәбенең, куәтле тәртип вә тәрәккъыен күрә алмады, без дә үзебез өмет иткән максатларыбызның уннан берсен дә күрә алмадык, залим яла ягучыларның вә инсафсыз хөкүмәтнең теш вә тырнаклары арасында бетте мәктәп, сүнде.

Бер адәмнең дөньяга килүе бер милләт өчен тормыш җәүһәре булса, икенче бер адәмнең тууы, ул милләт өчен үтергеч агу булганлыгы һәр көн күренеп торган бер табигый канун бит. Менә шулай ук Бубый мәктәбе өчен дә атабызның тууы тормыш җәүһәре, вә Бәдретдин мулланың тууы үтергеч агу иде. Ләкин Аллаһының бик зур рәхмәте булды да, атабыз сәламәт вакытта ук вә мәктәпне ислахка керешүдән элек үк, мәктәп вә милләт Бәдретдин мулланың шакшы гәүдәсеннән котылды. Шулай ул, әгәр бер эшнең киләчәге өметле булса, Аллаһы тәгалә үзе җай: китерә дә тора. Әгәр, Алла сакласын, Бәдретдин мулла Бубый мәктәбен ислах вакытларында исән

булса, бу мәктәпнең күптән үк эзе калмас, җомгаларда татарча хотбәнең исеме дә булмас. Мәсҗидтә иганә сандыгы куелмас, безне Бубыйдан күптән сөрерләр, Бубыйдагы милләтебезгә бик күп хезмәт итеп ябылган ирләр вә кызлар мәктәбенең торуы да икеле булыр, мөгаен, тормас иде.

1895 елда, туганым Фәйзи ул вакытта Истанбулда иде, мин ибтидаи балаларга ысуле җәдид мәктәбе ачмакчы булып, Миңлешәех Фәттахетдин углы Галимовны Бакчасарайга, Исмәгыйль әфәнде Гаспринскийга ысуле җәдид өйрәнергә җибәрдем һәм, Мөхәммәдҗан хаҗидан үтенеп, дүрт сыйныфка зур-зур дүрт бүлмәдән гыйбарәт бер мәктәп салдырттым, аяклы парталар вә кара такталарның һәммәсен хәзерләттем.

Акча Мөхәммәдҗан хаҗиның булса да, аны сарыф кылучы, вә бу мәктәп артыннан бил бәйләп йөрүче, аның вәкиле Ибраһимов Әхмәдҗан әфәнденең углы Габдрахман әфәнде булды. Бу Габдрахман әфәнде, төп Казан ягыныкы булса да, хәзер төп йортлары Уфа губернасы Бөре өязе Сәйтәк авылында[51]. Бу Габдрахман әфәнде үзе Мөхәммәдҗан хаҗида вәкил булса да, үзләренең дә байлыклары юк түгел: тире белән зур сатулары, Борай[52] дигән алты мәсҗидле авылда зур кибетләре, һәм Сәйтәктә дә тире заводлары, вә үз кесәләреннән тәрбия кыла торган яхшы бер ибтидаи мәктәпләре бар. Бубый мәктәбенең матди реформа вә төзелүеннән, Мөхәммәдҗан хаҗиның акчасы вә Габдрахман әфәнденең кулы-тырышлыгы кермәгән һичбер нәрсә юк. Габдрахман әфәнде хөр фикерле, гайрәтле, яңалыкны яклаучы, эшлекле кешедер. Бубый мәктәбен ислахның башыннан алып ябылганга кадәр, безнең максатларны тормышка ашыру юлында бик иҗтиһад иткән адәмнәрнең берсе Мөхәммәдҗан хаҗи, икенчесе Габдрахман әфәнде.

Ошбу 1895 елда, минем дә указ кайтып, сигезенче буларак Бубыйга имамлыкка билгеләндем. Туганым Гобәйдулла Мөхәммәдфәйзи дә шушы елда, көз көне, Истанбулдан, "Милкияи шаһанә"дә игъдадияне[53] бетереп кайтты, вә ибтидаиябезне тәртипкә кертү юлында бик күп тырышлыгын сарыф кылды, вә акрынлап зур шәкертләрне дә укыта башлады. Атабыз шушы елда мәдрәсәдән бөтенләй ваз кичеп, уку вә укыту эшләрен бөтенләй безнең кулыбызга, безнең фикеребезгә тапшырды. Шушы елда Мөхәммәдҗан хаҗи да ибтидаия баш мөгаллиме Миңлешәех әфәндегә хезмәт хакы билгеләде. Мәктәпнең утыннарын, лампа, майларын, хезмәтчеләр белән аш пешерүчеләрен, барысын да үз өстенә алды. Димәк ки, шушы 1895 елда Бубый мәктәбенең алга китеше өчен тиеш булган матди вә мәгънәви бик күп нәрсәләр бирелде туры

килде ки, бу исә бу мәктәпнең тәрәкъкый табачагы хакында бер хәерле фал иде.

Һәрбер эшнең иң элек нигезен яхшы кору зарур булганлыктан, без иң элек мәктәп ислахына да ибтидаиядән вә аны тәртипкә салудан тотындык, вә акрын-акрын гарәп теле шөгъбәләрен дә үзгәртергә керештек. Асылда, гарәбият шөгъбәләрен берьюлы үзгәртергә тотыну мөмкин түгел, куркыныч иде. Чөнки искечә гадәтләнгән вә шунда тәрбияләнүдән башканы күрмәгән шәкертләрне берьюлы тәртипкә кую, бигрәк тә аларның һәрбер искене изге санай торган аталарын яңачага риза итү, бик мөшкел, шуңа күрә берьюлы үзгәртергә керешкән вакытта гарәбият шөгъбәсенең бөтенләй таралып китү, андагы бар мулла балаларының качып бетү ихтималы бик якын иде. Хәтта ибтидаияне тәртипкә салу өчен дә, ике хәлфәбез риза булмаенча, мәдрәсәне ташлап чыгып киткәннәр иде. Шуңа күрә үзгәрешне сиздермәс өчен эшне акрынлык белән йөртү тиеш иде.

Без менә шулай иттек: иске китапларны акрын-акрын чыгарырга, вә яңа китаплар белән яңа фәннәрне ипләп-ипләп кертергә керештек, шулай итеп шәкертләрне акрынлап яңа китаплар белән яңа фәннәргә гадәтләндердек, вә 6-7 ел арасында үзебез теләгән үзгәрешне тәмам ясап җиткердек. Ошбу 1895 елда ибтидаияне менә бу тәртипкә куйдык:

| Дәрес исемнәре | 1 нче сыйныф | 2 нче сыйныф | 3 нче сыйныф | 4нче сыйныф |
|---|---|---|---|---|
| Әлифба, имля, уку | 18 | | | |
| Унга кадәр хисап | 4 | | | |
| Коръән | 2 | 6 | 6 | 6 |
| Йөзгә кадәр хисап | | 4 | | |
| Игътикад вә гыйльме халь | | 3 | 4 | 4 |
| Төркичә уку | | 6 | 4 | 4 |
| Төрки имлясы | | 4 | 1 | 2 |
| Сүрәләр ятлау | | 1 | | |
| Меңгә кадәр хисап | | | 6 | |
| Хисаптан дүрт төрле гамәл | | | | 6 |
| Тәҗвид | | 2 | | |
| Җәгърафия | | | 1 | 2 |
| Тарихе әнбия вә ислам | | | 1 | 1 |
| Атнадагы дәрес сәгате | 24 | 24 | 25 | 25 |

Иске мәдрәсәләрнең һичберсендә, шулар җөмләсеннән бездә дә, тәҗвид белән Коръән укыту бер дә булмаганлыктан, муллалыкка чыгачак шәкертләр намаз дөрес булыр кадәре Коръән укый белүдән дә мәхрүм калырлар иде. Шуның өчен, унбер-унике яшәр балаларының, тәҗвид белән Коръән беләчәкләренә, башта һичбер мулла ышанмаган иде. Аннан соң, имтихан вакытында күргәннәреннән шаклар каттылар, вә ихтыярсыз "ә", диделәр, "бу ысуле җәдид дигән нәрсәдә яхшы эшләр дә бар икән".

Бу вакытта, атабыз сәламәт булганлыктан, аннан куркып иске фикерле муллалар да безнең ысуле җәдид мәктәбенә каршы бер сүз дә әйтә алмаслар иде. Фәкать Әгерже Каюм мулланың атасы Фәттах мулла Халиков[54], үзе асрау кызыннан бала таптыра торып, кара такта эчендә тәре бар дип, иң якын дус һәм кардәше Бәдретдин мулладан калган иске дошманлыгын тагы чыгарып куйды. Ләкин, халык эшне күзләре белән күреп белгәнгә, аның сүзенә илтифат иткән, аңар ышанган һичбер кеше булмады.

Бер вакытларда Бубыйда акча мәсьәләсе бик авыр, вәкыфның[55] исеме дә юк, имтиханда ваклап җыелган йөз сумлап иганәдән артык акча табар хәл булмаганлыктан, дүрт сыйныф ибтидаиядәге дүрт мөгаллимнән өчесе бөтенләй буш, вә баш мөгаллим Миңлешәех әфәндегә дә Мөхәммәдҗан хаҗи айлык бары ун сум гына бирер иде. Хәлбуки, бу вакыттан бер ун еллар соң без мәктәпкә якынча еллык ун меңләп чыгым тотып аның да акчасын таба башладык. Ягъни, бер эшне саф күңел вә тырышлык белән эшләгән вакытта, ул эшнең һич тә тормышка ашмай калу ихтималы юк. 1895 елда, Миңлешәех әфәндене Бакчасарайга җибәргәндә, җитмеш сумны мең бәла белән көчкә тапканны уйласаң, аннан соң ун ел узгач ун мең сум акча табуны хыял, мөмкин булмаган эш дияргә була.

1896 елда кавагыйд белән гавамилне һәм кафия белән "Шәрхе мулла Җами"не чыгарып, фәкать әнмүзәҗне татбыйкать белән укыта башладык. Туганым Фәйзи әфәнде, гарәбият шәкертләренә, хисап белән кавагыйде төркия дә укыта башлады. 1897 елда "Ногман", "Мирсәед", "Хәяли"не чыгарып, төрки иншасы вә җәгърафия дәресләрен керттек. Шәкертләрдә рух күтәрелүе, фикер ачылуы бик ачык күренә башлады. 1898 елда "тәлвих" белән "исагуҗины" чыгарып, татарча мантыйк, белән кавагыйде фарсияне керттек. 1899 елда әнмүзәҗне чыгарып, төрекчә татбыйкатьне, гарәп нәхүен укыта башладык һәм һәндәсә белән әхлак та керттек. 1900 елда "Гайнел-гыйлем" белән тариканы чыгарып, фараиз белән мөдафәгане керттек һәм көн саен дүртәр дәрес биреп (иске мәдрәсәләрдә бер

дәрестән артык юк ул) шәкертләрне тырышырга гадәтләндерә башладык. Шәкертләр күзгә күренеп алга бара башладылар. Безнең дә шатлыгыбыз артты, тырышлык вә гайрәтебезне тагын да артыграк, тагын да куәтлерәк кылырга башладык. Шушы 1900 елда гарәбият өчен менә бу түбәндәге програмны ясадык:

| Дәрес исемнәре | 1 сыйн. | 2 сыйн. | 3 сыйн. | 4 сыйн. | 5 сыйн. | 6 сыйн |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Гарәпчә | 9 | 21 | 21 | 6 | 4 | |
| Фикъһ | 3 | 3 | 3 | 2 | 2 | 2 |
| Төрекчә кәвагыйд | 6 | 3 | | | | |
| Әхлак | 6 | 3 | | | | |
| Хисап | 3 | 3 | 3 | 2 | 2 | 2 |
| Мантыйк | | | 3 | 2 | 2 | 2 |
| Гакаид | | | | 4 | 2 | 2 |
| Төркичә инша | | | | 2 | 2 | 2 |
| Ысуле фикъһ | | | | 4 | 2 | 2 |
| Һәндәсә | | | | 2 | 2 | 2 |
| Кавагыйде фарсия | | | | 2 | 2 | 2 |
| Тарихе гомуми | | | | | 2 | 2 |
| Мөдафәга | | | | | | 4 |
| Җәгърафия | | | | 1 | 1 | 1 |
| Атнадагы барлык сәгать | 27 | 33 | 30 | 27 | 25 | 23 |

Бубый мәдрәсәсендә үзгәреш бу дәрәҗәгә килеп җитә башлагачтын, бездә угыллары укый торган муллалар бик куркышып әткәйгә шикаятькә килделәр. Ләкин әткәй бик иске вакытларда да дин мәктәпләрендә һәрбер төрле фәннең укылуын, һәм искедән бирле дәрес китапларының заманга муафыйк яңарып, үзгәреп килгәнлеген исбат итеп, аларны сүзсез калдырды. Алар әткәй авызыннан үзләренең киреләренә сөйләнгән хакыйкатьләрдән башка бер сүз дә ишетмәгәчтен, ихтыярсыз җавапсыз калдылар, әткәйнең вафатына кадәр һичберсе аваз чыгармадылар вә балаларын алып китәргә дә батырчылык итмәделәр. Әгәр шул вакытта әткәй сәламат булмаса, алар ихтимал гына түгел, мәгълүм, һәммәсе балаларын мәктәптән алып китәрләр, мәктәп бөтенләй буш калыр, без дә шәкерт булмагач, кемне укытасың, теләр-теләмәс мәктәптән, укытудан ваз кичәргә мәҗбүр булыр идек. Алар әткәйнең вафаты соңында да балаларын алып китәргә теләп-теләп карадылар,

ләкин ул вакытта балалары инде күп нәрсәләр укып фикерләре ачылганлыктан, аталарына бирешмәделәр.

1902 елда "Шәмсия", "Тәлхыйс"не чыгарып, җәбер, хәйванат, нәбатат, хикмәт, кимия, һәйәт кертеп, рөшдия һәм игъдадия өчен түбәндәге програмны ясадык:

| Дәрес исемнәре | 1 сыйн. | 2 сыйн. | 3 сыйн. | 4 сыйн. | 5 сыйн. | 6 сыйн. | 7 сыйн. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Гарәпчә | 6 | 12 | 12 | 6 | 2 | | |
| Фикъһ | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 |
| Әхлак | 4 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | |
| Җәгърафия | 2 | 2 | | | | | |
| Ислам тарихы | 2 | 2 | | | | | |
| Гомуми тарих | | | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 |
| Фарсыча | 2 | 2 | 2 | | | | 2 |
| Кавагыйде төркия | 2 | | | | | | |
| Төркичә инша | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 |
| Хисап | 2 | 2 | 2 | | | | |
| Мантыйк | | | 2 | | | | |
| Гакаид | | | | 2 | 2 | 4 | 4 |
| Ысуле фикъһ | | | | 4 | 4 | 2 | 2 |
| Һәндәсә | | | | 2 | 2 | 2 | 2 |
| Мөдафәга | | | | | 2 | 2 | 2 |
| Җәбер | | | 2 | | 2 | 2 | 2 |
| Ысуле тәгълим | | | | 2 | | | |
| Хәйванат | | | | 2 | 2 | 2 | |
| Нәбатат | | | | | 2 | 2 | |
| Хикмәт | | | | | 2 | 2 | |
| Кимия | | | | | 2 | 2 | |
| Һәйәт | | | | | | 2 | |
| Тәфсир | | | | | | | 2 |
| Хәдис | | | | | | | 2 |
| Атнадагы барлык Сәгать | 24 | 26 | 28 | 28 | 30 | 30 | 24 |

Менә бу програмны әткәй исән вакытта ук, аның күз алдында ясалды вә ул үзе укыткан утызлап китаптан "Мөхтасарел-викая", "Һидая", "Зөбдәтел-әсрар", "Тәүзих"тан гыйбарәт дүрт кенә китап калды. Аның заманында ук без Бубый кызлар мәктәбен дә ислах кылырга керештек. Һәм туганым белән икәүләп, шул кызлар мәктәбенә кайбер дәресләргә дә керә башладык. Әткәй боларның һичберсенә каршы тормады, киресенчә, безне хуплады, безгә рәхмәтләр укыды, догалар кылды, вә шушы максатны, искелеккә каткан вә һәрбер искене, хәтта иске киемгә кадәр, изге санаган муллаларга каршы

булганга яклады. Димәк ки, күренеп тора, мәрхүм әткәй житмеш яшәр, һәм үзе искелеккә каткан фанатик түгел, бәлки һәрбер төрле яңалыкны кабул итүче, бик хөр фикерле бер адәм иде. Менә шул сәбәпле ул сәламәт вакытта безгә каршы һичбер мулла тавыш чыгара алмады. Бәлки безнең өскә, сукырларча иярүче муллалар тарафыннан авыз тулы көферләр, ләгънәтләр ява башлады. Мәрхүм әткәбезнең вафаты соңында, без 1901-02 нче уку елында кызлар мәктәбенең ибтидаиясен, югарыда язылган ирләр ибтидаиясе програмына куйдык, ике сыйныф рөшдия[56] дә рәтләдек. Әткәй дә менә шушы елны жәй көне вафат булды.

Менә шушы әткәй вафат булган елда көз көне, туганым Фәйзи әфәнденең дә указы кайтып, Бубыйга тугызынчы имам булды.

1903 елда, Бубый мәсжиденә рәсми иганә сандыгы куйдырдык. Бу сандыкны Бубыйның иң сүзе үтүчән вә иң яхшы бае Мөхәммәджан хажи алганга, вә без, тәрәккъый тарафдарлары, барыбыз да бер фикердә булганлыктан, Бәдретдин мулладан калган дошманнар, артта "мәсжидне чиркәү иттеләр инде, диеп сөйләп йөрсәләр дә, алда бер сүз дә әйтә алмадылар. Фәкать бер тапкыр бер исерекне котыртып, сандыкны ваттырдылар. Без шунда ук төзәттердек тә, яңадан урынына куйдырдык. Һәрбер жомгада диярлек, бу сандыкка сәдака салуның савабын сөйләү аркасында, халык бу сандыкка бик тиз ияләнде. Ел саен без аннан йөз илле вә ике йөз сумлап акча жыйдык. Русиядә мөселман мәсжидләренә куелган беренче сандык, менә шушы сандыктыр. Шуның өчен тирә-як муллалары бу сандык хакында да, көферләргә охшау бу, хәрам диеп байтак маташтылар.

Без шушы 1903 елда, жәй көне май башында, Бубыйга русча укытырга бер мөгаллим китердек. Без башта тирә-як муллаларыбызның бу эшебезне дә гөнаһ күрерләр диеп уйлаган идек. Ләкин эш без уйлаганча чыкмады. Бу елларда имам булачак шәкертләргә русча белү тиеш булганлыктан, вә шуңа күрә мулла балалары русча укыйбыз диеп төрле жирләрдә әвәрә булып йөрү өстенә бер дә акча чыгарырга риза түгел аталардан, иллеалтмыш сум чыгым тотарга мәжбүр иткәнгә, муллалар балаларын безнең буш укыттыруыбызны сизгәчтен, сөенә-сөенә вә безгә рәхмәтләр әйтә-әйтә, безнең бу эшебезгә ризалык күрсәттеләр. Бәс, без бу жәй, 1904 ел жәй көне дә, шәкертләрне русча укыттырдык, халык инде русча укытуны гөнаһ күрмәй башлады. Без ошбу 1904 ел көз көне, вәкыф хисабыннан русча бер мөгаллим алып, русчаны мәктәпнең програмы эченә кертергә ирештек, вә 1905 елда земстводан бер



# СВИДѢТЕЛЬСТВО.

Предъявительница сего дочь муллы дер. Каратай Самарской губер. Бугульминскаго уезда Зайтуна Харрасовна Фахритдинова на основанiи постановленiя Сарапульскаго училищнаго совѣта отъ 27-го марта и 5-го iюня 1907 года о специальныхъ испытанiяхъ, подвергнись полному испытанiю при Ижбобьинскомъ „медресе" и выдержавъ оное удовлетворительно, удостоен званiя учительницы — мугаллимы татарскаго начальнаго училища.

№ 19

Въ удостовѣренiе чего дано ей это свидѣтельство за надлежащимъ подписомъ и съ приложенiемъ печати Ижбобьинскаго „медресе".

Деревня Ижъ-Бобья Iюля 26 дня 1910 г.

Завѣдывающiе муллы и мударрисы: Г. Бобинскiй

Иж-Бубый мәдрәсәсендә бирелгән шәһадәтнамә.

класслы школ алып, русча мөгаллимнең вазыйфасын земство өстенә йөкләдек. Без менә шулай сабыр вә тотрыклылык аркасында акрын-акрын максатыбызга таба адымлап, шул 1904 елда күз күне менә бу программны ясадык:

| Дәрес исемнәре | 1 сыйн. | 2 сыйн. | 3 сыйн. | 4 сыйн. | 5 сыйн. | 6 сыйн. |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Гарәпчә | 5 | 7 | 6 | | | |
| Җәгърафия | 2 | 2 | | | | |
| Кавагыйде төркия | 2 | | | | | |
| Ислам тарихы | 2 | 2 | | | | |
| Хисап | 2 | 2 | 2 | | | |
| Фикъһ | 2 | 2 | 1 | 1 | 1 | |
| Фарсыча | 2 | 2 | 2 | 1 | | |
| Хөсне хат | 1 | 1 | 1 | | | |
| Коръән мәкам белән | 1 | | | | | |
| Әхлак | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | |
| Русча | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 |
| Төркичә инша | | 2 | 1 | 1 | 1 | 1 |
| Мөдафәга | | | 1 | 1 | 1 | |
| Гомуми тарих | | | 2 | 2 | 2 | 2 |
| Мантыйк | | | 2 | | | |
| Ысуле тәгълим | | | 1 | 1 | 1 | 1 |
| Гакаид | | | | 2 | 2 | 2 |
| Ысуле фикъһ | | | | 2 | 2 | 2 |
| Җәбер | | | | 2 | 2 | |
| Хифзы сыйххәт | | | | 1 | | |
| Кимия | | | | 2 | 2 | 2 |
| Хикмәте табигыя | | | | 2 | 2 | 2 |
| Хәйванат | | | | | 1 | |
| Нәбатат | | | | | 1 | |
| Тәфсир | | | | | | 2 |
| Хәдис | | | | | | 2 |
| Һәйәт вә һәндәсә | | | | 2 | 2 | 2 |
| Табакать | | | | | | 2 |
| Атнадагы дәрес сәгате | 24 | 25 | 24 | 25 | 25 | 26 |

Шушы 1904 ел яз көне әткәй белән абзый хаҗга йөреп кайттылар. Һәм шушы ел җәй көне, Мөхәммәдҗан хаҗи, рөшдия белән игъдадиягә махсус, фәкать укыр өчен (янар өчен түгел), буе егерме дүрт аршин, иңе унсигез аршинлы сигез сыйныфлы бер мәктәп салдырды, парталарын, кара такталарын һәммәсен хәзерләтте.

1905 елда рус вә япон сугышы иде. Уфа губернасы Минзәлә өязендә ел саен гыйнварда бер ярминкә була. Мин менә шушы ярминкәдә халыкны димләп "Собрание ислах кылынсын,

мөфти вә казыйлар халык тарафыннан сайланып куелсын, мәктәпләр һәммәсе собрание карамагында булсын" дигән эчтәлекле өч йөздән артык имза белән гариза бирдек, вә шул гаризаның копиясен тирә-якка таратып, бик күп авыл вә шәһәрләрдән дә бирдердек. Шул гаризаның нәтиҗәсе буларак, шушы елда яз көне, Уфада муллалардан оештырылган рәсми бер җәмгыять[57] ясалды, вә шул җәмгыятькә фикер вә язу белән ярдәм итү өчен берничә зыялы адәмнәребез дә килгән иде. Мин дә бу җәмгыятьтә булдым, вә аны уздырып Истанбулга киттем. Бәйрутта, Шамда[58], Мисыр вә Хиҗазда бер ел йөреп, 1906 елда Бубыйга кайттым. Миннән соң 1905 елда җәй көне булган дәһшәтле янгында Бубый бөтенләй харап булган. Безнең биналарыбыздан һәм кызлар мәктәбеннән бер казык та калмаган иде. Фәкать мәсҗид белән ирләр мәдрәсәсе сәламәт иде. Вә туганым Фәйзи әфәнде хәзерге йортыбыз белән кызлар мәктәбен бик яхшы итеп салдыра башлаган иде.

Хаждан кайттым. Инде халык изге санай торган шушы хаҗилык хәленнән бер файда кылып калырга кирәк. Безнең һәрбер мәсҗидтә һәрбер мулла хотбәне, һичшиксез, гарәпчә укый. Мәхәллә халкы аңласын-аңламасын, анда һичбер мулланың эше юк. Татарча хотбә[59] укучы бер мулла да тапмассың. Минем бу эшкә күптәннән эчем пошып йөридер иде. Ләкин халыктан куркып татарча укыганым юк иде. Менә мин хаждан кайтып керүем белән, иң элекке җомганы татарча хотбә белән укыдым, вә шушы хотбәмдә татарларга укылган һәрбер хотбәнең шәригать буенча бары тик татарча кирәклеген исбат иттем. Бубый халкыннан тавыш чыгарган бер кеше дә булмады. Фәкать әтраф муллалары бөтенләй һөҗүмсез үк калмадылар. Шулай булса да озакламады, болар да басылды. Хәтта бәгъзе бер яшь муллалар үзләре дә татарча хөтбә укырга тотындылар. Менә шулай итеп 1906 елда, мартның 21ендә беренче тапкыр татарча хотбә укылды, бик мөһим бер инкыйлабның башы башланды.

1907 елда Мөхәммәджан хаҗи менә хәзерге буе 42 вә иңе 21 аршинлы зур мәктәпне салдырды. Эчендә бик зур бер зал вә унике сыйныф бар. Иске мәктәпләр һәммәсе шәкертләр торырга булып, монысы укырга билгеләнде. Мөхәммәджан хаҗи ул залны ясаттырмаска да теләгән иде, әмма мин "шәкертләргә җәмәгать белән намаз укырга бик кирәк" диеп үтенгәч, риза булды, ясатты. Ләкин безнең максат бер намаз уку гына түгел, бәлки шәкертләрнең җәмгыятьләре белән театрларына бер урын да хәзерләү иде.

Шушы елда без Бубый кешеләренең зәкятләрен мәктәп файдасына җыярга һәм рөшдия вә игъдадия мөгаллимнәренә

вазыйфа бирергә башладык, һәм шушы елда без кызлар мәктәбенә дә бер классны школ һәм Сарапул земствосыннан 600 сум иганә дә сорап алдык. Бу школ белән иганәне алу хакында безгә, ул вакытта Сарапул земствосында гласный булган, Бубыйның ачык фикерле кешеләреннән Бәдретдин Җәлалетдин углы бик зур ярдәмнәр күрсәтте. Без шушы елда кызлар рөшдиясе өчен менә бу програмны ясадык:

| Дәрес исемнәре | 1 сыйныф | 2 сыйныф | 3 сыйныф |
|---|---|---|---|
| Гарәпчә | 2 | 2 | 2 |
| Әхлак | 1 | 1 | 1 |
| Хисап | 3 | 3 | 4 |
| Төркичә инша | 1 | 1 | 1 |
| Кавагыйдә төркия | 2 | | |
| Төрки имлясы | 1 | | |
| Фарсыча | 1 | 1 | |
| Җәгърафия | 2 | 2 | 2 |
| Гомуми тарих | 2 | 2 | 3 |
| Гыйльме әшья | 3 | 3 | 2 |
| Хифзы сыйххәт | | 1 | 1 |
| Хәйванат | | 1 | 2 |
| Нәбатат | | | 1 |
| Балалар тәрбиясе | | | 1 |
| Идарәи бәйтия | | 1 | |
| Мөдафәга | | | 1 |
| Кул эшләре | | | |
| Русча | 12 | 12 | 12 |
| Атнада дәрес сәгате | 30 | 30 | 33 |

Безнең Бубыйда ирләр мәдрәсәсе күптәннән килгән кебек, кызлар мәктәбе дә әткәйнең Бубыйга имам булган көненнән башланган. Әнкәй[60] бик зур тырышлык белән укытып, хатын-кызларны наданлыктан бераз коткарган, язу-уку белдергән, хәтта кайберләренә бераз фарсыча белән гарәпчә дә өйрәткән иде. Үзенең дә әткәй аркасында фикере хөр булганлыктан, безнең кызлар мәктәбенә керүебезгә вә аны ислах кылуыбызга бер сүз дә әйтмәде, бәлки киресенчә, безнең бу эшләребезне яклады, һәм үзе ул бик карчык вә бик тәкъва булып кара халык тарафыннан гына түгел, бәлки тирә-яктагы бар муллалар тарафыннан да изге саналганнан, без аның бу яклавыннан вә бу игътибарлыгыннан бик зур файда иттек. Белер-белмәс вә шуның өчен каршылык кылучан күп кешене "әнкәй бар эшебезнең өстендә бит, әгәр шәригать буенча дөрес булмаса, ул ирек

бирмәс иде" диеп кенә туктата идек. Менә шул сәбәпле кызлар мәктәбенә русча кертүебез өчен тавышланган кеше бик сизелмәде. Асылда, без үз хисабыбыздан хосусый мөгаллимә яллап, ике-өч елдан бирле җәй көне кызларны русча укыта килгәнгә, халык, кызларын русча укытуга бераз гадәтләнгән дә иде. Шуның белән бергә земстводан иганә алу хакында, тирә-як муллаларыннан байтак кына сүзләр, инкярләр ишетелде. Бигрәк тә шушы 1907 елда ун-унбиш шәкерте безгә күчеп килгән өчен бик нык ачуы кабарган Түнтәр Ишминең ләгънәтләре хисапсыз булды, һәм ул шушы елда кызларга язу өйрәтү хәрам диеп фәтва чыгарды[61], һәм ул фәтваларның, ләгънәтләрнең, аның үз тарафындагы бик күп кешеләргә күп зарары тиде, фәкать безгә генә әсәр итмәде. Шуның белән бергә бу кызлар мәктәбе хакында безнең ишетмәгән һичбер сүз калмады. Кызларның шәкертләр белән урамда тотаклашып йөрүләре, берничә кызның бала табуы, шәкертләр белән кызларның бергә җыелып җырлап-биюләре, без сабак биргәннән соң кызларны берәм-берәм авызларыннан үбеп чыгуыбыз — һәммәсе сөйләнде. Хәтта 1912 елда, ротмистрның шәһадәте буенча, безне гаепләү кәгазендә, абзый белән минем бүлмәмдәге кызлар йоклай торган бүлмәгә бер юл барлыгы да язылган иде. Ләкин кызлар мәктәбе һаман көннән-көн алга китте. Уфадан, Казаннан, Мәскәүдән, Сембердән, Ташкенттан, Сәмәркандтан, Семипалаттан, Төмәннән, Әстерханнан, Каракүлдән[62], Пишпәктән[63], Касыймнан[64], Зайсаннан[65] вә кыскасы Русиянең һәрбер тарафыннан кызлар җыелды, һәм тирә-як муллалары үзләре дә, иң тискәреләренә кадәр кызларын китерделәр, чөнки алар һәрвакыт Бубыйга килеп, сөйләнгән сүзләрнең ялган вә яла икәнлекләрен үз күзләре белән күреп белерләр иде.

Русиядә иң элек ислах кылынган вә иң элек мөгаллимәләр чыгара башлаган кызлар мәктәбе менә шушы Бубый кызлар мәктәбедер. Без үзебез дә бу мәктәптә тәртип күрсәттек, ысул вә системаларны карадык. Һәм көнгә икешәр сабак та бирдек. Ләкин бу мәктәптә тәмам җаннары, тәннәре белән эшләүчеләр һәрбер рәхәтләрен шушы мәктәпнең алга китеше өчен фида кылучылар, безнең ата-анабыз, туганыбыз Мөхлисә Бубый белән абзыйның җәмәгате Нәсимә[66] вә минем җәмәгатем Хөснефатыйма[67] булдылар. Болар өчесе дә кич буенча бездән укый, көн буенча мәктәптә укытырлар, вә күрмәгән кеше бер дә ышанмаслык мәшәкатьләр чигәрләр иде. Болар Русия хатын-кызларын гыйлем вә мәгариф юлына кертү өчен иң начар вә иң кабәхәт сүзләр ишетә-ишетә һәрбер төрле бәла вә авырлыкларны йөкләделәр, вә бер тиен айлыксыз, фәкать милләт

өчен диеп, бик зур адәмнәр кыла торган хезмәт вә тырышлыкларны кылдылар. Болар Бубый кызлар мәктәбе ябылгачтын да тик ятарга разый булмадылар, бәлки Мөхлисә Бубый Тройски шәһәренә барып[68], кызлар мәктәбен анда нигезләде, Хөснефатыйма Бубый минем белән Голҗага килеп, яхшы кызлар мәктәбен монда нигезләде.

Без Бубыйның кызлар мәктәбенә шушы 1907 елда менә бу програмны ясадык:

| Дәрес исемнәре | 1 сыйн. | 2 сыйн. | 3 сыйн. | 4 сыйн. | 5 сыйн. | 6 сыйн. |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Гарәпчә | 3 | 3 | 3 | 3 | 2 | 2 |
| Төркичә инша | 1 | 1 | | | | |
| Кавагыйде төркия | 1 | | | | | |
| Фарсыча | 1 | 1 | 1 | | | |
| Җәгърафия | 2 | 2 | | | | |
| Әхлак | 1 | 1 | 2 | 1 | | |
| Хисап | 4 | 4 | 4 | | | |
| Төрки имлясы | 1 | | | | | |
| Хөсне хат | 1 | 1 | 1 | | | |
| Гыйльме әшья | 3 | 3 | 2 | | | |
| Гомуми тарих | | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 |
| Мантыйк | | | 1 | | | |
| Фикъһ | | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 |
| Мөдафәга | | 1 | 1 | 1 | | |
| Җәбер | | | | 2 | 2 | 1 |
| Ысуле фикъһ | | | | 2 | 2 | |
| Гакаид | | | | 2 | 1 | 1 |
| Хикмәте табигыя | | | | 2 | 2 | 2 |
| Һәндәсә | | | | 2 | 2 | 2 |
| Хәйванат | | | | | 1 | |
| Кимия | | | | | 2 | 2 |
| Бәләгате төркия | | | | | | 1 |
| Һәйәт | | | | | | 2 |
| Нәбатат | | | | | | 1 |
| Табакать | | | | | | 1 |
| Хифзы сыйххәт | | | | | 1 | 1 |
| Русча | 12 | 12 | 12 | 12 | 12 | 12 |
| Атнадагы бар сәгать | 30 | 32 | 30 | 30 | 30 | 31 |

Шушы 1907 елда 24 декабрьдә, мәдрәсә залында зур вә камил бер театр ясалды. Моннан элек тә шәкертләр арасында вак-вак театрлар булгаласа да, болай зур театр булганы юк иде. 7-8 адәмнән оештырылган гармун вә скрипкалар китерелде,

буфетлар ачылды, билетлар сатылды. Бубыйдан гына түгел, бәлки тирә-ягыннан да бик күп адәмнәр килде, һәммәсенең күнеле хуш булды. Театрның узуы шулай бик яхшы узды. Ләкин бу театрда иске муллаларның вә иске тормышның бик күп начарлыклары күрсәтелгәнгә, тирә-як муллалары һәм кайбер карт фикерле Бубый кешеләре, безгә дәһшәтле бер сурәттә һөҗүм иттеләр һәм төрле тарафтан котыртып мәдрәсәне төзетүче вә мәдрәсәнең беренче тоткасы Мөхәммәдҗан хаҗины да безгә ачуландырдылар. Безнең белән аның арасы байтак кына ачылды, бик якын кешеләребез бездән аерылды. Хәтта алар Мөхәммәдҗан хаҗины, безнең өстән гариза бирергә вә мәдрәсәне ябып куярга кадәр котырттылар. Ләкин Мөхәммәдҗан хаҗи бик гакыллы вә бик суык канлы булганлыктан, табигый, бу эшләрне кылмады.

Инде без бу театр мәсьәләсен, бераз элегрәк мәйданга чыгаруыбызны аңладык, ләкин эш узган иде, башлаган бер эшне ерып чыкмаенча хәл юк. Бәс, без җомга саен мөнбәрдән, театрның шәригатьчә дөреслеге, вә уен коралларын уйнау вә тыңлауның хәрам эш түгеллеге хакында төрле дәлилләр вә хәдисләр сөйләй башладык. Һәм Мөхәммәдҗан хаҗины хосусый күреп тә эшне аңлаттык. Ахырында, Мөхәммәдҗан хаҗи, гакыллы кеше, эшне тәмам аңлады, безнең фикергә кушылды.

Менә шулай бу театр мәсьәләсе, безнең башка бик күп җәфа вә хәсрәтләр китергәннән соң, ниһаять сәламәт узып китте. Ләкин комиссар килеп, узганы узды, анысы өчен мин сезне җәфаламаймын, фәкать моннан соң рөхсәтсез уйнай күрмәгез, югыйсә мин протокол язарга мәҗбүр булачакмын, дип, рөхсәтсез театр уйнау мөмкинлеген бикләп куйды. Менә шул рөхсәтсез уйнау мөмкин булмаганлыктан вә безнең рөхсәт сорап хөкүмәт күзенә күренәсебез килмәгәнлектән, аннан соң безнең мәдрәсәдә бер театр да уйналмады, фәкать атна саен, бер атнада гыйльми әңгәмәләр булды, вә берсендә әдәбият вә музыка кичәләре ясалды.

Менә шушы театр мәсьәләсе, безне никадәр җәфаласа да, бөтенләй файдасыз булмады. Безнең тирә-як мөселманнары арасында, театр вә уен кораллары бәхәсе кузгалды. Кайсылары дөреслек вә кайсылары хөрмәт тарафына китте, вә ниһаять, боларның шәригатьчә хәрам түгеллеге бик күп хәдисләр белән исбат кылынды. Шул кадәр ки, бүгенгә кадәр, бөтен тирәягыбыз уен коралларын хәрам диеп беләләр иде. Бу вакыйгадан соң аны хәрам диюче бер кеше дә калмады.

1908 елда мирза Гомәр Сәлман углы Янкаевтән Бубый мәктәбенең вәкыфенә вә ун елда түләп бетерү шарты белән, 22000 сумга, утызы урман, калганы болын, 225 дисәтинә җир

сатып алдык, 25 гыйнварда, нотариуска барып язылыштык. Бу җирдән ел саен мең сум файда килә. Бу җирне шушы бәһагә, ярты акчасын хәзер биреп, яртысын ике ел эчендә түләп бетерү шарты белән алучылар кыстап йөри торып, безгә көткән өчен һичбер процент алмаенча, бу озын вакытка бирүе, бары тик Бубый мәктәбенә һәм милләтебезгә ихлас вә мәхәббәтеннән иде. Менә шул сәбәпле ул, үзләрендә калган йөз илле дисәтинә җирен, 70 дисәтинәсе урман һәм елында 2000 сум файда китерә торган дүрт ташлы тегермәнен, вә бөтен сарайларын, каралтыларын гомерлеккә үзе, хатыны вә хатынының анасы файдалану шарты белән, Бубый мәктәбенә вәкыф кылды. Бу вәкыфны шәригатькә туры китереп, шаһитләр белән үз арабызда яздырган кебек, шул 1908 елда, 25 гыйнварда Сарапулга барып, нотариуска да яздырды, вә язуларның икесенә дә, үзе дә, хатыны да, вә хатынының анасы да имза кылды. Ләкин бу вәкыфне Мөхәммәдьяр мөфти расламады, чөнки бу җирләр Гомәр мирза белән әлеге хатыннарның вафаты соңында башка варислар юк иде, Мөхәммәдьяр мөфтинең угылларына тиячәк иде.

Гомәр мирза Казан тарафында руслар көчләп чукындыра башлагачтын, бөтен җирләрен ташлап, башкорт арасына күчкән, Уфага якын Каргалы[69] дигән авылга барып җирләшкән Янкаев фамилиясеннән. Кадетский корпус бетереп, офицер булган, Ташкент вә Бохара якларында күп еллар хезмәт иткән, аннан соң бераз Уфада торып, ниһаять, Алабуга өязе Мордыбый[70] авылына тоташ үз җирендә торучы Хәдичә бикәне никахлаган, вә хезмәтеннән китеп, шушы хатыны җирендә тора башлаган, вә бик күп бурычлар һәм дә начар вәкилләрнең хыянәтләре сәбәпле сатылырга җиткән бу җирен сатылудан коткарып, үз гомерендә 10-15 мең тәңкә сумма ясарга да ирешкән. Менә без вәкыф алган һәм Гомәр мирза тарафыннан Бубый мәктәбенә вәкыф ясалган җир, Бубыйга 16 чакрым ераклыкта, Иж суы кырында, шушы Хәдичә бикәгә, атасы Йосыф мирза Ягъкуб углы Юнысовтан мирас калган җирдер. Болар өчесе, ягъни Гомәр мирза, Хәдичә бикә, бикәнең анасы Шәрифә бикә Мөхәммәдгәрәй кызы Солтанова, 1909 елда хаҗга йөреп кайттылар. Гомәр мирза хаҗда да буш йөрмәде, бәлки Мәдинәдә саклаучы пашаларны, мәчет картларын күреп, Мәдинә мәчете эчендә иганә сандыгы куярга риза итте, һәм үз кесәсеннән бер тимер сандык алып, беренче тапкыр буларак Мәдинә мәчетендә иганә сандыгы ачтырды. Бу сандыкның кереме ышанычлы бер комиссия аркылы Мәдинәдә булган мәктәпләр һәм шәкертләргә сарыф кылыначак иде. Ләкин бу

сандык бик аз дәвам кылды, шәригать "сакчыларының" шайтанлыклары белән ябылды, бетте.

Бичара мирза Гомәр әфәнде хаждан кайткач озак тормады, бәлки шушы 1909 елда 12 ноябрьдә мәңгелек дөньяга китте. Бубыйның бар мөгаллимнәре һәм шәкертләре, аны ихтирам итеп, җеназасында катнаштылар. Мәрхүм Аллаһының рәхмәтендә булсын. Тормышында һәрвакыт милләт өчен кайгырды, безнең иң ышанычлы киңәшчебез шул иде, үз тормышында милләтебезгә файдалы максатларының бик күбесенә иреште. Ләкин бик зур бер максатыннан мәхрүм калды. Бар акчасын банкка салып, шуның кеременнән, милләтебезгә хезмәт итәчәк милләт балаларын укыту вә тәрбияләү иде, монысы булмады. Вафатыннан алты көн элек хәлен сорарга барган идем, "Аллаһы биреп сәламәтләнсәм, акчаларымны да тизрәк рәтләр идем" дигән иде. Ләкин сәламәтләнмәде, шушы хакта хафалана-хафалана дөньядан китте, Бубый мәдрәсәсе дә ябылды, аның үзе ясаган вәкыфе дә шул көенчә калды, җимерелде, без сатып алган җиргә дә вәкыфтән акча түләргә мөмкин булмады, шуңар күрә без ул җирне, вәкыфтән түләнгән микъдар акчасын тиешле урынына тапшырдык та, үзебезгә калдырдык.

1908 елда, элек Оренбургта "Хөсәения" мәдрәсәсендә[71] мөгаллимлек кылган Фәйзулла Мөхәммәд[72] әфәнде белән Габдулла Фәхри[73] әфәнде, андагы мөдирләрнең юньсезлегенә чыдай алмаенча безнең Бубый мәдрәсәсенә күчеп килделәр. Алар артыннан һәм "Хөсәения" мәдрәсәсенең иң аңлы 35-40 шәкерте[74] дә күчеп килде. һәм шушы елда без, ул вакытта Сарапул земствосында гласный булган Бәдретдин әфәнде Җәлалетдиневнең тырышлыгы аркасында, Бубый мәдрәсәсенең эченә ике класслы русча школ сорап алырга да ирештек. Фәйзулла әфәнде тарих, җәгърафия вә төрки әдәбиятында, Габдулла әфәнде математикада бу вакыт безнең Русия мөгаллимнәре арасында беренче булганлыкларыннан, боларның килүе белән бер, вә икенчеләй ике класслы русча школ, безнең мәктәпнең рухын тагын да күтәрә төште. Без инде барыбыз, русча өч мөгаллим белән унөч мөгаллим булдык, вә бергәләшеп менә бу программны ясадык:

| Дәрес исемнәре | 1 с. | 2 с. | 3 с. | 4 с. | 5 с. | 6 с. | 7 с. | 8 с. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Гарәпчә һәм әдәбияты | 4 | 4 | 4 | 3 | 2 | 2 | 2 | 2 |
| Төркичә инша | 1 | 1 | | | | | | |
| Төрекчә һәм әдәбияты | 1 | 1 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 1 |
| Җәгърафия | 2 | 2 | 2 | | | | | |

| Дәрес исемнәре | 1 с. | 2 с. | 3 с. | 4 с. | 5 с. | 6 с. | 7 с. | 8 с. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Хисап | 3 | 3 | 3 | | | | | |
| Хөсне хат | 1 | 1 | | | | | | |
| Гыйльме әшья | 2 | 2 | 2 | | | | | |
| Рәсем | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | | | |
| Ислам тарихы | 2 | 2 | 2 | 2 | | | | |
| Фикъһ | | | 1 | 1 | 2 | 2 | | |
| Мөдафәга | | | 1 | 1 | | | | |
| Хисап назари | | | | 2 | | | | |
| Ысуле тәгълим | | | | 1 | | | | |
| Гакаид | | | | 1 | 1 | 1 | | |
| Һәндәсә | | | | 2 | 2 | 1 | | |
| Карыйдан мәкам | 1 | 1 | | | | | | |
| Әхлак гамәли вә назари | | | | 1 | 1 | 1 | 1 | |
| Җәгърафия гыймрани | | | | 1 | 1 | | | |
| Ысуле фикъһ | | | | | 2 | 2 | | |
| Җәбер | | | | | 2 | 2 | | |
| Хәйванат | | | | | 1 | | | |
| Гомуми тарих | | | | | 2 | 2 | 2 | 2 |
| Нәбатат | | | | | 2 | 2 | 2 | 2 |
| Мантыйк | | | | | | 1 | | |
| Сәйереннәби | | | | | | 1 | | |
| Мөсәлласат | | | | | | | 1 | 1 |
| Хикмәт | | | | | | | 2 | 2 |
| Кимия | | | | | | | 2 | 2 |
| Табакать | | | | | | | 1 | |
| Һәйәт | | | | | | | | 1 |
| Хәдис | | | | | | | 2 | 2 |
| Тәфсир | | | | | | | 2 | 2 |
| Гыйльме сәрвәт | | | | | | | 1 | 1 |
| Хифзы сыйххәт | | | | | | | | 1 |
| Фараиз | | | | | | | | 1 |
| Русча | 12 | 12 | 12 | 12 | 12 | 6 | 6 | 6 |
| Атнадагы дәрес сәгате | 30 | 30 | 30 | 30 | 31 | 24 | 24 | 24 |


Без шушы 1908 елда, беренче тапкыр буларак, май башыннан август башына кадәр өч айлык мөгаллимнәр һәм үз алдына мөгаллимәләр сыйныфы ачтык. Бу ел мөгаллимнәр барысы 20 вә мөгаллимәләр 6 гына булды. 1909 елда мөгаллимнәр 64, вә мөгаллимәләр 42 кеше җыелды.

1910 елда мөгаллимнәр 84 вә мөгаллимәләр 58 булды. Болар педагогикадан башка яңа фәннәр укып та бик файда кылдылар, килгән мөгаллим вә мөгаллимәләр һәммәсе бик риза вә бик шат булып киттеләр. Бәс, бара-бара Бубыйның бу җәйге сый-

ныфы тагын да куәтләнәчәк иде, ләкин 1911 елны без дә тотылдык, мәдрәсә дә ябылды. Шулай да башка җирләрдәге җәйлек мөгаллимнәр курсы, хөкүмәт тарафыннан ябылган вә рөхсәт сораган адәмнәргә рөхсәт бирелмәгән хәлдә, Бубыйныкы, без бер дә рөхсәт сорап азапланмаганлыгыбыздан вә хөкүмәт күзеннән мөмкин кадәр яшеренергә тырышканга, өч җәй тоташ дәвам итте.

Шулай да менә бу, 1909 нчы елларда тынычлык бозылды. Түнтәр Ишми ишаннар "Бубыйда хөкүмәт зарарына укыталар, хәтта җәй көне мөгаллимнәр җыеп та котыртып яталар" диеп донос ясаганга, 1909 елда, майның 15 ендә Сарапулдан исправник, вә августның 10 сында жандармский ротмистр килеп тикшерделәр. Без аларга җыелган мөгаллимнәрне мөгаллимнәр түгел, бәлки үз шәкертләребез, мәкам вә дин гыйлемнәрен өйрәнеп яталар, диеп күрсәттек. Алар "җәен-кышын нинди уку ул?" дип сорауларына, бездә әткәй заманыннан бирле шулай, берсе килә, берсе китә — һичбер вакыт шәкерт өзелгәне юк, безнең татар мәктәпләренең кайсысында булса да, җәй юк, кыш юк, шәкерт кайчан житешсә, шунда укып китә, диеп җавап бирдек. Мәктәпнең рөхсәтен сорауларына каршы без әйттек, монда 130 елдан бирле мәктәп дәвам кылган, башта рөхсәте булганмы-юкмы, безгә мәгълүм түгел. Сорау-җавап 4-5 сәгатькә сузылды, ирләр һәм кызлар мәктәбе барысы да каралды, безнең хакыбызда кайбер кешеләрдән дә соралды. Без земский начальник белән комиссарларны һәрвакыт җайлап торганга, аларның җаваплары да безнең файдага чыкты. Шул сәбәпле безне кулга алу вә мәктәпне ябу, 1911 елга тикле кичекте.

Асылда, без теләсә кайсы рус белән сөйләшеп торганда, үзебезне бик кара вә татарларны руслаштыру тарафдары итеп күрсәткәнгә, һәм ирләр мәктәбе эченә ике класс русча кертүебездән өстен, кызларны татарча укыту да хәрам саналган бер вакытта, кызлар мәктәбенә дә бер класс русча сорап алуыбыздан тирә-як чиновниклары безне, хөкүмәт яклы вә татарларны руслаштыру өчен тырышалар диеп белерләр иде. Менә шуның өчен һәм Бубый мәктәбенең урыны да мөселманнар арасында, ишмиләр тирәсендә түгел, бәлки иң караңгы бер почмакта, чи рус арасында булганлыктан, безнең мәктәпләрнең тикшерелүе һәм ябылуы бераз соңгарак калды.



# СВИДѢТЕЛЬСТВО.

Предъявительница сего Казанской губ. гор. Чистополь Зайтуна Хайдаровна Мавлюдова на основанiи постановленiя Сарапульскаго училищнаго совѣта отъ 27-го марта и 5-го iюня 1907 года о специальныхъ испытанiяхъ, подвергшись полному испытанiю при Ижбобьинскомъ „медресе" и выдержавъ оное удовлетворительно, удостоена званiя учительницы—мугаллимы татарскаго начальнаго училища.

№

Въ удостовѣренiе чего дано ей это свидѣтельство за надлежащимъ подписомъ и съ приложенiемъ печати Ижбобьинскаго „медресе".

Деревня Ижъ-Бобья августа 23 дня 1910 г.

Завѣдывающiй муллы и мударрисъ: А. Бобьинскiй

БОБЬИНСКОЕ МЕДРЕСЕ САРАПУЛЬСК. УѢЗДА

Иж-Бубый мәдрәсәсендә бирелгән шәһадәтнамә.

Без менә шушы 1909 елда, Бубый кызлар мәктәбенең 4 ибтидаи вә 3 рөшдия сыйныфларының програмын менә болай ясадык:

| Дәрес исемнәре | 1 с. | 2 с. | 3 с. | 4 с. | 5 с. | 6 с. | 7 с. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Әлифба, имля вә кыйраәт | 18 | | | | | | |
| Унга кадәр хисап | 4 | | | | | | |
| Телдән мәгълүмат вә тарих | 1 | 2 | | | | | |
| Гыйльме халь | | 3 | 3 | 3 | 2 | 2 | 2 |
| Йөзгә кадәр хисап | | 4 | | | | | |
| Меңгә кадәр хисап | | | 4 | | | | |
| Әгъмале әрбәга тәмам | | | | 4 | | | |
| Тәҗвид | | | 2 | | | | |
| Коръән | 1 | 6 | 4 | 4 | | | |
| Төркичә уку вә имля | | 8 | 8 | 8 | | | |
| Тарихе әнбия вә гасре Сәгадәт | | | 2 | 2 | | | |
| Җәгърафия | | 1 | 1 | 1 | 2 | 2 | 2 |
| Кызларга махсус кыйраәт | | | | | 2 | | |
| Гыйльме әшья | | | | | 2 | 2 | 1 |
| Кәсер | | | | | 3 | 3 | 2 |
| Ислам тарихы | | | | | 2 | 2 | 2 |
| Гарәпчә | | | | | 4 | 4 | 4 |
| Төрекчә, фарсыча | | | | | 2 | 2 | 2 |
| Төркичә инша | | | | | 1 | 1 | 1 |
| Идарәи бәйтия | | | | | | | 1 |
| Хәйванат вә вөҗүде Бәшәр | | | | | | | 1 |
| Русча | | | | | 12 | 12 | 12 |
| Кул эшләре | | | | | 1 | 1 | 1 |
| Бар сәгать | 24 | 24 | 24 | 24 | 31 | 31 | 31 |

Бу ел дүртенче сыйныф оештырылмаганлыктан. мөхтасар һәндәсә, әхлакы нәзари, хифзы сыйххәт вә ысуле тәрбия, тәгълим дәресләре бу програмга кертелмәде, кертергә мөмкинлек булмады.

Ошбу 1909 елда без, гарәп әдәбияты мөгаллимлегенә Әхмәдфаиз әфәнде Сөләйман углы Даутовны[75] алдык. Бу елга кадәр мәктәп идарәсе шәкертләрнең үз кулларында иде. Алар сигез кешедән төзелгән бер комиссия сайлап, шуларның карары белән эш йөрттеләр, вә бик сирәк эшләрдә генә безгә мөрәҗәгать кылырлар иде. Без моннан, вакытлыча файда да күрдек, чөнки 1905, 1906 вә 1907 елларда һәрбер мәдрәсә шәкертләре чуалган вә тавышланган вакытта, безнең

шәкертләргә, идарәдән шикаять кылырга бер дә урын булмады. Ләкин аннан соң бу идарәнең һәлакәте безгә генә түгел, хәтта шәкертләрнең үзләренә дә аңлашылды: мәктәп көтебханәсенең[76] китаплары югалып бетте, җәза вә шелтәгә лаеклы бик күп кешеләр җәзасыз калды... Шуңа күрә ошбу 1909 елда без, идарәне алар кулыннан алып, мөгаллимнәр комитетына тапшырдык, вә якынча өч йөз пунктлы бер устав ясап, бер мөдир, бер тикшерүче, бер назир вә бер мөдир урынбасары сайладык һәм бу ел ирләр мәктәбенә менә бу программны ясадык:

| Дәрес исемнәре | 1 с. | 2 с. | 3 с. | 4 с. | 5 с. | 6 с. | 7 с. | 8 с. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Төрекчә һәм әдәбияты | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 3 | 2 | 2 |
| Гарәпчә һәм әдәбияты | 4 | 4 | 4 | 3 | 2 | 3 | 2 | 2 |
| Ислам тарихы | 2 | 2 | 2 | 2 | | | | |
| Гомуми тарих һәм фәлсәфә | | | | | 2 | 2 | 2 | 2 |
| Хисап | 3 | 4 | 2 | 1 | | | | |
| Җәбәр | | | | | 2 | 2 | | |
| Һәндәсә | | | | | 1 | 2 | 2 | |
| Һәйәт | | | | | | | | 1 |
| Тәфсир | | | | | | | 2 | 2 |
| Хәдис | | | | | | | 2 | 2 |
| Ысуле фикъһ | | | | | | 2 | 1 | 1 |
| Тарихе табигый | | | | | | 1 | 1 | 1 |
| Хикмәте табигыя | | | | | | | 2 | 2 |
| Җәгърафия гомуми вә гыймрани | 2 | 2 | 2 | 1 | 1 | 2 | 1 | |
| Кимия | | | | | | | 2 | 2 |
| Мөссәлласат | | | | | | | 1 | 1 |
| Хифзы сыйххәт | | | | | | | | 1 |
| Әхлак | | | | | | 1 | 1 | 1 |
| Гыйльме сәрват | | | | | | | 1 | 1 |
| Рәсем | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | | |
| Хөсне хат | 1 | 1 | 1 | | | | | 1 |
| Мантыйк | | | | | | 1 | 1 | 1 |
| Фараиз | | | | | | | | 1 |
| Фикъһ | 1 | 1 | 2 | 1 | 1 | 3 | 2 | 2 |
| Гакаид вә мөдафәга | | | 1 | 1 | 1 | 2 | 1 | |
| Гыйльме әшья | 2 | 1 | 1 | | | | | |
| Французча | | | | | | 1 | 1 | 1 |
| Ысуле тәрбия вә тәгълим | | | | | | | 1 | 1 |
| Русча | 12 | 12 | 12 | 18 | 18 | | | |
| Коръән мәкам белән | 2 | 2 | 2 | 2 | 1 | 2 | 2 | 2 |
| Атнадагы дәрес сәгате | 32 | 32 | 32 | 32 | 32 | 28 | 30 | 30 |

1908 елга кадәр без шәкертләрдән уку акчасы алмайдыр идек, менә бу ел шәкертнең байлыгына күрә, иң азы бер сум вә иң күбе 20 сум билгеләдек, якынча 700 сум акча җыелды. 1909 елда иң азы 3 сум вә иң күбе 30 сум билгеләп, якынча 1200 сум җыелды. 1910 елда иң күбен 30 көенчә куеп, иң азын 5 сум иттек, якынча 1500 сум җыелды. 1911 елда иң азын 6 сум вә иң күбен 60 сум билгеләдек. Җыелып беткәндә 2000 сумнан артык җыелачак иде. Ләкин безне тоттылар да, күбесе алынмады, шул көенчә калды. Без менә шушылай, бара-бара мәдрәсәнең үзен-үзе белән идарә кылып булмасмы дигән идек. Югыйсә, байлардан теләнүе бик кыен бит. Алар милләтне укыту вә алга җибәрү хакында сөйләшүне бик яратсалар да, акча турысына килеп җиткәчтен бик чишелеп китмәйләр. Әле яхшы, без үзебез бай, сигез сыйныфлы кызлар мәктәбен дә үз кесәбездән салдырдык. Һәм аны ябылган көненә кадәр үз кесәбездән тәрбия иттек. Бубый мәктәбенең шөһрәте дә зур, үзебез сатучы булганга, байлар һәммәсе белеш, безгә акчабызны үзләре ашамас диеп ышаналар да, һәм без сорасак, бөтенләй бирмәенчә калырга да оялалар. Шуңар күрә, без ни чек итсәк тә иттек, акча тугрысында бик ул кадәр йөдәмәдек.

1909 елда кызлардан да акча ала башладык, ләкин ул акчаны кызлар мәктәбенә түгел, бәлки ирләр мәктәбенә сарыф кылдык. Бубый кызлар мәктәбендә укып чыккан кызлар, өчәр-дүртәр йөз сум бәрабәренә мөгаллимәлеккә алына башлагачтын элек Түнтәр Ишминең сүзе буенча кызларны укыту хәрам диеп йөргән тирә-як муллалары да (мулла кешегә акча өчен җәһәннәмгә керү бернәрсә түгел) үз кызларын безнең мәктәпкә тутыра башладылар. Баласы укыган вакытта мәктәп файдасына бер тиен бирергә разый булмаган вә бер тиен бирмәс өчен әллә ниндәй фәтвалар тапкан муллалар, үз кызларының вазыйфа алуларын бик яраттылар, хәләл санадылар. Кызлар бик күбәйде. Мәскәү, Казан, Уфа, Сембер, Әстерхан, Петропавел, Ташкент, Сәмәрканд, Каракул, Капал[77], Зайсан, Семипалат — һичберсе калмады, һәммәсеннән кызлар килде. Боларның аталары, ир баласын китергән кешеләрнең күбесе кебек, фәкыйрьләр түгел, бәлки байлар иде. Шуңар күрә болардан, 1909 елда 600 сум, 1910 елда 800 сум, 1911 елда 1000 сум акча җыюы бер дә кыен булмады.

1909 елда Бозаулык[78] мулласы Галиәсгар Чыгытай[79] тарафыннан "Исабәт"[80] исемле бер китап нәшер ителде. Бу китапның тарихи кыйммәте юклыктан башка, эче тулы исламга яла һәм әфәндебез галәйһиссәламне ялганчы вә бер дә юкка кан түгүче дигән кеби ялган сүзләр белән тулган иде. Әгәр без бу



N 367

شهادتنامه

| | |
|---|---|
| عقاید | اخلاق |
| علوم دینیه | مکمل حساب |
| تورکچه | علم اشیا |
| عربچه (صرف، نحو، قرائت) | تاریخ عمومی |
| انشاء | جغرافیا |
| منطق | حسن خط |
| فقه | اصول تعلیم و تربیه |
| اصول فقه | حسن حرکت |
| مدافعه | روسچه |

بو شهادتنامه بوبی هیئت معلمه طرفندن تصدیق
و مکتبه مخصوص مهر ایله تأكيد اولندی.

N2 1910

مدیر:
معلم:
معلم:
معلم:
معلم:

Иж-Бубый мәдрәсәсендә бирелгән шәһадәтнамә.

китап хакында бер нәрсә язмасак, дәшмәсәк, ул вакыт бу китапның зарары бөтен яңаларга житәчәк иде. Шуңар күрә без бу китапка каршы Бубый мөгаллимнәре исеменнән протест һәм нәфрәт белдердек[81]. Чыгытай аптырап калды. Әфәндебез галәйһиссәлам хакында хөрмәте камил вә иманы тәмам икәнлеген "Исабәт"тәге сүзләренә каршы булса да, "Йолдыз" газетасында игълан кылды, чөнки соңыннан эшенең яхшылыгын ул үзе дә сизенде. Мәхәллә халкы һөжүм итте, кардәшләре бизде, халык бойкот ясап кибетендә сатуы бетте. Ниһаять, Духовный собраниегә чакырылып, тәүбә итте, вә бөтен "Исабәт"не жыеп яндырырга вәгъдә бирде. Бу хакта, Чыгытайны, 2-3 гакылсыз малайдан башка яклаучы чыкмады. Безнең Бубый мәдрәсәсе бу протесттан бик күп файда күрде. Моннан элек, безнең мәдрәсәне исламга каршы диеп бик күп ялалар бар иде. Безнең менә бу протестыбыз соңында, бу ялаларның куәте бик кимеде. Мәдрәсәнең исламны яклавы бик ачык мәйданга чыкты. Вә бу мәдрәсәгә шөбһә белән карай торган күп искеләрнең мәхәббәтләре жәлеп кылынды. "Исабәт"не яңалыкка каршы корал итеп тотарга сөенә-сөенә ябышкан искеләр, безнең протестыбыз чыккач, аптырап туктап калдылар.

1910 елда, 15 августта Вятка губернаторы безнең мәдрәсәләрне карарга үзе килде. Ул чакта Вяткада губернатор Камышанский иде. Кызлар мәдрәсәсенә кереп, минем кызым Галияне (ул вакытта Галия жидедә генә иде) русча сөйләштерде, бер кызны русча укытып карады. Ирләр мәдрәсәсендә дә бер шәкертне русча сөйләштереп карады. Безнең бәхеткә каршы, бик яхшы русча белә торган бер шәкерт туры килде. Камышанский яшермәде, кызларның һәм ирләрнең русча белүләреннән шатлыгын белдерде. Аңар безне хосусый жирләрдә лекция укыйлар диеп донос ясаганнар булырга кирәк, безгә әйтте: "һичбер жирдә лекция укымагыз, вә шушы мәдрәсәләрегездән башка жирдә укытмагыз, сак булыгыз, хөкүмәткә каршы тәгълиматта була күрмәгез, юкса мин сезне 24 сәгать эчендә Бубыйдан чыгарырмын"... Кыш көне безнең мәдрәсәдә падишаһ сурәте булса да, жәй көне алып куелган иде. Мәдрәсәдә падишаһ сурәтен күрмәгәч, аның бик кәефе китте. Шул вакытта инспектор[82] арага кереп, "яз көне мин килгәндә бар иде" диеп, эшне төзәтте. Шул вакытта Камышанский янына килгән земский начальник, доктор һәм комиссар белән исправник[83] һәммәсе безнең сәясәт белән бер дә маташмаганыбызны сөйләп, безгә бик күп файда ясадылар. Шул сәбәпле ул вакытта безнең мәктәп сәламәт котылып калды.

Шушы 1910 елда Петербургта инспекторлардан, зур кешеләрдән һәм кайбер мәшһүр поплардан бер жәмгыять[84] яса-

лып, татар мәктәпләре хакында фикер алыштылар. Алар иске мәктәпләрне "гыйлем-мәгърифәт бирмәй, гакыл-фикер арттырмай, шуңар күрә болар хөкүмәт өчен бик файдалы" диеп, яңа мәктәпләрне, аеруча Бубый мәктәбен "татарлар арасында гыйлем вә мәгариф тараталар, фикер бирәләр, мәгълүматлы имам вә мөгаллимнәр җитештерәләр" диеп бик ачуландылар, вә аларда фән укыттырмаска, бәлки дин генә укыттырырга, диеп карар бирделәр. Ниһаять, шушыларның, "Казанский телеграф"ның, Малов[85] белән Ишминең тырышулары аркасында 1911 елда Бубый мәктәбе ябылды, сүнде.

Менә шушы 1910 елда, мартның өчесендә, Фәйзулла Мөхәммәд әфәнде хакында полиция тарафыннан тикшерү башланды. Фәйзулла әфәнде, бөтенләй Төркия гражданы булганлыктан, икенчеләй, паспорты тулганлыктан, тизрәк Истанбулга китәргә мәҗбүр булды. Без аны, андай-мондай сорашу була калса диеп, Мөхәммәдҗан хаҗида вәкил диеп нотариуста яздырган идек. Полиция мәктәптә укытмадымы диеп сорай башлагач, һәркем аның укытмаганын, Мөхәммәдҗан хаҗида вәкил булуын сөйләп торды. Шул сәбәптән бу вакытта яңадан сорашу булмады, шул көенчә басылып калды. Алай да бу ел көз көне, Фәйзулла киләме-юкмы дип тагын да соралды. Безне дә жандармнар авыл саен сорап йөри башладылар.

Шушы 1910 елда Мөхәммәдҗан хаҗи, көнбатыш тарафындагы иске рөшдия өстенә тагын бер мәктәп салды. Ибтидаия, рөшдия, игъдадия янынннан чыгарылып, шул яңа мәктәпкә куелды. Көнчыгыш тарафындагы зур бинада, рөшдия белән игъдадия генә калды. Бу бинадагы 12 бүлмәдән сигезендә 8 сыйныф гарәп бүлеге куелып, калганнарыннан берсе назиргә, берсе мөгаллимнәргә, берсе школ әйберенә вә берсе мәктәпнең җәгърафия, хикмәт, кимия әсбаблары белән көтепханә өчен билгеләнде.

Шушы 1910 елда Бубыйның җәйге курсына килгән 84 мөгаллим белән без, ягъни туганым Фәйзи әфәнде, Рәхимҗан Атнабаев, Юныс Вәлидев[86] һәм мин, барыбыз бергә киңәшләшеп, дүрт сыйныф ибтидаия мәктәпләренең програмын менә болай төзедек (шуның кырында, Бубый кызлар рөшдиясенең дүрт сыйныф програмы да бәян кылынды):

| Дәрес исемнәре | ибтидаи | | | | рөшди | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1 с. | 2 с. | 3 с. | 4 с. | 1с. | 2с. | 3 с. | 4 с. |
| Кыйраәте төркия | 6 | 5 | 3 | 3 | | | | |
| Коръәни кәрим | | 4 | 4 | 4 | | | | |
| Гыйльме халь | 2 | 3 | 3 | 3 | 1 | 1 | 1 | 2 |
| Тәҗвид | | | 1 | | | | | |
| Ислам тарихы | | | 2 | 2 | 2 | 2 | 1 | 1 |

| Дәрес исемнәре | ибтидаи | | | | рөшди | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1 с. | 2 с. | 3 с. | 4 с. | 1с. | 2с. | 3 с. | 4 с. |
| Җәгърафия | | | 2 | 2 | 1 | 1 | 1 | |
| Имля | 4 | 2 | 2 | 1 | | | | |
| Төркичә инша | | 1 | 2 | 2 | 1 | 1 | 1 | 1 |
| Төркичәнең кавагыйде вә әдәбияты | | | | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 |
| Хисап | 4 | 5 | 4 | 6 | 2 | 2 | 2 | 2 |
| Рәсем | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 2 |
| Хөсне хат | 4 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 |
| Мәгълүмате шифаһия | 2 | 1 | 1 | 1 | | | | |
| Хифзыс-сыйххәт | | 1 | 1 | 1 | | | | |
| Илаһи вә милли шигырьләр | 1 | 1 | 1 | 1 | | | | |
| Коръән мәкам белән | | | | | 1 | 1 | 1 | 1 |
| Гыйльме әшья | | | | | 2 | 2 | 1 | 1 |
| Гарәпчә | | | | | 4 | 4 | 4 | 4 |
| Идәрәи бәйтия | | | | | | | 1 | 2 |
| Тарихе табигый | | | | | | | 1 | 3 |
| Русча | | | | | 12 | 12 | 12 | |
| Кул эшләре | | | | | 1 | 1 | 1 | 2 |
| Атнадагы бар сәгать | 24 | 25 | 28 | 30 | 31 | 31 | 31 | 34 |

Бу програмны ясаганнан соң, без кызлар рөшдиясенең 4 нче сыйныфына атнада ике сәгать ысуле тәрбия вә тәгълим дәресләре дә керттек. Кызлар рөшдиясе дә безнең бик яхшыланды.

1910 елның рөшди вә игъдади 8 сыйныфлы Бубый мәдрәсәсенең програмы менә бу сурәткә керде:

| Дәрес исемнәре | 1 с. | 2 с. | 3 с. | 4 с. | 5 с. | 6 с. | 7 с. | 8 с. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Тәҗвид вә мәкам белән Коръән | 1 | 1 | 1 | | | | | |
| Тәфсир | | | | | | | 2 | 2 |
| Хәдис | | | | | | | 2 | 2 |
| Ысуле фикъһ | | | | | | 2 | 1 | 1 |
| Фикъһ | | | 1 | 1 | 1 | 2 | 1 | 1 |
| Гарәпчә сарыф вә нәхү һәм әдәбият | 4 | 4 | 4 | 3 | 3 | 4 | 3 | 3 |
| Әдәбияте төркия | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 |
| Ислам тарихы | 2 | 2 | 2 | 1 | 1 | | | |
| Гомуми тарих | | | | | | 2 | 2 | 2 |
| Гакаид вә мөдафәга | | | 1 | 1 | 1 | 2 | | |
| Тарихе табигый | | | | | | 1 | 1 | 1 |
| Җәгърафия | 1 | 2 | 2 | 1 | 1 | 2 | | |

| Дәрес исемнәре | 1 с. | 2 с. | 3 с. | 4 с. | 5 с. | 6 с. | 7 с. | 8 с. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Хикмәте табигыя | | | | | | | 2 | 2 |
| Кимия | | | | | | | 2 | 2 |
| Мөсалласт | | | | | | | 1 | 1 |
| Җәбер | | | | | 2 | 3 | | |
| Һәндәсә | | | | | 1 | 1 | 2 | |
| Һәйәт | | | | | | | | 2 |
| Хисап | 4 | 4 | 2 | 2 | 2 | | | |
| Хифзыс-сыйхxәт | | | | | | | | 1 |
| Гыйльме әхлак | | | | | | 1 | 1 | |
| Гыйльме сәрвәт | | | | | | | 1 | 1 |
| Рәсем | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 |
| Хөсне хат | 1 | 1 | 1 | | | | | |
| Гыйльме әшья | 2 | 1 | 1 | | | | | |
| Французча | | | | | | 1 | 1 | 2 |
| Педагогия вә мантыйк | | | | | | | 2 | 2 |
| Русча | 12 | 12 | 12 | 12 | 12 | | | |
| Атнада бар сәгать | 30 | 30 | 30 | 24 | 28 | 24 | 28 | 28 |

Бу ел Бубый мөгаллимнәр коллективы, сигезенче сыйныф шәкертләре хакында менә бу карарны бирде: 8 нче сыйныф шәкертләре, 1911 елның гыйнвар башыннан алып май башына кадәр, түбәндәге дәресләрдән, теләгән вакытларында имтихан бирерләр:

1. Хисап - язып.
2. Җәбер, һәндәсә вә мөсалләсәт бергә катыштырып берьюлы —язып.
3. Һәйәт — телдән.
4. Тарихе табигый — язып.
5. Хикмәте табигыя — телдән.
6. Тарих вә җәгърафия — язып.
7. Гыйльме сәрвәт — телдән.
8. Тәфсир вә хәдис — телдән.
9. Фикъһ вә ысуле фикъһ — телдән.
10. Гыйльме әхлак — язып.
11. Гарәпчә — язып һәм телдән.
12. Педагогия — телдән.
13. Төрки әдәбияты — язып һәм телдән.
14. Гакаид вә мөдафәга — телдән.
15. Хифзыс-сыйхxәт вә кимия — язып.

Бу ел, Бубый гарәбият шөгъбәсенең 6 нчы сыйныфыннан беренче дәрәҗә мөкяфәт[87] белән бетергән Гаяс әфәнде Максудовны Истанбулга укырга җибәрдек. "Сыйрател-мөстәкыйм" журналы[88] идарәсендәге Хәлим Сабит[89] әфәнде, Истанбулда укытып бирү өчен бездән бер сәләтле шәкерт сораган, вә юл чыгымын без түләгән тәкъдирдә, Төркия мәктәпләренә кичке буларак түләүсез кабул кылдыруны вәгъдә биргән иде. Шуның буенча без үз арабызда киңәшеп, Гаяс әфәндене җибәрдек. Истанбулда мәктәпләр зур булганлыктан, ул барып Солоник[90] игъдадиясенә керде. Имтиханда бик яхшы чыгып, бөтен мөгаллимнәр рәхмәт әйткәннең өстенә, мөдир үзе чакырып та бик илтифат иткән. Вә Гаяс әфәнде 6 нчы сыйныфка керергә имтихан бирә торып, әгәр ул үзе теләсә, 7 нче сыйныф игъдадиягә кабул кылачагын сөйләгән. Ләкин Гаяс әфәнде нигезле укып бару максаты белән, 6 нчы сыйныфта калуны ихтыяр иткән.

Бу вакытта Бубый игъдадиясенең Истанбул игъдадияләре белән тигезрәк баруын, вә Бубый игъдадиясендә 6 нчы сыйныфта яхшы укып барган бер шәкертнең Истанбулда да 7 нче игъдадиягә кабул кылына алачагын бик ачык күрсәтәдер. Асылда моннан элек Бубыйда 5 нче игъдадияне бетергән түбәнле Әюб әфәнде Мирсәлимев тә Истанбулга барып, фәкать 2-3 ай хәзерләнгәннән соң, 6 нчы сыйныф игъдадиягә керә алган иде. Димәк ки, Бубый мәктәбе дин гыйлемнәреннән өстен, Истанбулның яхшы фән мәктәпләре рәтенә кереп җиткән иде.

Ләкин шушы елда, безнең тирәдә яшерен полиция агентлары вә жандармнар да бик күп йөри, һәм Истанбул белән мөнәсәбәтләре бар, хат алышалар, кулга төшермәенчә калмабыз, дигән сүзләре дә ишетелә башлады. Русия эчендәге мондай кара болытлардан, һичбер вакытта рәхмәт яву ихтималы булмаганлыктан, без дә бу сораштырулар артыннан дәһшәтле бозлар, ташлар явачагына иман китергән идек. Шуңар күрә без, Фәйзулла Мөхәммәд әфәндене быел китермәскә карар биргән вә шул эшләрне аңлатып үзенә хат та язган идек. Шул арада, Фәйзулла әфәндене Истанбулда күрдем, шушы көннәрдә Бубыйга барачак, диеп Гаяс әфәнде Максудовтан хат килде. Без бик аптырап киттек. Казаннан аңар "бездән хат булмаенча чыкма" диеп телеграф суктык. Безнең телеграф аңа тапшырылмаган. 9 ноябрьдә Фәйзулла әфәнде килде төште. Инде без аны һичкемгә сиздермәенчә җибәрергә теләгән идек, ләкин булмады, шәкертләр сизделәр, калсын да калсын диеп шаулаша башладылар, хәтта Фәйзулла әфәндегә барып "мөгаллимнәр синнән көнләшә, шуңар күрә сине җибәрергә тырышалар, югыйсә сине җибәрерлек бер сәбәп тә күренмәй, полиция-

фәлән килгәне юк"дип безнең өскә бик зур бер кабахәт йөкләделәр. Ләкин Фәйзулла әфәнде боларга каршы төшеп мөгаллимнәрнең бу эшне ихтыяр итмәячәкләрен вә аларга үзенең тәмам ышанганлыгын сөйләде, һәм шәкертләрнең, син китсәң без дәрес ташлайбыз дигән сүзләренә бик ачуланып кире какты. Фәйзулла әфәнде китте, шәкертләр дә басылып калды.

Соңрак аңлашылды. Бубыйга бер төрек профессор килә диеп, өч жандарм, Әгерҗе белән Бубыйда 5 көн саклаганнар, ләкин алар (кайдан хәбәр алганнардыр) Бубыйга ноябрьнең 4 сенә кадәр килеп җитәчәк дип белгәнгә, инде, ахрысы, килмәде диеп, 6 сында кайтып киткәннәр, вә чынлап та 4 ләрендә килеп җитәчәк Фәйзулла әфәнде, Казанда 4-5 көн юану сәбәпле, ноябрьнең 9 ында гына килеп җиткәнлектән, алар, жандармнар, Фәйзулла әфәндене эләктерүдән мәхрүм калдылар.

1907 елда Сарапул земствосыннан безнең 600 сум иганә алганыбызны ишеткәчтер, Сарапул өязендәге башка муллаларның да нәфесләре чыкты. Иганә сорап земствога гаризалар күбәйде, болар арасында әллә ниндиләре бар иде. Иң шәбе, элек Мәдинәдә дәрвишлек кылган вә хаҗилар йөртә торган пароходта агент вә маклер булып, аннан соң ни максат беләндер, Әгерженең бик иске мулла эзләүче Әхмәд Фәттах углы Тимкин мәхәлләсенә имам, һәм аның мәдрәсәсенә мөдәррислеккә утырган Габдеррәхим мулла Мөхәммәд углы Габденнасыйровның гаризасы. Ул мескен 1913 ел ахырында үзен-үзе суеп дөньядан китте. Менә монда бер кызык булсын диеп, мин шул Габдеррәхим мулланың програмын укучылар игътибарына күрсәтеп үтүне кирәк күрдем.

Сарапул өязе Әгерҗе авылында мөдәррис Габдеррәхим Габденнасыйров[91] белән попечитель Әхмәт Тимкин[92] тарафыннан земский управага бирелгән программа:

Мәктәптә 80 нән 100 гә кадәр бала дүрт ел, мәдрәсәдә 60 тан 80 гә кадәр зур шәкертләр 5 ел, барысы 9 ел укыладыр. Мәктәптә ике мөгаллим вә ике алмаш мөгаллим, барысы дүрт кеше, мәдрәсәдә бер мөдәррис вә ике алмаш мөдәррис — барысы өч кеше укыта. Һәрбер сыйныфта иртән сәгать 9 дан 12 гә кадәр, кич сәгать 1 дән 3 кә кадәр дәрес бирелә.

Мәктәпнең беренче сыйныфында, балалар 6 белән 8 яшь арасында булыр, хәреф өйрәнерләр вә ана телендә басма китаплар укырлар. 2 нче сыйныфында, балалар 8 белән 10 яшь арасында булыр, Коръән, иман вә ислам өйрәтелер, һәм ана телендә әдәп китаплары укытылыр. 3 нче сыйныфта балалар 10 белән 12 яшь арасында булыр, ана телендә һәртөрле гыйбадәт

вә намаз хөкемнәре укытылыр, мөгамәлә укытылыр, бераз хисап, җәгърафия һәм тарих күрсәтелер. 4 нче сыйныфта балалар 12 белән 14 яшь арасында булыр, хисап гыйлеменнән арихметика (?), вакланмалар укылыр, гарәпчә берничә закон китаплары укытылыр, тулы җәгърафия вә тарих күрсәтелер. Бу сыйныфны тәмам кылгач, балалар сатуга яки башка бер эшкә тотынырлар, яки мәдрәсәгә кереп, анда укый башларлар...

Бу программа шул вакытта кыскача газетада да язылган, вә Риза казый[93] үз тарафыннан, "тагын да бер сыйныф арттырылса, пәйгамбәрләр дә чыгар иде", дигән мәгънәле сүзне язган иде. Габдеррәхим мулла бу програмның соңында мөдәррисләр, мөгаллимнәр, урынбасарлар, сторожлар, бәдрәф тазартучылар, балаларга кәгазь-кара, каләм, башка кирәк-яраклар, утын вә кәрәчиннәр өчен 1327 сум чыгым күрсәткән, вә иң ахырда безнең мәдрәсәнең уку вә гыйлеменең нинди дәрәҗәдә икәнен җентекләп беләсегез килсә, Оренбургский духовный собраниедән сведения ала аласыз, мөфти күрсәтер, диеп сүзен тәмамлаган иде...

Сарапул земствосы, мондый гаризалар күбәйгәннән соң, мөселман мәктәпләрен тикшертергә, үз тарафыннан махсус кеше чыгарып йөртте, вә тикшертеп белгәннән соң, "ысуле җәдид белән укыла торган мәктәпләргә иганә бирергә, вә ысуле җәдид белән укылуын белү өчен ул мәктәп мөгаллименең Бубыйдан алган шаһәдәтнамәсе булырга тиеш", дип карар бирде. Вә бу карар, безнең күрсәтүебез вә шул вакыт гласный булган Бәдретдин Җәлалетдин углының тырышлыгы аркасында 1908 елда Сарапулның училищный советы тарафыннан яңартылды һәм расланды, вә шушы елның хисабын язган журналда да нәшер ителде. Менә шул сәбәпле безнең Бубый мәктәбе, ибтидаи мөгаллимнәренә шәһадәтнамә бирә торган бер мәктәп, ягъни рәсми дарелмөгаллимин[94] булып китте. Без шуннан соң русча шәһадәтнамә дә бастырып алдык та, мөгаллимнәр белән мөгаллимәләргә тарата башладык. Безнең бу шәһадәтнамәләр, инспекторлар вә һәрбер хөкүмәт чиновниклары тарафыннан кабул кылынды. Бу шаһәдәтнамә кулында булган һичбер мөгаллим вә мөгаллимәне урынынан җибәрмәделәр. Ләкин моннан соң Бубый мәктәбе озак дәвам кылмады, ябылды. Без дә бары 200 белән 300 арасында шаһәдәтнамә таратырга ирештек.

## Бубый мәдрәсәсенең ябылуы

1910 елда җәй көне, тирә-ягыбызда иң кара вә надан Әгерҗе авылының Әхмәт хаҗи[95] Түнтәр Ишмине кунакка алдырды. Мине дә чакырды. Мәҗлескә мин дә бардым. Мәҗлесләрдә кеше талаштырып ләззәт алучы, Әгерҗенең үзе кара, фикере кара Әфтах мулла, мине Ишми белән талаштырырга теләп ысуле җәдид мәсьәләсен кузгата башлады. Ләкин минем шайтаным аның шайтанын җинде, ничек итсә иттем, мин талашмадым, бәлки Ишми белән аны талаштырдым. Ике этнең талашуы бик кызык бит, мәҗлес бик хозур узды.

Ишми шушы килүендә, безнең өйгә дә кереп чәй эчте. Ул миңа, Әгерҗедә бер аулак бүлмәгә алып кереп, һәм Бубыйда янындагы иптәшен чыгарып, икебез генә калганнан соң әйтте:

— Мәхдүм, сезнең юлыгыз бик яхшы, мәдрәсәгезне бик ыспай алып барасыз, ләкин белер-белмәс кешеләр, сезгә укырга җибәрәбез диеп эздән чыгалар. Шуңар күрә бу юлыгызны куеп торсагыз мәслихәт булыр иде.

Мин гаҗәпсенеп Ишминең йөзенә карадым. Күзе асылынып төшкән, озын, ямьсез, сары кашы астында дүнгән иде. Мин әйттем:

— Әйдә, хәзрәт, мәдрәсәгә бараек, хәзер шәкертләр укып ята, әгәр шәригатькә каршы берәр нәрсә булса, мин хәзер ташларга әзер.

— Юк, — диде Ишми, — беләм мин, беләм, анда бармыймын. Әгәр сез болай куймасагыз, башка төрле куярсыз әле.

Ишми шулай диде дә китте. Мин бу сүздән бер нәрсә дә аңламадым, уйлап та карамадым. Бу шулай узып китте. Шәкертләр җыелды, кыш булды, декабрь җитте. Декабрьнең 25 ендә Минзәләдә ярминкә була. Мин шул ярминкәгә бардым. Казан Садыйк Галикәевнең[96] вәкиле Гыйльман әфәндедә булдым, ул миңа күңелсез бер эш бар әле, диеп, бер язу күрсәтте. Язу Ишминең гомумән ысуле җәдидләр вә бигрәк тә безнең өстебездән Вяткадагы Жандармский управлениегә "алар мәктәпләрендә хөкүмәткә каршы котырталар, Төркия флотына иганә җыялар, Русия мөселманнарын берләштереп, Төркия яклавы астында татар хөкүмәте ясарга теләйләр" диеп доностан гыйбарәт иде. Шул вакытта мин уйладым, Ишми җәй көне Әгерҗегә дә шушының өчен вә кайбер кешеләрне безнең зарарыбызга хәзерләү өчен барган, вә миңа, әгәр сез болай куймасагыз, башка төрле куярсыз әле, дигән сүзе дә шушыннан гыйбарәт икән. Чыннан да безгә хөкем булганнан соң күренде, безнең тарафтагы, безнең зарарга күрсәткән шаһитләрнең, вә

шул җөмләдән Әгерҗе Әхмәд хаҗиның да шәһадәте, шушы доноста язылган сүзләрнең үзеннән гыйбарәт иде.

Менә шушы доносның нәтиҗәсе, мин Минзәләдән кайткач, озак тормады — 1911 елда, гыйнварның 29 ында мәйданга килеп чыкты. Гыйнварның 30 ына каршы төндә, безне һәм мәдрәсәне жандармский ротмистр, исправник, җиде становой пристав вә йөзләп атлы стражник килеп басты. Ләкин моннан 12 сәгать элек безгә боларның киләчәген, Атабай авылының Степан Кривоногов бер стражник аркылы белеп хәбәр биргәнгә, без дә, мөгаллимнәр дә, боларның килүенә хәзерләнгән, җыенган идек. Чынлыкта без үзебез, өч елдан бирле сакланып, җыенып килгән идек. Язган китапларымның, язуларымның һәммәсе читтә иде. Шуңар күрә безгә, болар килгән көндә күп җыештырынырга туры килмәде, фәкать һәрвакыт өстәлемдә булган бик күп адреслар язулы дәфтәремне, бер ышанычлы кешегә илтеп куярга туры килде.

Килеп керделәр, абзыйны үз бүлмәсендә, мине үз бүлмәмдә кулга алдылар, тентү башланды. Минем бүлмәмнән бер браунинг алдылар. Соңра бу браунинг безнең протоколда күренмәде. Димәк, ки, исправникның, яки ротмистрның кесәсендә юкка чыкты. Болар бик бур бит. Безнең көтепханәдә жандармский вахмистрның бик ыспай тышлы, бәләкәй бер "Инҗил"не кесәсенә тыкканын әнкәй үз күзе белән күргән. Минем бүлмәмнән бик күп рәсемнәрне эченә алган бер альбом да алганнар иде, анда кайбер төрек офицерларының рәсемнәре дә бар иде, ләкин мин аны бер җай белән очырдым, алар кулына төшмәде.

Тентү, китаплар карау өч көн дәвам кылды. Без шул арада алар белән җайлаштык, аларны сыйладык, безгә хөрриятебезне бирделәр, теләсәк кайда йөри башладык. Безнең мөгаллимнәрнең күбесе Сарапулга озатылды. Тирә-якта бездә укып чыккан 6-7 яшь мулла да, Бубыйга китерелеп, Сарапулга җибәрелделәр. Безне исә бер җибәрергә, бер җибәрмәскә теләп, озак икеләнделәр. Ахрысы, бездән ришвәт көттеләр. Хәтта ротмистрның бик якыны бер пристав, безнең алдыбызда кесәсеннән биш йөз сумлык бер кәгазь чыгарып, моны ротмистрга Бубыйлар сиңа бирделәр, дисәк, ни әйтер иде микән диеп тә бу ришвәт мәсьәләсен безгә аңлатты. Ләкин ул вакытта, ришвәт бирү бер дә безнең акылга килмәде. Ахырында безне дә тотып Сарапулга озаттылар. Ул пристав соңыннан безнең бер якын кешебезгә әйткән, ротмистрга бүләк бирүне мин аларга аңлатырга тырыштым, аңламадылар, ачык әйтергә аулак туры китереп булмады...

Ни димәк кирәк, тәкъдир шулай икән, без дә эләктек. Галия, безне инде калдылар диеп тыныч кына йокысында, Ситдыйка[97] һәм Фидаи белән Зыяи[98] бер нәрсәдән хәбәрсез караватларында аунамакта иделәр, кич сәгать 11 иде, безнең китәчәкне белеп, ишек алларыбыз да, урамнар да шәкертләр һәм халык белән тулы иде. Балаларыбызның маңгайларыннан үптек тә, үзебездә пансионда торучы егермеләп кызның, мулла абыстай белән Хөснефатыйма һәм Нәсимәнең күз яшьләре арасында чыктык, Сарапулга юнәлдек. Фәкать бер әнкәй үзенүзе тотты вә күзеннән бер тамчы яшь чыгармады.

Иң элек безне полициягә илтеп яптылар. Ачы вә кабахәт бер ис, параша исе безне каршылады. Бер бүлмәнең йозагы шалтырап ачылды. Искедән ат абзары булганлыктан, тәрәзәсе, якты төшәр җире юк, көндез дә китап укырга мөмкин түгел иде. Безне шунда керттеләр, хаҗәт өчен зур бер агач бидрә, ягъни параша куйдылар да, өстән шалтыратып бикләп алдылар. Инде без бүген, ягъни 1911 ел, февральнең икесендә, полициядә, арестта идек. Безнең мөгаллимнәребезнең кайсы төрмәдә вә кайсы шушында, күрше бүлмәдә иделәр.

Фаиз Даутов белән Коддус Габдрахманов[99] жандармский ротмистрга безгә каршы шәһадәт бирделәр[100] дә төрмәдән чыгарылдылар. Шушы ике бәхетсездән башка, милләтенә хыянәт кылган бер мөгаллим вә бер адәм булмады.

Безне дә өч көннән соң төрмәгә озаттылар. Без баштa полициядә ятарга бик разый, төрмәгә барудан бик курыккан идек, ләкин барып кергәч, төрмәнең полициягә караганда бик күп таза, яхшы икәнлеген күрдек. Фәкать полициянең бер яхшы җире бар: аз гына ришвәт белән анда теләсәң нәрсә китерергә мөмкиң, вә теләсәң кем белән күрешергә мөмкин һәм бик ансат. Әмма төрмәдә күбрәк ришвәт белән теләсәң ни китерергә вә теләсәң кем белән хат алышырга мөмкин булса да, теләгән вә ләкин закон рөхсәт итмәгән бер кеше белән күрешергә, сөйләшергә һич тә юл юк. Фәкать төрмә башлыгының, төрмә стенасының тышында, һәм урам кырындагы бакчасын карауны өстебезгә алуыбыз сәбәпле җәй көне, көн буе, шул бакчада булдык, балаларыбыз һәр көн шунда килеп безнең янда йөрделәр, Газизә Шамова да һәрвакыт килде, кызым Галия хат йөртте, вә койма аркылы урамдагы теләсә кем белән сөйләшергә җай табылды. Без төрмә башлыгының өендә, аның үзе белән бергә ашадык, бергә эчтек, хатыннарыбыз килгән вакытта да шунда булдык. Хәтта бервакыт төрмә башлыгы, үзе Вяткага[101] киткәндә, өенә безне хуҗа итеп куйды. Без бер көн абзый белән бакча ягында чәй эчәдер идек. Урам ягыннан ишек кагылды. Ул вакытларда бакчаны карарга килүче бик күп

иде, аларга ишекне ачып без кертә торган идек. Ишекне барып ачтык. Карасак, жандармский ротмистр. Без дә аптырап киттек, ул да безне күреп аптырап калды. Бакчага керде, безнең белән бераз сөйләште. Шушы көтелмәгән очрашуның соңыннан безгә дә, төрмә башлыгына да бик күп зарары тиде, безнең хөрриятне бераз кыса төштеләр, төрмә башлыгына шелтәләр килде. Әгәр бу төрмә башлыгы, Пермьдәге вә өч губернага баш районный жандармский полковник белән бик якын дус булмаса, ротмистр аны бу эше өчен урынында бер минут та торгызмас иде.

Без төрмәгә бардык. Иң элек безне төрмәнең конторына керттеләр. Полициядә безне тентү-фәлән булмаган иде, монда бер нәрсәне куймадылар, аякларга, киемнәргә кадәр салдырып тентеделәр. Шулай булса да бер пәке яшереп алып керә алдым. Безне башта үзебезнең мөгаллимнәр белән бер бүлмәгә яптылар. Икенче көн, ротмистрның әмере белән, безне алар яныннан чыгарып, руслар вә яһүдләрдән торган алты сәяси тоткын янына күчерделәр. Без монда ике ай тордык. Аннан соң төрмә башлыгыннан сорап, абзый белән икебезгә генә махсус бәләкәй бер бүлмәгә күчтек. Без аның борыс вә диварларын, идән вә түшәмнәрен майлы буяу белән буяттык. Икебезгә ике тимер караватт куйдык, өстәл вә урындыклар китерттек һәм һәрбер төрле ашны, үзебез ни теләйбез, шуны төрмәдәге хатыннарны караучы надзирательницаларга кушып әзерләттек. Тормыш һәм ашау-эчү ягыннан кысанкылык бетте, мин әнә шуннан соң рәхәтләнеп укырга, язарга керештем, төрмәдә яткан 22 ай эчендә 6000 биттән артыграк нәрсә яздым, шуның белән гомер узлырдым. Безгә бу мөмкинлекләрне, төрмә башлыгы немец Александр Робертович Гольцман ясады, үзе бер тиен ришвәтсез-нисез ясады. Минем язган язуларымның барысын, теге безгә аш әзерләгән надзирательница Ольга Осиповна йөртте. Бу да бер тиен хаксыз-нисез йөртте. Шуңар күрә без бу ике кешенең изгелекләрен үлгәндә дә онытачак түгел.

Без төрмәгә кереп, аннан чыкканга кадәр безгә иң зур хезмәт иткән кешеләрнең берсе, беренчесе Сарапулда сатучы Хафиз әфәнде Сәймановтыр[102]. Безгә һәр бер кирәкне ул хәзерләде. Безнең һәр бер хат-хәбәр аның аркылы йөрде. Хәтта ростмистр моннан шөбһәләнеп, аны губернаторга җиткерде, 3 ай полициядә ябып торгызды. Ләкин Хафиз әфәнде аннан соң да туктамады, һаман безгә хезмәт итте. Хәтта үзе төрмә бакчасы янына килгәләп безнең белән сөйләшеп тә китте. Юк-бар куркытулардан курыкмас, нык иманлы, чын кеше вә чын мөселман ул. Мөгаллимнәр төрмәдә яткан вакытта, дусишләрдән иганә җыеп алырга ярдәм кылучы, аларның һәрбер

кирәкләрен хәзерләп бирүче дә шул Хафиз әфәнде Сәйманов булды.

Ротмистр безне тотып төрмәгә япканнан бер ай соң тагын Бубыйга барды, халыкны, бигрәк тә Мөхәммәджан хаҗины теләгәнчә куркытты, әнкәйгә "балаларың мәңге төрмәдән чыкмаслар, аларны мин каторга җибәрәм, менә 7000 сум акча бирсәң, бер атна эчендә чыгарам мин аларны" диеп 7000 сум ришвәт алды, ләкин үзе безне чыгармады, акчаны да йотты. Жандармский вахмистр да 300 сум ришвәт алган иде. Төрмәдән чыккач анысын сәер иттек. Судка бирәбез диеп куркытып, аякларыбызга сәҗдә кылдырдык, 300 сумны тәмам түләттек. Безне кулга алганда аждаһа кебек йөргән кешенең, аякларыбыз астында җыланнар кебек бөгәрләнүе, әмма кызык, күңелле булды соң...

Ротмистр бездән озак җавап алмады, һәм озакламады, безнең эшне судебный следовательгә тапшырырга мәҗбүр ителде. Апрель башында бездән, Сарапул судебный следователе белән прокурор җавап алдылар. Май 10 сында Казан судебный палатасының следователе белән прокуроры килде. Бубыйга барып безне тагын тентеделәр, аптырадылар ахрысы, тагы бер нәрсә дә чыкмады. Аннан соң төрмәгә килеп бездән җавап алдылар. 1912 ел гыйнвар 10 сында, шул Казан следователе тагын килде. Бу юлы безнең хактагы тикшерү беткән, вә бу следователь безгә, үз хакыбыздагы тикшерүнең нәтиҗәсен аңлатырга килгән иде. Без Фаиз Даутов белән Коддус Габдрахмановның милләткә дәһшәтле хыянәт кылуларын, иң беренче мәртәбә менә шушы вакытта аңладык. Һәм безне элек Русия мөселманнарын берләштереп Төркия яклавы астында бер падишаһлык ясау ниятендә диеп 102 нче статья[103] белән гаепләгәннәр иде. Бу статьяда иң җиңел җәза каторга. Безгә бу вакытта следователь аңлатты: "Палата Русия мөселманнары арасында ул фикернең юклыгына ышанды, шуңар күрә 102 статья сездән күтәрелде".

Без шушы 11 ай эчендә төрмәдән чыгарга никадәр тырыштык. Өч доктор безне хәстә, төрмә боларны харап итәчәк диеп раслады. 50000 сум залог та бирмәкче булдык. Бу залогның 25 меңен Мөхәммәджан хаҗи, 10 меңен Кукарканың Сәйфуллин, 10 меңен Карманның Фәхретдин әфәнде, 10 меңен Бөре өязенең Шаһингәрәй хәзрәт бирәчәк иделәр. Ләкин безне, җәза күрсен диделәр ахрысы, чыгармадылар. Без хөкемгә кадәр 16 ай җәзаланырга мәҗбүр булдык. Әгәр Беренче Думада сул фирканең хөкемсез җәза булмасын дигән сүзләре кабул кылынган булса, ул вакытта без дә болай хөкемсез җәзаланмас идек. Без төрмәдә хөкемнән соң да 6 ай яттык. Ләкин хөкемнән элек яту, хөкемнән соң ятуга караганда әллә кайда

авыр. Хөкемнән элек ятканда тоткынлык вакытының ахыры мәгълүм түгел, монысы бер, озак сузылудан куркасың, чөнки хөкемсез өчәр-дүртәр ел яткан кешеләр бар, хөкемдә ни булачагын интизар белән хафаланасың, икенче, сине дәһшәтле коллыкта тоталар, синең белән күрешергә аналарыңнан, хатын вә балаларыңнан башка бер кешене дә кертмәйләр. Әмма хөкемнән соң ул кадәр дәһшәтле көтү юк, теләсә кем синең белән күрешергә керә, кайчан котылачагың да мәгълүм. Шулай була торып хөкемнән элек ятуга җәза исемен бирмәсләр, җәза түгел, саклау гына, диләр. Боларның һәммәсен шул гадәләт чиновниклары дигән кешеләр үзләре кылалар һәм гаделлек исеменнән кылалар. Белмәм, бу золымнарның гаделлек белән ул кадәр мөнәсәбәтләре бар микән? Кайбер кешеләр бар, хөкемнән элек 2-8 ел төрмәдә яталар да, хөкем соңында гаепсез күрелеп азат кылыналар. Без төрмәдә ятканда, шушындый 4-5 кешене күрдек. Ихтимал, без аңламый торганбыздыр, боларны гаепсез җәзалау мәдәният вә гадәләт исеменә "муафыйктыр" шул.

Шул вакытта судебный следователь безгә, безнең хактагы следственный материалларны укыды. Зур табаклы кәгазьдә, һәр берсе 250 биттән ким булмас, 12 томнан гыйбарәт иде. Безнең яңа хөкүмәт ясау эшебез Кавказларда, Кырымнарда, Себердә, Ташкентларда, Казан вә Оренбурларда, вә, кыскасы, Русиянең һәрбер тарафында тикшерелеп, шушы кадәр кәгазьләр каралынган иде. Закон буенча судебный следователь безгә, шушыларның һәммәсеннән копия бирергә мәҗбүр икән, үзе сөйләде, ләкин ул безгә мәслихәт бирде, "әгәр, диде, барысыннан да копия алсагыз, язу бик озакка китәр, сезгә хөкем бу ел майга җитешмәс, үзегезгә төрмәдә озак ятарга туры килер, мин сезгә, риза булсагыз, хосусый, үзегезгә бәйле булган җирләрен генә бирәем". Без төрмәдә ятудан бик туйган идек, риза булдык. Безгә шул 12 томнан берсенең яртысы кадәреннән копия бирделәр, мин аны төрмәдә вакытымда ук татарчага тәрҗемә кылдым. Ләкин безгә хөкем ябык ишек эчендә булганлыктан, бу тәрҗемәне бүгенгә кадәр бастырып булган юк әле. Бу 12 томның эчендә, панисламизм[104] хакында Русия эчендә күзгә күренгән мөселманнардан күбесенең җавабы булган кебек, Петербургтагы зур профессорларның да фикерләре бар икән. Кяшки, шуны бервакыт кулга төшереп булса...

## Безгә хөкем

Хөкем көннәре якынлашты. Гаепләү кәгазе безгә бирелде. Без гаепләү кәгазендә өч эш өчен өч пункт белән гаепләнә идек. Мәктәптәге падишаһ сурәтен шәкертләргә мәсхәрәләттергән өчен 103 нче пункт,[105] шәкертләргә хөкүмәткә каршы инандыруда булган өчен һәм Төркия флотына иганә җыйдырган өчен 128 нче пункт, минем цензурда калган тугызынчы "Хакыйкать"ем өчен 132 нче пункт[106].

Озакламады, безгә хөкем 26 майда булачак диеп тәгаен дә кылынды. Адвокатыбыз Сарапулда Егоров[107], Казанда Бать[108] иде. Бу икесенең, аеруча Батьның безгә, палаттагы эшләребезне вакытында белеп торуыбыз өчен бик күп файдалары тиде. Хөкем вакытында безне яклауга, Ибраһим Әхтәмев[109] белән мәшһүр Маклаков[110] та килмәкче булдылар.

27 майда төрмәгә безнең белән сөйләшергә Маклаков белән Бать килделәр. 103 нче пункт белән 128 пунктның уалачагын, ләкин 132 нче пунктның калачагын, бигрәк тә Казаннан килгән палат әгъзалары күрсәтмә алган, ягъни сезнең зарарга хөкем кылмаенча калмаска боерыклы булганлыкларыннан, безгә, һичшиксез, ни булса да бер хөкем булачагын сөйләделәр. Судьяларга каршы бер сүзебез булса, аны турыдан-туры үзебез әйтмәскә, бәлки алар — адвокатлар аркылы әйтергә куштылар. Һәм Маклаков минем суд кулына төшкән бер фикерләрем хакында әйтте: "Ничек Сез ул кадәр ачы язасыз? Мин суд каршысында христианлыкка каршы шулкадәр ачы бер нәрсәне укудан чирканам..." Ләкин Маклаковка бу китапны сөйләргә хаҗәт төшмәде. Чөнки ни сәбәпледер, прокурор безне гаепләгәндә бу китапны теленә алмады.

28 майда иртән торып юындык, киендек. Урамда төрмә капкасы алдында татарлар кайный башлады. Безне алырга конвой — өч солдат килде. Шулар арасында, сак астында без инде судка юнәлдек. Урамның ике тарафы туп-тулы безне күрергә җыелган халык иде. Юл буенча безнең артыбыздан ияргән татарлар судка кадәр бардылар, аның каршысындагы зур мәйданда туктадылар. Мәйдан халык белән тулды.

Безне хөкем бүлмәсенә кертеп, гаепләнүчеләр урынына утырттылар. Судьялар керде, аяк өсте каршыладык. Болар барысы җиде кеше иде. Дүртесе Казаннан җибәрелгән 70-80 яшәр картлар. Бать боларны иң каралар, юри сайлап җибәрделәр, диде. Өчесе Сарапулдан кергән городской голова, земский управаның председателе, бер старшина. Ягъни бу өчесе безнең тарафта булсалар да, тегеләр дүрт кеше. Аларны җиңәргә мөмкин түгел иде. Һәм шулай булды да, бу өчәве без-

не гаепсез диделәр, тегеләр дүртесе гаепле диеп, абзыйга ике ай, миңа алты ай төрмә бирделәр. Бать әйткәнчә, үзләренә кушылып җибәрелгән сүзне тәмам иттеләр. Юкса ул картларның, шаһитләрнең шәһадәтен тыңлауда бер хәбәрләре дә булмады, хәтта икесе шәһадәт алган вакытта, урындыкка җайланып гырлай-гырлай йокладылар.

Палат башланды, шаһитләрне ант иттерә башладылар. Иң элек рус шаһитләрне бер поп кереп, ант иттерде. Фәкать шаһитләр арасыннан ротмистр белән Ананьин дигән поп, без электән үк антлы диеп ант итмәделәр. Поп русларны аяк өсте бик тиз генә ант иттерде дә чыгарды. Әмма Сарапулның Хөсәен мулла мөселман шаһитләрнең барысын аяк астына тезләндерде. Ишми дә озын чапаны белән тузаннарны себерә-себерә тезләнде. Үзе антлы булса да, кеше рәтеннән ант итте. Хокукын белмәгән абруйсыз адәм һәрвакытта шулай була шул. Хөсәен мулла поп кебек тиз генә ант иттермәде, бәлки иң элек бер нотык сөйләмәкче булды. "Җәмәгать, — диде, Аллаһы тәгалә, Коръәни Кәримдә, хөкүмәткә, падишаһка баш иярргә, карышмаска кушкан. Һәм хәзрәти рәсүл үзе дә кара кол булса да, әмирегезгә баш салыгыз дигән. Сез менә шуларны игътибарга алып мөселман диеп якламагыз... "

Ләкин Хөсәен мулла сүзен тәмам кыла алмады, председатель ачуланып кычкырды:

— Монда Сезне чакырганнар ант иттеррергә, халык котыртырга түгел, тизрәк ант иттерегез дә чыгарыгыз.

Хөсәен мулла элек тә кызыл кеше, инде пешергән кыскыч кебек булды, калтыранды, ниһаять, шаһитләрне Коръән үптереп ант иттерде.

Хөсәен мулла бу эшнең башыннан бирле, астыртын безнең зарарга йөргән кешеләрнең иң беренчесе. Электән үк ул, миңа мәдрәсәләрне карарга куштылар диеп, Бубый мәдрәсәсен тикшереп йөрде. Ишминең аңар "ахрысы, без Бубыйлар эшен юккарак башладык, бик зурга китте", дигән бер хатын Әгерҗенең Хәбибрахман мулла үзе күреп сөйләде. Һәм судтан соң Ишминең аңар "аз белән котылдылар, яңадан указлары бирелмәсә ярар иде, мелла Хөсәен" дигәчтен, Хөсәеннең "юк тәкъсир, хафаланмагыз, аларның указлары, мәдрәсәләре кайтарылу ихтималы юк" диеп җавап биргәнен, Кичкутан авылының Габдулла мулла үз колагы белән ишетеп миңа сөйләде. Кыскасы, үзе шпион ул. Хатыны да шпионлык кыла. Котдус Габдрахманов төрмәдә вакытта, аның анасына, үземә 50 тәңкә бирсәгез, улгылыгызны мин ротмистрга әйтеп төрмәдән чыгартам дип, шушы Хөсәен мулла хатыны сөйләгән.

Шаһитләрнең һәммәсен чыгардылар, ялгыз ротмистр калды, судьялар алдында торды, аннан җавап алырга керештеләр. Председатель сорады:

— Сез Бубыйлар эше хакында ни беләсез?

Ротмистр:

— Мин Малмыж мулласы Мансуровны кулга алдым. Бу да Бубыйлар белән бер фикердә, бер юлда. Болар арасында панисламизм фикере барлыгы миңа катгый мәгълүм. Мансуров никадәр судтан котылса да, ул да гаепле иде.

Председатель ротмистрның сүзен бүлеп:

— Сез Бубыйлар хакында гына сөйләгез!

Ротмистр бер дә көтмәгәндә сүзе бүленүеннән аптырап:

— Бубыйлар... һм... Бубыйлар... әйе... Бубыйлар панисламизм тарафдары... алар бу фикерне ирләргә генә түгел, хәтта хатын-кызлар арысына да тараталар. Мин тентүгә барган вакытта, читтән килгән кызлар белән аларның өйләре туп-тулы иде.

Председатель ачуланып кычкырды:

— Сезгә әйтәм, эшкә бәйле булмаган сүзләрне сөйләмәгез! Сез Бубыйларның эше турында гына сөйләгез!.. Менә падишаһ сурәте хакында ни беләсез? Бозылган идеме?

Ротмистр калтырай башлады, күзен түшәмгә текәде, җансыз кебек бер биш минут торганнан соң мырылдады:

— Әйе, - диде, падишаһ сурәте бозылган иде.

Председатель:

— Сез аны күрдегезме?

Ротмистр:

— Юк та, ләкин минем ышанычлы хәбәрчеләрем хәбәр бирде. Бать председательдән рөхсәт сораганнан соң, ротмистрга:

— Сезнең ышанычлы хәбәрчеләрем дигәнегез, Аппаков[111] белән Ардашевтыр[112] инде. Ярый, анысында зарар юк. Ләкин рәсем, сез барудан күпме элек бозылган иде?

Ротмистр:

— Ике ай элек бозылган иде. Мин аның бозылганын декабрь башларында ишеттем.

Бать:

— Алай булгач, сез нигә аны шул вакытта алып китмәдегез?

Ротмистр:

— Мин аны Жандармский управлениегә хәбәр бирдем дә, вакыт күп узды. Бать:

— Ләкин законча сезгә бит Жандармский управлениегә хәбәр бирү тиеш түгел, бәлки мондагы прокурорга хәбәр итәргә дә, барып алырга кирәк иде. Сезгә ич ансат юл: хәбәрчеләрегез хәбәр биргәч тә, барасыз да, рәсемне кулга

төшерәсез, хәтта үзегез барырга да хаҗәт юк, бер жандармский җибәрдегезме, җитте, ул барыр да рәсемне кулга алыр иде. Ротмистр калтыранып беркавем торганнан соң:

— Алай итсәм, минем эшемә көйсез киләдер иде.

Бать:

— Ничек көйсез килә? Хәлбуки, аны шул бозык көенчә алып китү бик мөһим иде: беренчеләй, Сезнең вазифагыз бит ул. Икенчеләй, бу хакта бик нык тырышучы кеше Сез күренәсез, алай булгач мондай бер форсатны кулдан җибәрү сезгә бер дә килешмәй бит.

Ротмистр кызарынды, бер аягыннан икенче аягына алмашты, дәшмәде. Бать та, сүзем бетте, диде, туктады. Председатель ротмистрдан сорады:

— Тагын ниләр беләсез?

Ротмистр:

— Бубыйларның шаһитләре һәммәсе ялган, аларның барысын да Бубыйлар яллап китерделәр. Алар миңа да 5000 тәңкә биргәннәр иде. Бубый халкыннан дөрес шәһадәт бирүче, Аппаков белән углы[113] гына.

Председатель тагын ачуланып:

— Сездән шаһитләрнең ялганлыгын сораган кеше юк.

Ротмистр озак аптырап торганнан соң:

— Бубый халкы барысы бер киңәштә. Алар Ардашевны рус булган өчен Бубыйдан кудылар. Аппаковка бойкот ясадылар. Ишмөхәммәд мулланы[114] үтерәбез диеп, исемсез хатлар яздырдылар, мин аны жандармнар җибәреп, ике ай саклатырга мәҗбүр булдым. Ишмөхәммәд мулла яхшы кеше ул.

Председательнең ачуы тагын кабара төшеп:

— Аңларсызмы? Сезгә бит тиешсез сүз белән маташма, диләр. Ротмистр янып, тирләп озак дәшми торганның соңында:

— Алар төрек мөгаллим Фәйзулланы да китерделәр.

Председатель ачу белән:

— Башка бирердәй хәбәрләрегез булмаса, утырыгыз. Ротмистр утырды. Шаһит Аппаков керде. Председатель:

— Сез Бубыйлар хакында ни беләсез? Падишаһ сурәте бозылган идеме?

Аппаков:

— Бозылган иде.

Председатель:

— Үзегез күрдегезме?

Аппаков:

— Юк. Углым әйтте.

Председатель:

— Тентүдән күпме элек иде?

Аппаков:

— Унбиш көн чамасы элек иде.

Председатель:

— Муллаларыгыз мәсҗидтә падишаһка дога кылалар идеме?

Аппаков:

— Ун елдан бирле аларның падишаһка дога кылганнары юк. Алар падишаһка каршы. Аларның шәкертләре урамда "Марсельеза"[115] җырлап йөрделәр. Мин аны шул вакытта тиешле урынына да белдердем, ләкин губернатор, нигәдер эшне бөтенләй басып куйды. Нигәдер, анысы миңа мәгълүм түгел...

Председатель аның сүзен бүлдереп:

— Аны тикшерү синең эшең түгел!. Аппаков калтыранып:

— Ваше высокоблагородие. Алар бит миңа бойкот та ясаттылар, минем бәләкәй булса да бер кибетем бар иде, шуны бетерттеләр. Минем Бубыйда түзәр хәлем калмады инде. Бар Бубый халкы ялганчы, барысы падишаһка каршы...

Председательнең ачуы кабара төшеп:

— Син андай юк сүзләрне сөйләп гомер уздырма! Башка хәбәрең булмаса бар, утыр!

Аннан соң Ардашев керде.

Председатель сорады:

— Сез Бубыйлар хакында ниләр беләсез?

Ардашев:

— Алар мәдрәсәләрендә төрек мөгаллиме китереп укыттырдылар. Алар һәм төрек флотына акча җыйдылар, мин акча җыеп йөргән өч төрекне Бубый мәдрәсәсендә үз күзем белән күрдем. һәм бервакыт мәдрәсәдәге бер җәмгыятьтә, шәкертләр Русия падишаһысын мөртәд, Төркия падишаһысын паша диделәр. Алар һәрвакыт хөкүмәткә каршы сүз сөйләйләр, хөкүмәткә каршы фикер тараталар.

Председатель:

— Сез татарча яхшы беләсезмени?

Ардашев:

— Үз телем кебек беләм, Бубыйда туып үстем.

Председатель:

— Ул сүзләр гаепле сүзләр мени? Ардашев:

— Мөртәд — мәлгунь дигән сүз. Паша зурлап әйтелә торган сүз.

Әхтәмев председательдән рөхсәт сорап:

— Мөртәд – мәлгунь дигән сүз түгел, бәлки диннән чыккан дигән сүз, безнең Русия падишаһысына туры килмәй ул. Паша – генерал дигән сүз, солтанны алай диеп әйтү, аны мактау булмай, бәлки кимсетү, хурлау була.

Безнең китапларны русчага тәрҗемә кылган бурят Катанов[116] белән гарәп Җузе[117], без русча тәрҗемәнең дөреслегенә каршы килгән вакытта җавап өчен, шунда судта катнаша иделәр. Председатель мөртәд белән пашаның мәгънәсен алардан сорады. Алар да Әхтәмевнең сүзенә муафыйк җавап бирделәр. Ардашев утырды. Аппаковның углы керде. Председатель сорады:

— Падишаһ сурәтенең бозылганын күрдегезме?

— Күрдем, бозылган иде. Авызы ертылган, күзе тишелгән иде. Председатель:

— Тентүдән күпме элек иде?

Аппаков:

— Ике атна элек иде.

Бать председательдән рөхсәт сорап:

— Падишаһ сурәте диварга сөялеп куелган идеме, яки утыртылган идеме?

Аппаков баласы:

— Сөялеп куелган иде. Бать:

— Ни белән ертылган иде? Аппаков баласы:

— Карандаш белән ертылган иде. Бать:

— Диварга сөялеп торган бер кәгазьне карандаш белән ерту мөмкинме соң? (Диварга бер кәгазь куеп карандаш белән төртеп) Менә күрәсең бит, ертылмай бит.

Аппаков баласы:

— Авызы карандаш белән ергаланган гына иде. Күзе тишелгән иде. Бать:

— Димәк ки, авызы ертылмаган, ләкин күзе ничек тишелде микән? (Диварга бер кәгазь кисәге куеп карандаш белән төртеп) Менә карале, күрәсеңме, тишелмәй бит.

Аппаков баласы:

— Белмәм, тишелгән иде.

Председатель бу малайны утыртты. Казанның мәшһүр әдәпсез Мөхәммәдҗан Хафиз[118] керде. Председатель аннан сорады:

— Сез Бубыйлар хакында ни беләсез? Мөхәммәдҗан Хафиз:

— Мин шуны беләм, Габдулла Бубый Мәкәрҗәдә булган мөселман җәмгыятендә хөкүмәткә каршы нотык сөйләде.

Председатель:

— Ничек диеп сөйләде?

Мөхәммәдҗан Хафиз:

— Кан белән җан белән тырышырга кирәк диде.

— Ни өчен тырышырга кирәк диде?

Мөхәммәдҗан Хафиз:

— Ирешер өчен диде, ирешер өчен.

— Нәрсәгә ирешер өчен диде?

— Нәрсәгәдер, ләкин ирешер өчен диде. Бик хәтәр сөйләде ул. Бик начар сүзләр сөйләде ул. Кан белән җан белән тырышырга кирәк диде. Алар бик яман, бик начар кешеләр бит. Динне бетерәләр, Коръәнне таптайлар. Харап эш, харап!

Председатель:

— Сез шуны әйтегез әле, нәрсәгә ирешер өчен кан белән җан белән тырышырга диде ул? Мөхәммәдҗан Хафиз:

— Боларның барысы да минем китабымда язылган. Мин автормын, язучымын. Минем бик шәп китапларым бар.

Председатель:

— Шулай диген! Димәк ки, сез язучы, автор. Нинди әсәрләрегез бар соң?

Мөхәммәдҗан Хафиз: .

— Бар инде, бар. Минем ысуле җәдидне бетергән китапларым бик күп. Ысуле җәдид хәрам ул, ысуле җәдидчеләр кяфер алар. Минем бар сүзләрем шул китапларда язылган. Кая соң тәрҗемәче? Мин сезгә тәрҗемәче аркылы бик шәп сөйләп бирер идем.

Председатель:

— Русча беләсең бит. Тәрҗемәче кирәк түгел. Мөхәммәдҗан Хафиз:

— Беләм белүен дә...

Председатель:

— Башка сөйләсе сүзләрегез бармы?

Мөхәммәдҗан Хафиз:

— Юк.

Бать председательдән рөхсәт сорап:

— Габдулла Бубый Макария җәмгыятендә нотык сөйләгән вакытта полиция тарафыннан берәр кеше бар идеме?

Мөхәммәдҗан Хафиз:

— Бар иде.

Бать, башка сүзем юк диде, утырды. Мөхәммәдҗан Хафиз да борынын казаки итәге белән сөртә-сөртә утырды. Шушы Мөхәммәдҗан Хафиз судка килгән вакытта да, Бубыйларны бетерәм, каторга җибәрәм диеп мактанып килгән. Судтан чыккач та, әмма әйттем соң, беттеләр инде, кадалдырдым кяферләрне диеп, сөйләнеп тә йөргән.

Моннан соң Ишми керде. Ишектән килеп кергәч тә судьялар алдында тузанлы, нәҗес идәнгә тезләнде. Пристав килеп торгызган иде, ике-өч адым атлап тагын тезләнде. Пристав монысында җилкәсеннән тартып, ачуланып торгызды. Ишминең исәр үгез кебек як-ягына каранып "шәригать, шәригать" дигәне ишетелде. Председатель аннан сорады:

— Сез Бубыйлар хакынданиләр беләсез? Ишми бер нәрсә аңламаенча:

— Тәрҗемәче, тәрҗемәче. Минем үз тәрҗемәчем бар иде, кая соң ул? Чыннан да, Ишминең үзе белән йөртә торган бер мөәзине, тәрҗемәчесе бар икән. Ул тәрҗемәчесен монда судка да алып килгән. Һәм үзе белән бергә судьялар янына алып керергә теләгән. Полиция каршы төшкән, ул мөәзин һаман керергә теләгән икән, ниһаять аны полиция төрткәләп чыгарып җибәргән. Бу мөәзин Сарапулда кайбер кешеләргә сөйләгән: безнең хәзрәт бик серле сөйләй ул, аның бер сүзен дә миннән башка юньле аңлаган кеше юк, шуңар күрә аның сүзләрен судта бары тик мин тәрҗемә итәргә кирәк.

Председатель Ишминең сүзен аңламаенча:

— Сез Бубыйлар хакында ниләр беләсез?

Судта катнаша торган тәрҗемәче торып:

— Тәрҗемәче сорай ул. (Ишмигә карап) Сездән сорай, Бубыйлар хакында ниләр беләсез, ди. Сез Бубыйлар хакында ниләр беләсез?

Ишми йокыдан уянган кебек булып:

— Ә... беләм, бик күп нәрсә беләм. Аларның аталарын да беләм мин, мәрхүм бик яхшы, бик кәттә кеше иде. Бу бәдбәхетләр генә юлдан чыктылар, динне боздылар. Алар хөкүмәткә дә каршы.

Председатель тәрҗемәче аркылы:

— Сез моны үзләреннән ишетеп беләсезме?

Ишми:

— Барыбер үзләреннән ишеткән кебек, чөнки мин аны аларның шәкертләреннән ишетеп беләм. Ай, бик тәүфикъсыз бит алар!

— Сез аларның шәкертләрен кайда күрәсез? Бубый Сезгә якын мыни?

— Якын түгел. Ләкин безнең яктан аларда шәкертләр бар. Минем үземнең унлап шәкертем китте анда. Шунда барып юлдан чыктылар, йөзләре кара. Шул шәкертләр миңа кергәләйләр. Сөйләштерәм мин аларны. Алар барысы да чепчи кызыл. Барысы да кяфер.

Бать председательдән рөхсәт сорап, тәрҗемәче аркылы:

— Сезнең "Мизанел-хак" китабыгызда, ысуле җәдидчеләр белән утырышу, алар белән бергә ашау, алырдай кыз алып кыз бирү хәрам дигән сүз бармы? Ул китапта ысуле җәдидчеләрне үтерү дә, алар зарарына ялган шаһитлек бирү дә ярай, савaплы дигәнсең бугай?

Ишми тәрҗемәче аркылы аңлаганнан соң:

— Аны мин әйтмәймен, Коръән шулай ди, Коръән.

— Ул китабыгызда земство акчасы таланып җыела диган сүз дә бар түгелме?

Тәрҗемәче ялгыш тәрҗемә кылып:

— Земство акчасын алу хәләлме, диләр?

Ишми:

— Ысуле җәдидләргә хәләл. Дин мәдрәсәләренә хәрам. Коръән шулай ди. Хәдистә дә бар бу.

Абзый торып:

— Тәрҗемәче сорауны ялгыш тәрҗемә итте. Бать тәрҗемәчегә:

— Юньләп сорагыз, шул китабында земство акчасы таланып җыела дигән сүз бармы?

Тәрҗемәче һаман ялгыш тәрҗемә кылып:

— Земство акчасын алу хәләлме диләр?

Ишми:

— Хәләл, димен. Ысуле җәдидләргә хәләл ул. Ләкин ысуле кадимнәргә хәрам, гөнаһ. Аны мин әйтмәймен, Коръән шулай ди, хәдис әйтә.

Без әйттек, тәрҗемәче тәрҗемәне ялгыш кылды. Катановтан сорадылар, ул да ялгыш диде. Ниһаять, бу мәсьәлә аңлашылмады, шул көенчә калды. Арыслан Моратов[119], тентүдән бер атна элек Бубый мәдрәсәсендә булганын, падишаһ сурәтенең бер дә бозылмаганын сөйләп безгә күп файда ясады. Аннан соң Нәҗип Думави[120] керде. Председатель:

— Бубыйлар мәсҗидтә падишаһка дога кылганнар идеме?

— Кыла торганнар иде.

— Нигә соң следовательгә кылмайлар дидегез?

Нәҗип әфәнде бик калтырана башлап:

— Юк, мин алай димәдем.

— Үзегезнең имзагыз бар бит, хәтта сез әйткәнсез, мин Бубыйларга нигә падишаһка дога кылмайсыз дигән идем, алар, андый вак эш белән маташуда ни мәгънә бар диделәр диеп.

Нәҗип әфәнде тагын да артыграк калтыранып:

— Алар дога кыла торганнар иде. Хәтта җомга саен бер генә түгел, ике дога кыла торганнар иде.

Председатель чат ябышты:

— Ничек ул алай, җомга саен ике дога кылалар?

Нәҗип әфәнде бөтенләй югала төшеп:

— Мин русча белмәймен, тәрҗемәче кирәк.

Председатель аны шулай йөдәтте дә, ниһаять безнең шаһитләргә чират җитте. Алар һәммәсе бик кыска вә бик ачык итеп, безнең һәр җомгада падишаһка дога кылуыбызны, вә безнең һичбер вакыт хөкүмәткә каршы сөйләшмәгәнебезне исбат иттеләр. Фәкать элек бездә, Сарапулда, мәктәпләр инспек-

торы булып торган, һәм шул вакытта безнең мәктәпкә бик күп файдалар ясаган, аннан ни сәбәпледер, Алатырь өязенә күчерелгән Меньшиковтан[121] гына бик озак сорадылар. Ул безнең файдага бик күп сүзләр сөйләде. Татар мәктәп вә мәдрәсәләре хакында хөкүмәт тарафыннан сөйләнгән һичбер програмның юклыгын, алар теләсәләр нинди програм белән укытуда хаклы булуларын, аларның програмаларына керешергә инспекторларның һичбер хаклары юклыгын законча да алар төрекме-башкамы, теләсәләр нинди мөгаллим тотарга ихтыярлы булуларын бәян кылды.

Шаһитләр һәммәсе соралып бетте. Инде аларның барысын да чыгардылар. Бать безгә әйтеп куйган иде, Катанов белән Җузе вөҗдансыз тәрҗемә кыла торган кешеләр түгел, шуңар күрә сез аларның тәрҗемәләренә каршы килеп маташмагыз, диеп. Шуның өчен без каршы килмәдек, аларның хаҗәтләре калмады, алар да чыгарылды. Безнең судларны язып, татар газеталары шауламасыннар, бу эш шулай тып-тын гына узып китсен өчен, безгә хөкемне ябык ишек эчендә кылдылар, шуңар күрә хөкем бүлмәсендә бер кешене дә куймадылар, хәтта Сарапулның прокурорын да кертмәделәр. Ялгыз ротмистр калды. Фәкать Бать белән Маклаков сөйләгәндә, прокурор, Сарапул прокуроры, озын гына ишек янында, ишеккә корган пәрдә артында утырды.

Шаһитләр соралып бетте. Аннан соң прокурор безне гаепләде, вак-төяк ялган шәһадәтләрнең берсен куймады, кертте, иң вак нокталарга кадәр тартты, турайтты, падишаһ рәсеме бозылмаганга егермеләп шаһит була торып аны кыстырды, җыйды, оештырды, безне тәмам гаепле итеп чыгарды, шул кадәр ки, хәтта үзебезне, гаепле икәнбез диеп, үзебез ышана язып калдык.

Аннан соң безнең адвокат Егоров сөйләде, аннан Әхтәмев:

— Әфәнделәр, диде, монда сезнең хөкем алдыгызга ике генә кеше китерелсә лә, монда хөкем ителгән бу ике кеше генә түгел, бәлки 20 миллион мөселман, бу хөкемнең нәтиҗәсен 20 миллион мөселман дүрт күз белән карап тора, алар сездән гаделлек һәм мәрхәмәт көтә. Бу мәсьәләнең гади бер мәсьәлә түгеллеген, бәлки искелек белән яңалыкның сугышы булуын, кайчан гына булса да, озакламаенча, яңалыкның искелекне җиңәчәген, Русиядә иске фикерле, хөкүмәт сүзен аңламас, фанатик мөселманнар урынына тиз көннәрдә яңа фикерле, сүз аңлар вә хөкүмәткә дә файдалы яңа мөселманнар житешүен хәтерегездән чыгармагыз. Яңа буынның хөкүмәткә файдалы яңа укытуларын, яңа тормышларын бүген менә монда, гаделлек вә сәясәт мәйданында яклауны, бөтен әһле ислам, 20 миллион

мөселман сездән көтә. Карт фикерле, искелек тарафдары фетнәчеләрнең золым вә ялганнарына корбан булган бу ике рәнҗетелүченең аклануы, котылуы сезнең кулыгызда, сезгә әманәт. Боларнын уналты айдан бирле, әйтергә генә ансат, уналты айдан бирле дүрт дивар арасында, төрмәнең төрле кысынкылыклары эчендә изелүләрен, аналары, балаларыннан канлы күз яшьләреннән гыйбарәт салкын бер дәрья белән аерылуларын искә алыгыз, кызганыгыз. Әнә, урамда иртәдән бирле җыелып сездән мәрхәмәт көтеп яткан бу кадәр халыкны, ак сакаллары буенча туктаусыз яшьләре агып торган шулкадәр картларны өметсезләндермәгез, кызганыгыз. Бубый әфәнделәрнең күргән бу кадәр газаплары, аларның карт аналары һәм балалары күзләреннән аккан бу кадәр ачы яшьләр җитәр инде. Бу хөкем көне, сезнең гаделлегегез, бу хаксызлыкларга, бу тәмсез күз яшьләренә бер чик бирергә тиеш. Бу көнгә кадәр хөкүмәткә иң тугры 20 миллион мөселманның сезгә, хөкүмәт адәмнәренә, вә шуның аркылы хөкүмәткә дә мәңге тугры калдыру чарасын, бу ике корбанны азат итеп, аларны шул 20 миллион мөселманны риза кылу вә шатландыруны онытмагыз, хәтерегездә тотыгыз. Мин сездән 20 миллион мөселман белән бәрабәр шуны өмет итәм, вә ышанамын ки, сез мондый кече бер мәсьәлә өчен бу кадәр мөселманнарны хөкүмәткә ачуландырмассыз, аларны үзегезгә дошман ясамассыз, бәлки мөмкин кадәр аларны риза итүнең, аларны үзегезгә дус ясауның чарасын карарсыз.

Моннан соң Бать сөйләде:

— Әфәнделәр, диде, сез үзегез белеп торасыз, Бубый әфәнделәр укымышсыз, тәрбиясез түгел, бәлки фәлсәфәгә караган китаплар язарлык мәгълүматлы, инспектор әйтмешләй, Духовный академия дәрәҗәсендәге зур бер мәктәпне үзүзләреннән карар, идарә кылыр һәм тәрәккый иттерерлек фикерле, тәрбияле адәмнәр алар. Шулай булгач, мондаен кешеләрнең, падишаһны мыскыллыйм дип, рәсем бозу кебек мондый вак эшләр белән маташулары, үзегез бер уйлап карагыз, мөмкинме соң бу? Сез менә, менә мондагы ике кыяфәтне күз алдыгызга китерегез: берсе менә монда гаеплеләр урынына утырган ике Бубый, берсе болар өстеннән зарарлы вә ләкин нигезсез шаһитлек бирүче Ишми Динмөхәммәдев. Сез бу ике кыяфәтне менә күз алдыгызга китерсәгез, боларның хөкүмәт өчен кайсысы файдалы, кайсысы зарарлы икәнен аңларсыз.

Динмөхәммәдевнең Бубыйлар хакындагы сүзләре, шәһадәтләре шул кадәр төпсез вә нигезсез ки, хәтта ул Бубыйларның хөкүмәткә каршы булуларына, аларны Коръәнгә каршы гамәл кылалар, Коръәнгә ышанмайлар диеп дәлил өстәй. Әгәр

аның бу дәлиле дөрес булса, сез, судья әфәнделәр дә Коръәнгә ышанмайсыз. Ул вакытта сез дә хөкүмәткә каршы, падишаһка дошман булып чыгарга кирәк.

Ниһаять Маклаковка чират җитте:

— Әфәнделәр, диде, һәрберегезгә, күзегез белән күргән шикелле мәгълүм, Бубый әфәнделәр мәгърифәтле, гакыллы һәм тәрбияле адәмнәр алар. Аларның падишаһ сурәтен бозу вә мыскыллау кебек вак, килешсез, сабый вә тиләләр эше белән маташулары мөмкин түгел. Хәлбуки, падишаһ сурәте бозылган тәкъдирдә дә, шаһитләрдән аңлашылды — һич тә бозылганы юк, шәкертләр эшләгән бер кабахәт өчен Бубый әфәнделәрне гаепләргә мөмкин түгел. Шуңа күрә 3 нче пункт белән хөкем кылырга юл юк.

Җомга көннәрдә падишаһка дога кылуны законның зарур иткәне юк, циркулярларда дога кылырга куша, ләкин ул да җомга көн дими, бәлки хөкүмәт вә падишаһлык көннәрендә, ди. Аның өстенә падишаһка дога кылмау падишаһка каршы бер эш, бер кабахәт түгел бит. 128 нче пункт белән хөкемгә эш, гамәл булырга кирәк. Шулай итеп, Бубый әфәнделәргә 128 пункт белән дә хөкем кылырга мөмкин түгел.

Сез менә Бубый әфәнделәргә хөкем итсәгез итәрсез 132 нче пункт белән. Дөрес, "Хакыйкать" бик каты язылган, дөрес язылган, ләкин бик каты язылган. Мөселманнарны төрле тарафтан кысу вә җәберләү бик күп булганлыктан, аптырап, ихтыярсыз язылган бер нәрсә ул. Әгәр Бубый әфәнде бу китапны нәшер кылса иде, ул вакытта аны 102 нче пункт белән хөкем итәрләр, һәм коткаруы да бик читен булыр иде. Ләкин аны ул нәшер итмәгән, акылы җиткән, рөхсәт сорап цензорга мөрәҗәгать кылган. Әгәр Бубый әфәнденең максаты бер начарлык кылу булса иде, цензорга мөрәҗәгать кылмас, бәлки туп-туры нәшер итәр, таратыр иде.

Шуңар күрә, бу эштә мин, хөкем итәрлек, җәза бирерлек һичбер гөнаһ вә кабахәт юк диеп беләм.

Бубый әфәнделәр бар гомерләрен Русия мөселманнарын агарту вә алар арасына мәдәният вә мәгариф кертү өчен сарыф кылган ярдәмчел, кешелекле, хөрмәтле кешеләр алар. Алар малларын, җаннарын, үзләрен шул юлга вәкыф иткәннәр, шул изге хезмәт артыннан йөргәннәр, һичбер каршылыкка карамаенча дәвам иткәннәр. Алар мәктәпләрен бер тарафтан Духовный академия дәрәҗәсенә күтәргән шикелле, икенче тарафтан шул мәктәп эченә русча ике класслы школ сорап алуны да онытмаганнар. Шул сәбәпле аларга, иске фикерле кайбер адәмнәр каршы төшкән, дошманлык кыла башлаган. Мин катгый мәгълүматка таянып әйтәм, Бубый әфәнделәрнең ба-

шына яуган бу казалар, һәммәсе көнләшүдән, һәммәсе дошманлыктан гына, башка һичбер сәбәптән түгел. Сез бер уйлап карагыз, мәктәпләренең эчендә русча белән татарчаны кочаклаттырып бергә алып барган, вә иске наданлык вә фанатиклыкны җимереп тәрәккый вә мәдәният юлында зур-зур адымнар атлаган бу әфәнделәрнең, рус милләтенә вә Русия хөкүмәтенә дошманлык кылулары мөмкинме соң? Русча уку хәрам, гөнаһ диеп кара халыкны котыртучы, вә шулай итеп хөкүмәтнең халык арасында русча телне тарату фикеренә, тырышлыгына каршы бик куәтле бер тоткарлык тәшкил кылучы адәмнәр, карт фикерле фанатик муллалар арасында, Бубыйларның бу эшләре, бу хезмәтләре, күз йомып китәрлек кенә бик аз бер хезмәт түгел. Шул сәбәпле боларга мөселманнар арасыннан кайбер дошманнар чыкты, болар өстеннән ялган донослар, ялалар кылынды, ниһаять болар шул мәгарифкә тырышлыклары вә халыкны агартырга, нурландырырга тырышулары өчен кулга алынды, ел ярым, бик аз түгел, ел ярым төрмәдә яттылар. Ләкин боларның, Бубый әфәнделәрнең дошманнары никадәр булса да, Русия мөселманнары арасында алар тарафдары кешеләр күбрәк. Аларның теләкләре Бубый әфәнделәрнең бу золым вә караңгылыклардан котылулары. Алай булгач, безгә хөкем вакытында, ул тугры вә зыялы гражданнарыбызның хәтерләрен җәрәхәтләрлек һәр бер хәрәкәттән сакланырга тиешле буладыр.

Татар мәктәпләре начар вә тәртипсез вакытта без алардан күз йомып, Бубый әфәнделәр мәктәпләрен заманга муафыйк ислах кыла вә тәртипкә сала башлагач кына безнең ул мәктәпкә барып катышуыбыз, аны алга барудан туктатуыбыз, ябып куюыбыз, безнең кебек мәдәният юлындагы кешеләргә бик оят, вә кеше арасында бик килешсез вә бик күңелсез бер эш бит ул. Безгә чынлыкта, мәдәни вә мәгърифәтле милләткә, үзебезнең иң турылыклы гражданнарыбыз, татарларның мондай тәрәккый юлына кергән мәктәпләрен ябып куярга, аны бетерергә түгел, бәлки аны алга җибәрергә вә аңар ярдәм итәргә тырышу тиешле.

Хуш, Бубый мәктәбендә төрек теле укыла имеш, һәм шуның өчен Төркиядән бер мөгаллим дә китертелгән имеш. Булсын, анда ни зарар бар? Һәркемнең теләсә нindәй тел укырга хакы бар. Тел өйрәнү кабахәт бер эш түгел. Закон буенча һәрбер телне уку рөхсәт ителә, һичбер телне уку вә укытудан тыю-фәлән юк. Закон буенча чит мәмләкәтләр телен уку, укыту яраган кебек, шул мәмләкәтләрдән мөгаллимнәр китерү дә тыелмый. Без үзебез дә мәктәпләребездә французча тел укытыр өчен француздан мөгаллим китерәбез, чөнки саф французча

телне французның үз авызыннан гына алырга мөмкин. Безнең хөкүмәт мәктәпләрендә, бетәсе түгел, чит мәмләкәтләрдән мөгаллимнәр бар. Алай булгач, Бубый әфәнделәрнең мәктәпләрендә төрек теле укытулары, вә шуның өчен Төркиядән төрек мөгаллиме китерүләре һичбер гаепле вә гөнаһлы бер эш түгел.

Инде килик Бубый әфәнделәрнең көтепханәсеннән "Мең бер хәдис"[122] кебек кайбер китаплар чыгуына. Үзегез әйтәсез аларның көтепханәләре бик зур диеп. Андай көтепханәдә кайбер тыелган китапларның булуы түгел бәлки булмавы гаеп. Мин үзем, үз фикеремә ошаймы-юкмы, анысы башка, ләкин һәрбер яңа китапны укып чыгуны сөям, яратам. Мин аны үзебезнең хакта зарарлы сүзләре булса да, һичшиксез, укып чыгам. Шулай булгач, Бубый әфәнделәрнең, чыннан да үзләре бу кадәр әһле гыйлем вә әһле мәдәният булгач, аларның ул кадәр шау-шуларга сәбәп булган "Мең бер хәдис" шикелле китапларны укулары түгел, бәлки укымаулары, аның эчтәлегеннән хәбәрсез калулары гаеп.

Әмма Төркиядән газеталар, журналлар алдыру, аны уку, мин бу эшне гаепкә санауны оят, көлке дип санаймын. Мин үзем дә немец, француз газеталары алам, аларны, бигрәк тә үзебезгә бәйле җирләрен бик дикъкатләп караймын, укыймын. Алай булгач, Бубый әфәнделәр Төркиядән газеталар, журналлар алып нигә укымасыннар? Хәлбуки бу газеталар, журналлар һәммәсе цензор каравыннан, аның дикъкатеннән уза. Димәк ки, әгәр аларда бер гаепле сүз була торган булса, аның өчен Бубый әфәнделәр түгел, бәлки цензор гаепле булырга тиеш.

Сүзләр сөйләнеп бетте. Председатель прокурордан, адвокатларның сүзенә җавап бирә торган җирләрең бармы, диеп сорады. Юк, диде. Аннан соң судьялар киңәш кылырга, бер карар бирергә кереп китте. Араларында тавыш булды ахрысы, безгә дә ишетелде. Соңнан белдек, Сарапулдан кергән өч судья безне гаепсез дигәннәр, ләкин Казаннан килгән дүрт карт бары тик гаепләү тарафында булып, ниһаять безгә, абзыйга ике ай, миңа алты ай төрмә җәзасы салынуы, һәм безне хәзердән, безгә бирелгән җәза Казанский судебный палата тарафыннан раслангančы төрмәдән чыгарып полиция күзәтүе астында торгызу игълан ителде. Ягъни элек утырган уналты аебыз, анысы җәза түгел, бәлки безне "кунак итү" генә булды. Ай бу гаделлек хезмәтчеләрен, үзләрен дә шулай берәр уналты ай шунда кунак итеп чыгарырга!

Бать безгә, сезне һичшиксез гаепләрләр, монда җибәргән Казан судьяларына шулай әмер бар, һәм сезне, җәзагызны тутырмаенча төрмәдән дә чыгармаслар, дигән иде. Ләкин ни

сәбәп булды, ихтимал адвокатлар сүзенең әсәре, ихтимал Сарапулдан кергән судьяларның безне гаепсез табуларының тәэсире булды, безне вакытлыча төрмәдән чыгарып торырга карар бирелде. Һәм безгә төрмәдән чыгару хакында секретарь язу биргән вакытта әйтте: "Инде палатадан риза булгансыздыр? Маклаковларны риза итеп юкка китергәнсез. Алар килмәсә дә барыбер сезгә хөкем шушы иде".

Димәк ки, Батьның сүзе дөрес чыкты: ягъни Казаннан килгән судьялар безне һичшиксез гаепле кылу белән әмерле икән. Хуш, мине гаепле дә кылсыннар, минем 9 нчы "Хакыйкать" бар. Ләкин абзыйның ни гаебе бар? Аның язуларында зарарлы бер сүз дә юк, шуңар күрә аның китаплары судка да кермәде, һәм көтепханәбездәге китапларны барысын мин үз өстемә алдым, һәммәсе минеке дидем. Хәтта безнең эш артыннан камил тырышлык белән йөргән Бәдретдин Җәлалетдин углына, безнең эшне башыннан ахырына кадәр тикшергән судебный следователь әйткән: Гобәйдулла Бубыйның гаебе юк бит, нигә яңадан кәгазь бирмәй, котылыр, дигән. Күрәсең, үзләре гаепсез дип беләләр, үзләре гаепләйләр, җәза бирәләр. Чөнки ул минем белән бер өйдә торган, мөгаен минем фикеремә сердәш, имеш. Менә сиңа яңа бер фәлсәфә! Менә сиңа гаделлек хезмәтчеләренең гаделлек вә хакыйкать исеменнән кылган гаделлекләре! Алай булса, минем белән бер өйдә торган әнкәй дә бар, җәмәгатьләр һәм балалар да бар, хәтта бик күп вакыт минем язу өстәлемә менеп кунаклай торган песәем дә бар, абзый минем белән бергә торганлык өчен гаепле булса, болар да гаепле булырга тиеш.

Син гаделлек хезмәтчеләренең гаделлек исеменнән кылган хаксызлыкларын тәнкыйть итмә, сүз кушма, югыйсә сиңа тагын бер җәза хәзер. Монысы тагын үзе бер гаделлек. Абзыйны да бер дә юкка гаепләмәделәр, кирәккә гаепләделәр: беренчеләй, Бубый мәктәбенең алга китүенә, татарлар арасында гыйлем, мәгърифәт таратырга бик тырышкан вә шуңа күрә кара хөкүмәт алдында бик зур гаепле бер кеше ул. Икенчеләй, безнең китапларны русчага тәрҗемәләр вә башкалар өчен сарыф кылынган 1600 сум акчаны безгә түләтү, безгә матди зарар ясау өчен, әлбәттә безне гаепле ясау, безгә җәза бирелү тиеш.

Иртән сәгать 9 дан башланган безнең суд кич сәгать 12 гә кадәр дәвам итте. Вакыт шулай кич булса да, безне хөкемнең нәтиҗәсен көтә торган халык белән урамнар туп-тулы иде. Шуңар күрә халык тарафыннан демонстрация ясалмасын диеп, безне кире төрмәгә кайтарган вакытта, 5 солдат янына 25-30 атлы стражниклар белән саклап кайтардылар. Төн караңгы, янгыр сибәли иде. Судтан чыгып озак та китмәдек, ка-

раңгылык эченнән бер сабыйның әсәрле бер авазы ишетелде. 7 яшәр кызым Галиянең авазы иде. Иртәдән алып төннең уртасына кадәр, безне көтеп суд тирәсендә йөргән. "Әткәй! Кайтасызмы?" Мин җавап бирдем: "Төрмәдән чыгабыз, иртәгә кайтабыз".

Иртән, майның 29 ында, төрмә алды безне каршыларга килгән халык белән туп-тулы иде. Бәдретдин Җәлалетдин углы, абзыйның балаларын бер арбага, минем балаларны бер арбага утыртып, төрмә алдына безне алырга килгән иде. Без шул арбаларда, урам тулы халык арасында, иң элек полициягә, аннан әнкәйләр төшкән номерга киттек. Бәдретдин әфәнде Җәлалетдин углы, югарыда сөйләгәнемчә, бик искедән бирле Бубый мәктәбенә зур хезмәт кылып килгән шикелле, бу бәла вә каза вакытларында да безгә бик күп хезмәтләр кылды. Һәм Мөхәммәджан хаҗи Әхмәджан углы белән аның җәмәгате Фатиха түтәйнең дә зур акчалар белән ярдәмнәре, һичбер онытылачак түгел. Мөхәммәджан хаҗи бу юлда 15000 тәңкәдән артык чыгым тотты. Бу акча бит аз иманлы кешенең кесәсеннән чыга торган бик аз акча түгел. Батьны да Мөхәммәджан абзый яллады, Маклаковны да Мөхәммәджан абзый китерде, башка чыгымнарның да иң күбесен Мөхәммәджан абзый тотты. Милләт, милләт дигән башка кешеләрнең берсеннән бер тиен иганә булмады. Фәкать Мөхәммәдьяр Саттаров әфәнде 100 тәңкә иганә кылды.

Менә шулай безнең өстебездән дәһшәтле бер кара дулкын узып китте. Без үзебез аның астында вакытлыча калдык, вакытлыча җәза күрдек, бәлаләндек. Ләкин мәктәпләр бөтенләй беттеләр, мәңгегә югалдылар. Ирләр мәктәбе без тотылгач озак тормады, хөкүмәт әмере белән ябылды[123]. Кызлар мәктәбен сүз белән куркытып яптырмакчы булганнар иде. Безнең кыз кардәшебез Мөхлисә Бубый белән безнең җәмәгатьләребез, бу хакта киңәшер өчен безнең янга төрмәгә килделәр. "Ни эшләйбез?" Кызлар мәктәбен дәвам кылдырсак, безне дә "ябарлар диеп куркыталар". Без әйттек:

"Яман исем белән мәктәп ябудан, яхшы исем белән төрмәгә ябылу артыграк". Шуннан соң алар безнең сүз белән канәгатьләнеп, чыгып киттеләр, кызлар мәктәбен һаман дәвам кылдырдылар. Ниһаять, кызлар мәктәбе дә, Вятка директорының 1912 елда 18 гыйнварда 47 номердагы әмере белән ябылды, сүнде. Бубыйның ирләр һәм кызлар мәктәбе, заманында тантана белән дәвам кылды, изге хезмәтләрен итте, ябылган вакытта да безнең тарафтан бер гаеп белән түгел, бәлки залим хөкүмәтнең золымы, әмере белән, безгә мәртәбәле бер ябылу белән ябылды. Халык соңыннан никадәр тырышты,

мәктәпләрне ачтырырга йөрде, ләкин өметсез җаваплардан башка һичбер нәрсә алырга ирешмәделәр. Хәтта ябылуның сәбәбен сораганнар иде, директор да һәм губернатор да, сезгә сәбәбе кирәк түгел диеп кенә кайтардылар.

Менә шулай бу вакыйгалар: бөтен Русия мөселманнарын бер мәртәбә селкетеп узып киттеләр. Без янадан төрмәгә кереп, тоткынлык вакытыбызны тутырдык. Мин 1913 ел, февральнең 9 ында тәмамлап чыктым. Әгәр Бубый кызлар мәктәбе ябылмаса, абзый белән без киңәшне беркеткән идек. Икебез дә Бубыйда калырга, вә ничек кенә булса да шул кызлар мәктәбен алып барырга, хезмәт итәргә, алга җибәрергә. Ләкин кызлар мәктәбе ябылгачтын без исәпне үзгәрттек, озак киңәшләр иттек, бер уйладык Мәдинәгә мин барып, мәсҗидләр нәзарәте астында мәгариф җәмгыяте ачарга, хаҗиларны шуңа иганәгә ризалатып, акча җыярга, вә шул акча белән гарәпләр арасында гыйлем-мәгърифәт таратырга. Ләкин безне кайбер сәбәпләр бу уйдан кайтырга мәҗбүр итте. Ниһаять, без карарны бирдек, мин төрмәдән чыккач та, Кытай эченә, Голҗага китәргә, андагы бер мәктәпне кулга алырга, аны ислах итәргә, заманга муафыйк мөгаллим һәм имамнар чыгарырлык бер дәрәҗәгә җитештерергә, кызлар мәктәбен дә мөгаллимәләр тәрбия итәрлек төзәтергә, вә акрын-акрын Бубыйда хезмәт иткән мөгаллимнәрнең һәммәсен шунда җыярга, вә, кыскасы, Голҗаны Төркестанда гыйлем вә мәгариф таратыр өчен бер үзәк ясарга, мөмкин булса халык арасында һөнәр вә санагать чәчү җәмгыяте оештырырга...

Безнең кыз кардәшебез Мөхлисә Бубый кызлар мәктәбе ябылганның икенче көзендә Троицкига китте[124], кызлар мәктәбен анда тергезде. Мин төрмәдән чыккач та Голҗага үземне чакыртыр өчен планнар кора башладым, Габдрахман Әхмәревне[125] арадашчы ясадым. Чөнки чакырылмаенча барган вакытта, мин килдем, мәктәпне бирегез диеп эшне кулга алу байтак кына авыр бер мәсьәлә. Әмма үзләре чакырса, эш башка, барганда ук мәктәп минеке диеп ышанып барасың, хезмәт урыны ачык билгеле була. Ниһаять, эш булды, Голҗа татарлары мине чакырды, без дә Галияне Тройскида гимназиядә куеп, Хөснефатыйма, Ситдыйка, мин 1913 ел август 25 ендә юлга чыктык.

* * *

Без Яркәндтән[126] сентябрьнең 23 ендә чыктык, 24 ендә чиктән уздык. Голҗага сентябрьнең егерме бишендә барып кердек. Юл буе чуп-чуар, алмага чыккан ир-ат, хатын-кыз

белән тулы иде. Мәктәп балалары да безне менә бу шигырьне әйтеп каршыладылар:

Хуш килдегез, әй остаз!
Сезне һәркем ята эстәп.*
Көтә-көтә менә без дә
Тилмерештек бихисап.
Менә остаз карагыз,
Сезне каршы алабыз.
Сезнең килү шатлыгыннан
Шаулай бөтен калабыз.
Гөж килә бөтен кала,
Һәркем чыгып каршы ала,
Сезнең килү бәйрәменә
Шатлана һәрбер бала.
Инде наданлык бетәр,
Шәхси максатлар китәр,
Милләт бары бер киңәштә
Мәктәпне алга итәр.
Яуды Голҗага дөррәт,**
Итә алмас дошман сауләт.***
Шатланыгыз менә инде
Сүнмәс безнең бу милләт.

## Мөхтәрәм Гаспринскийның[127] вафат хәбәре

Һава салкын, күңелсез. Иртәдән бирле нигәдер эчем поша, бер дә юкка хафаланам. Дүрт көн элек, халыкка әйтеп, Исмәгыйль бәкнең сәламәтлеген сорап телеграф суктырган идем. Аңар да җавап юк. Без телеграф суккан вакытта ул мөхтәрәм остазның кара туфраклар эчендә ял итүеннән кемнең хәбәре бар? Кемнең хәбәре бар ул хөрмәтле әфәндебезнең безне ташлап җиде кат күкләргә, иң югары галәмнәргә очуыннан? Ниһаять газеталарның каралар белән буялган кара нумерлары[128] монда да килеп җитте. Ачы хакыйкать аңлашылды. Һәммәбезнең остазы, мөхтәрәм Исмәгыйль бәк хәзрәтләре үлгән, мәңгелек дөньяга, мәңгелек оҗмахына киткән иде.

---

* эстәп – теләп, көтеп.

** дөррәт – энҗе-мәрҗән.

*** сауләт – һөҗүм.

Тәкъдиргә каршы һичбер нәрсә эшләр хәл юк. Кяшки, ул безнең арабызда ун гына ел торса, безне армас куәте белән тагын да алга, тагын да алга сөйрәсә иде!.. Юк шул әҗәлгә чара, юк үлемнән котылу.

Инде нишләргә? Алама хатыннар кебек елап утырудан бер файда да чыкмас. Аңар каршы соңгы бурычыбызны үтәргә кирәк. Шуңар күрә мин, иң элек ирләр мәктәбендә ир балаларны җыеп, аннан кызлар мәктәбендә кыз балаларны җыеп Исмәгыйль бәкнең кем икәнен, милләткә, безгә һәм аларга нинди хезмәтләр кылганын аңлаттым. Гөнаһсыз балаларның күзләреннән аккан тәэсир бөртекләре минем үземә дә әсәр итте. Түзмәдем, балалар кебек мин үзем дә еладым.

Аннан соң аксакал аркылы, халыкны да мәктәпкә җыеп, шул хакта бер нотык сөйләдем, аның кебек милләт юлында тырышырга өндәдем. Коръән укылды. Һәркем ихлас күңелдән дога кылды.

Бәхетле бул, мөхтәрәм остазыбыз, әткәбез әйткәнчә "һәрбер гасыр башында бер җәдитче килер" дигән сүзнең мисалы булуында минем бер шөбһәм дә юк. Пәйгамбәребез яшендә, аның хезмәтен эшләп үлдең, аның белән бәрабәр телгә алыначак син. Мөселманнар арасында аваз ысулы белән укытуны иң элек син чыгардың, "Хуҗаи сыйбъян"ны[129] иң элек син яздың, уку китапларын иң элек син төзедең, муллалар белән зыялыларыбызны син якынлаштырдың, муллаларыбызга тәрәккый фикерен, зыялыларыбызга миллият фикерен син бирдең, бөтен әһле исламны бер фикергә җыю вә шуңар хезмәт иттерү өчен син тырыштың, Мисырына, Һиндстанына син чаптың[130], Русиядә башлап төркичә газета[131] син чыгардың, ислам типографиясен син кордың, хатын-кызларыбызны укытырга тиеш дигән шәригать хөкемен башлап син аңлаттың, бу яхшы мәктәпләрне вә бу тәртипле мәдрәсәләрне чәчәргә, салдырырга син сәбәп булдың...

Без синнән разый, Аллаһы да синнән риза булсын, сөекле, хөрмәтле остазыбыз!..

## Хөррият көннәре

Хөррият[132] безгә Голҗада өченче мартта ишетелде. 4 нче мартта кайбер кибетләргә шатлык байраклары күтәрдек. Консул хатыны базарда: "Нигә күтәрәсез бу байракны? Хөкемгә эләгәсегез киләмени?" - диеп кызуланып йөрде. Ләкин аның

өрүенә игътибар кылган бер кеше дә булмады. Хәтта консулның 15 яшәр улына тикле: "Без падишаһ тарафдары, безгә падишаһ кирәк", — диеп мыркылтап йөрде. Консул үзе дә хөрриятне яшерергә бик тырышты. Николай сурәте почтаханәдән алынгачтын да, консул идарәсеннән һаман алмады. Соңрак аны көчләп алдырдык...

Мартның 12 сендә консул яңа хөкүмәткә дога кылдырырга диеп, халыкны консулханә алдындагы мәйданга чакыртты. Без "доганы мәсҗидтә кылабыз, консул үзе мәсҗидкә килсен" дидек. Килде ул. Иң элек дога булды. Аннан соң мин, "без иске хөкүмәткә, аның түрәләренә дошман, рус халкы белән дус без, без алар белән искедән дә бергә, хәзер дә бергә, моннан соң да бергә булачакбыз. Бетсен карагруһлар! Яшәсен яңа хөкүмәт!" эчтәлегендә кыска бер нотык сөйләдем. Гариф әфәнде аны русча тәрҗемә кылды...

13 ендә без, татарлар, 10 кешедән гыйбарәт вакытлы комитет сайладык. 14 ендә үзбәкләр сайладылар. 15 ендә уйгурлар сайладылар. Иске аксакалларның барысын себереп, яңа аксакаллар эшкә керештеләр.

## Беренче Май бәйрәме

Бөтен дөнья эшчеләре, һәр ел майның берендә хөррият бәйрәме ясыйлар. Ләкин русларның ел хисабы Европа халкының ел хисабыннан 13 көн артта калган. Русиядә хөррият булгач та, эшче халык, Европадагы эшче халык белән бер көндә бәйрәм итмәкче булды. Аларның Беренче Май, безнең 18 нче апрельгә туры килә. Шуңар күрә бездәге эшче халык, Беренче Май бәйрәмен 18 нче апрельдә ясамакчы булды. Без аны Голҗада да ясадык.

Халык, консулханә каршысындагы зур мәйданга җыелды. Төркем-төркем һәрбер милләтнең алдында "Яшәсен хөррият! Бетсен золым! Яшәсен гадел яңа хөкүмәт!" диеп язылган байраклар җилферди иде. Русларның атлы гаскәрләре дә шунда чыккан, тезелгән иде. Без үзебезнең мәктәп кызларын да алып чыктык. Алар үз алларына сайланган сакчылар сагы астында бардылар, ирләрдән бер тарафта, мәйданның бер читендә тордылар. Нотыклар сөйләнде. Безнең мәктәп кызларыннан да 4 кыз нотык сөйләделәр. Рус хатыннарыннан бер сөйләүче дә булмады. Татарларга йөз аклыгы булды. Руслар бик хурландылар.

## Минем өчен мәҗлес

Апрельнең 25 ендә, Голҗадагы татарлар мине хөрмәтләп бер мәҗлес бирмәкче булдылар. Голҗадан биш чакрым ераклыкта Җыргалан дигән җиргә алып чыктылар. Анда безне татар яшьләре зур байраклар күтәреп каршы алдылар. Дүрт егет бер чатырның дүрт почмагында тотып, безнең өстебезгә күләгә итеп бардылар. Ике якка тезелгән 30лап солдат арасыннан узган вакытта, алар ялан кылыч "яшәсен хөррият каһарманы!" диеп кычкырдылар. Анда төрле милли уеннар уйналды. Гариф Габид әфәнде, Ситдыйк Юски, Йосыф Хуҗасәед, Йосыф Лаеш, бер казак мөгаллим, Гани шәкерт, Фатыйма Янсыб тарафларыннан нотыклар сөйләнде. Мин дә аларга бер нотык сөйләдем, рәхмәтләр укыдым, вә аларның бу мәҗлесләренең минем күңелемдә бетмәс бер күңелле әсәр куйганлыгын аңлаттым.

## Кадерле ядкәр

Голҗадагы татар өлкәннәре, 11 кадак көмеш, вә 8 мыскал алтыннан, өстәлгә утырта торган бер рәсем рамы ясатып бүләк иттеләр. Өстенә алтын белән дә, көмеш белән дә минем исемем язылмыш иде. Татар яшьләре берсенә минем исемем вә берсенә Хөснефатыйма исеме язылган көмеш такта ябыштырып ике зур кытай вазасы бүләк иттеләр. Уйгур яшьләре, башларында доктор Мәсгудь әфәнде белән, миңа ядкәр диеп язылган көмеш башлы бер таяк бирделәр.

## Озату

Мин Голҗага 1913 елда сентябрь 25 ендә килеп кергән, вә Шакир әфәнде Юашевның[133] өенә килеп төшкән идем. Мин киткән көнемдә дә шул өйдән чыгып киттем. Ул мине үз атлары вә Закир исемле углы белән Кургашка тикле озаттырды.

Голҗадан 1917 елда, майның берендә чыктым. Доктор Мәсгудь әфәнделәр, шәһәрдән 3-4 чакрым читтә, Йосыфҗан аксакал бакчасында бер хөрмәтләү мәҗлесе бирделәр. Бөтен мәктәп балаларын алып чыккан иде. Безнең дә ир вә кыз балаларыбызның барысы да чыкканнар иде. Уйгур, нугай, кашгар,

татар... озата чыккан кешеләрнең һичбер хисабы юк иде. Анда да урынына күрә нотыклар сөйләнде. 4 ел эчендә бик күп дуслар ясалган иде. Алардан бигрәк тә, мәктәбебезнең ир вә кыз шәкертләребездән аерылу бик кыен булды. Хәлил әфәнде белән кочаклашып аерылыштык. Ул кычкырып елап, исеннән авып калды. Мәсгудь әфәнде белән кочаклашканда, аның да минем дә күзләребез яшьләнгән иде.

Кургаштан Яркәндкә юнәлдек...

Яркәндтән Алма-Атага...

Алма-Атадан Пишпәккә...

Пишпәктән Әүлия-Атага...

Аннан Ташкентка...

## Ташкент

Ташкентта без Галиәсгар әфәнде Сәүтиүшнең "Касыйм" дигән номерына төштек. Үзе дә, хатыны да, кызы да безгә зур ихтирам күрсәттеләр. Кәбир Бәкер[134] әфәнде белән Рәхим Томин әфәнде халык тарафыннан делегат булып килеп, безне Хөррият белән һәм сәламәт кайтуыбыз белән тәбрик иттеләр. Анда мин Ташкентның мөхтәрәм кешеләреннән Кәрим Сәүтиүш һәм Рәхим Ширинский әфәнделәрне вә үзбәк кардәшләребездән Мөнәүвәр карыйны күрдем. Ул вакытта Ташкентта, андагы эшләрне тәртипкә салышырга килгән Садрый Максуди[135], Баттал[136], Сөнгатулла Бикбулат[137] әфәнделәр кебек байтак мөгаллимнәр һәм җәмәгать эшлеклеләре бар иде. Ташкент татарлары безнең барыбыз өчен, бер ямьле бакчада мәҗлес бирде, һәм миннән Ташкентта татар мәсҗиденә хатиб һәм яңа ачылачак дарелмөгаллиматта мөдир булуымны үтенделәр[138]. Мин хатиблыкны кире кагып мөгаллимлекне, мөдирлекне кабул иттем, яхшы терелсәм килмәкче булдым.

Оренбургта төнлә иде. Шулай булса да Борһан Шәрәф,[139] Харис Фәйзи,[140] Габделхәмид Мөслими[141] кебек берничә җәмәгать эшлеклесе күрешә төшкәннәр иде. Бу кардәшләрем белән вокзалда гына күрештем. Оренбургка керергә бик кысталар да, вагонга менү-төшү бик кыен, бик тыгызлык булганлыктан, кермәдем, туры Сакалга киттек.

Самарага пароходка кергәч тә Галимҗан хәзрәт[142] белән Зариф[143] вә Салихҗан[144] хәзрәтләрне очраттым. Галимҗан хәзрәт белән мөфтилек турында сөйләштек. Мәскәүдә мөфтилеккә сайлау мәҗлесендә,[145] миңа тавыш аңа тавыштан бик аз гына

ким иде. Ул беренче, мин икенче идем. Ләкин мин сәламәтлегем булмаганлыктан, мөфтилеккә риза түгел идем. Галимҗан хәзрәтне димләдем, мөфти булуын мәслихәт күрдем. Без аның белән пароходта күп сөйләштек. Бер сүз арасында ул, Муса Бигиев[146] белән Зыя Кәмали[147] әфәнделәр хакында "берсе динсез, берсе дәһри" диеп узды. Мин бик сәерсендем. Ләкин хәзер үкенәм, ныклап сорай алмадым.

Казанда үзебезнең Ягъкуб Хәлил[148] әфәндене күрдем. Ул да үзенә керергә бик кыстаган иде. Чынлыкта минем докторга (профессорга) күренәсем дә бар иде. Ләкин бу юлы күренмәдем. Яңадан килдем. Ягъкуб әфәндегә төштем. Аның җәмәгате Әсма ханым, Нәфигулла Заһидулла хаҗи кызы бик булган вә чын йорт хуҗасы хатын икән.

## Бубый

4 ел тулганда яңадан Бубыйга кайтып кердем. Бубый беткән, рух сүнгән, әллә нидәй ямьсез бер кыяфәткә кергән иде, фәкать безнең йортлар, кызлар мәктәбе иске сурәтендә, бакчаның агачлары бик үскән, ыспайланган иде. Мин анда кәҗә сөте эчтем, кояшта бакчада йөрдем, бераз кәефем төзәлде. Шулай да бөтенләй сәламәтләнеп җитә алмадым. Алай да Ташкентка бармакчы идем. Анда бик зур эшләр эшләүне өмет итә идем. Шул арада Тройскидан Яушев Муллаәхмәд әфәнде белән Мөнәвәрә ханым килделәр, үзләренең дарелмөгаллимин белән дарелмөгаллиматларына мөдир итеп чакырдылар. Мине Ташкентның ачлыгыннан вә һавасының минем сәламәтлегем өчен зарарлы булачагыннан куркытып берничә кешедән хатлар да бар иде. Доктор да "Ташкентның тышкы һавасы юеш, сиңа ярамас" дигән иде. Абзый да, әнкәй дә, мулла-абыстай да Тройскига барырга димләделәр. Шуннан соң мин Ташкентка "бара алмаймын, гафу итегез, тәмам сәламәтләнеп җитә алмадым" диеп телеграф суктым. Ихтимал, мин ялгышканмындыр. Ихтимал, мин Ташкент халкына вәгъдәсез булганмындыр, бар гаеп миндәдер. Ләкин чынбарлык менә шушыннан гыйбарәт: минем менә бүген дә һаман сәламәтләнеп беткәнем юк. Шулай булса да, әллә нигә Ташкентка бармый калганлыгым өчен күңлем рәнҗи, хафаланам, аның бүгенге куркынычлы ачлыклары вә утлы, канлы чуалышлары арасында җан бирүне, монда Тройскида туклык вә тынычлык эчендә рәхәт ятудан артык төсле күрәм.

## Тройский

Без Тройскийга 1917 ел 21 августта килеп життек. Нияз әфәнде[149] бер сүз арасында "Сезне монда ни диеп чакырдылар?" диеп сорады. Мин бу тупас сораудан аптырап киттем. Шулай да дарелмөгаллимингә мөдир итеп чакыруларын яшердем, асылда мин анда мөдирнең Нияз әфәнде икәнен белә идем, шуңа күрә мин анда мөдир булуны Бубыйда вакытта ук кире каккан, фәкать дарелмөгаллиматта мөдир булырга вәгъдә биргән идем.

Бубый-Сарапул-Голжа-Бубый.
1913-1918.

## Искәрмәләр

1. Ижевский завод — хәзерге Удмуртия Республикасының башкаласы Ижевск шәһәре.

2. Мөхәммәджан Әхмәджан углы (1842-1925) — Бубый бае.

3. Нигъмәтулла Монасыйб углы (1788-1845) — Гобәйдулла, Габдулла һәм Мөхлисә Бубыйларның бабалары, Бубый авылының дүртенче имамы. Ризаэтдин Фәхретдин аның хакында болай дип яза (теле җиңелләштерелде): "Сарапул ягында Бубый авылында имам вә мөдәррис булып 57 яшендә, 1845 елда, рабигыль-әүвәл аенда (26 нчы февраль) вафат булды. Чыгышы белән Казан ягындагы Бәрәскә авылыннан. Хатыны үзенең остазы булган Габделкәрим Хәлил улының кызы Газизә исемендә булып, 42 яшендә, иген вакытында 1842 елда вафат булган.

Балалары: Гобәйдулла, Габделгалләм, Габдулла. Остазлары: Әбүбәкер Йосыф углы әл-Казаный, Габдулла Яхъя углы әл-Чиртүши, Габделкәрим Хәлил углы әл-Бубый иде. Дәресе куәтле вә үзе шәригатьтә көчле бер зат иде, диләр. Үзе урынына имам вә мөдәррис булган углы Габделгалләм 1909 елда вафат булып, уку-укыту өлкәсендә үзенә яхшы алмаш булган балалар калдырып китте. Бу гыйлемханәсен Аллаһы тәгалә якласын!" ("Асар", 2 нче жилд, 10 нчы җөзьэ.- Оренбург, 1904.- Б. 121)

Шиһабетдин Мәржани дә "Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар" дигән хезмәтендә аның турында, "Бубый Нигъмәтулла дип танылган гыйлем иясе" дип телгә алып үтә.

4. Казан губернасы Бәрәскә авылы — Татарстанның Арча районындагы авыл.

5. Ибраһим Бикчәнтәй углы (? -1800) — Шиһабетдин Мәржанидә:

"Тумышы белән Олы Саба авылыннан. Кайбер сүзләргә карaганда, Буклавыч исемле авылдан чыккан... Мелла Бикчәнтәй Бәрәскә авылында имам, хатыйб һәм мөдәррис булып, 28 ел дәрес әйтеп, 1215 (1800) елда, шәгъбан аеның 27 се көнендә вафат булган һәм Бәрәскә каберлегендә җирләнгән. Дини идарә ачылгач, сайламыйча гына,

Мөхәммәдҗан мөфти соравы буенча Оренбургка беренче мәртәбә Дини идарәгә әгъза булып барган өч казыйның берсе. Беркатлы, вәгъдәсендә торучан, гарәп сүзләрен кулланып сөйләргә яратучан кеше булган". (Мөстәфадел-әхбар..., Казан, 1989. -Б. 244-245.) Ш. Мәрҗанинең бабасы һәм әтисе дә Ибраһим Бикчәнтәй углыннан белем алганнар.

6. Мәчкәрә авылы – хәзерге Татарстан Республикасы Кукмара районындагы авыл.

7. Дамелла Габдулла бине Яхъя (177?-1859) – "Мөстәфадел-әхбар..." да аның хакында болай диелә: "Тумышы белән Чистай тәбәгендәге Чиртүш исемле авылдан. Мишәр таифәсеннән. Башта Мәчкәрә авылында... соңыннан Бохарада олы галимнәрдән... дәрес ала. 1227 (1812) елның азагында иленә кайтып өйләнә һәм, каенатасына арадашчылык итеп, Мәчкәрәдә имам, хатыйб һәм мөдәррис була... Озак вакытлар дәрес әйтә, үз заманындагы мөдәррисләрнең иң шөһрәтлесе була. 1275 (1859) елда вафат булып, Мәчкәрә каберлегендә җирләнде. Якынча 85 яшендә иде. (319 б).

Р. Фәхретдин, аның шәкертләре арасында Нигъмәтулла Монасыйб углы әл-Бубыйны да атап үтә. ("Асарь", 2 нче җилд, 12 нче җөзьэ. Оренбург, 1907. - Б. 312.

8. Габделкәрим хәзрәт кызы Газизә (1800-1842) — Гобәйдулла, Габдулла һәм Мөхлисә Бубыйларның әтиләре ягыннан әбиләре.

9. Комиссар – XIX гасырда Русия дәүләт системасында җирле администрация чиновнигы.

10. Габделгаллэм (1834-1909) — Гобәйдулла, Габдулла һәм Мөхлисә Бубыйларның әтиләре. 1857 елдан Бубый авылының алтынчы имамы.

11. Сокман авылы – хәзерге Татарстан Республикасының Әгерже районында.

12. Гәйнә (Гәйнә иле) – хәзерге Башкортстан Республикасының төньяк-көнбатыш һәм Пермь өлкәсенең көнчыгыш өлеше.

13. Эстәрлебаш – Уфа губернасына караган Эстәрлебаш авылында XVIII гасырның 10нчы-20 нче елларыннан башлап 1921 елга кадәр атаклы татар мәдрәсәсе эшләп килгән.

14. Казан Габделкәрим хәзрәт – Мөхәммәдкәрим Габделгали углы Габделгаффар, Казанның 1868 елда төзелгән 8 нче җамигъ мәчетендә азанчы булган, 1891 елдан указлы имам-хатыйб һәм мөдәррис.

15. Хиҗаз – Гарәбстан ярымутравында урнашкан өлкә. Хиҗазның төп шәһәре – Мәккә. 1915-1925 нче елларда мөстәкыйль солтан дәүләте була, ә 1932 елдан Сәгуд Гарәбстанының бер өлкәсе.

16. Анатуль – (борынгы юнан телендә "шәрык" мәгънәсен аңлата, төрекчә "Анадолу" дип йөртелә). Борынгы чорда Кече Азиянең исеме. XIV гасырдан Госманлы төрек дәүләтенең бер өлкәсе.

17. Тукаев Нигъмәтулла хәзрәт – Ш. Мәрҗани аның турында түбәндәгечә язган: "Чыгышы белән Казан иленең Малмыж өязе Салавыч авылыннан. Бабасы шуннан күчеп китеп, башкортлар арасында башкорт дип язылып, Эстәрлебашта урнашып кала... Дөньясы киң, шәкертләре күп була. Үз илендә чиктән тыш зур шөһрәт казана. Мелла Габденнасыйр әл-Курсави карашын яклаучылардан һәм аның дусларыннан була. Үз мәдрәсәсендә аңа карата кызыксыну уята. ("Мөстәфадел-әхбар...". — Казан, 1989. — Б. 245)

18. Харис Нигъмәтулла хәзрәт углы – "Атасы урынына калып, 1287 (1870) елда вафат булды. Бохарада мелла Хәсән бине Халь әл-Бохари, мелла Фазыл бине Гошур әл-Гиждуани, мелла Нияз бине Биниямин әл-Бәлхи һ.б. дәресенә йөреп, үз вакытында мелла Гобәйдулла бине Ниязколый әт-Төрекмәнидән ишанлыкка рөхсәт алып кайткан." ("Мөстәфадел-әхбар...". — Казан, 1989. — Б. 246).

19. Харрас Нигъмәтулла хәзрәт углы – "Бохарага сәфәр кылып мелла Габделмөэмин Хуҗа, мелла Хәсән, Нияз һәм мелла Фазыл әл-Гиждуанилар хозурында шөгыльләнеп, иленә кайткач шәехлек иткән. Бусы 1288 (1871) елда 57 яшендә вафат булды. Бохарада чагында энебез мелла Садретдин аның белән бергә укыды. Мелла Харрас та ихтирам казанды, дөньясы киң, шәкертләре күп булды. Атасы һәм бертуган абыйсы дәрәҗәсендә иде." ("Мөстәфадел-әхбар...". - Казан, 1989. — Б. 246.).

20. "Җәннәтел-бакыйг" – Мәдинә шәһәрендә атаклы зират исеме. Мөхәммәд пәйгамбәр белән берлектә ислам дине өчен барган сугышларда корбан булган беренче мөселманнар җирләнгән урын.

21. Такта Алачык авылы – хәзерге Татарстанның Актаныш районында.

22. Тирсә – хәзерге Татарстанның Әгерҗе районындагы авыл.

23. Мансуров Ягъкуб Нигъмәтулла углы – Фазлулла Фәйзулла улының кияве. XX гасыр башында татар милли хәрәкәтен өйрәнгән тарихчы Гасыйм Мансуровның бабасы.

24. Сәлимгәрәй мөфти – Хаҗи Сәлимгәрәй бине Шаһингәрәй Тәүкилев (1806-1884), 1865 елдан гомеренең соңгы көненә кадәр Оренбург Диния нәзарәтендә мөфти булып торган.

25. Казыйлар – (гарәпчә "кади"-судья). Ислам динендәге дәүләтләрдә шәригать канунарына нигезләнеп, дини һәм дөньяви эшләрдә хөкем итүче кеше.

26. Собрание – Диния Нәзарәте. Әби патша – Екатерина Икенче указы белән 1789 елда Уфа шәһәрендә оештырылган "Оренбургское Духовное Собрание".

27. Приговор җыю – авыл общинасының барлык әгъзаларына да кагылышлы уртак эш (мәсәлән, имам сайлау, мәчет салу яки аны ремонтлау һ. б. ) мөнәсәбәте белән ир-атларның имзаларын җыю.

28. Габделкәрим углы Җәмалетдин (1807-1870) – Бубый авылының бишенче имамы.

29. Минзәлә өязе, Чебенле авылы – ?

30. Иманкол Мәхмүд углының кызы Бәдрелбәнат – Гобәйдулла, Габдулла һәм Мөхлисә Бубыйларның әниләре.

31. Ягъкуб хәзрәт – Тирсә авылының имам һәм мөдәррисе Мансуров Ягъкуб Нигъмәтулла углы.

32. Бәдретдин Җәлалетдин углы (? – 1890) — Бубыйларның әтиләренә туганнан туган кардәш тиешле. 1869 елдан Бубыйда имам, хатыйб һәм мөдәррис.

33. Түнтәр – хәзерге Татарстан Республикасының Балтач районындагы авыл.

34. Шәмсетдин бине Рәхмәтулла (?-1876) — Шиһабетдин Мәрҗанидә аның хакында болай язылган:"Тумышы белән Малмыж

өязенең Мазар Асты авылыннан. Кечкенә вакытында Түнтәр мәдрәсәсенә укырга килеп гыйлем ала һәм камиллеккә ирешә. Әхлак ягы, бөтен хәрәкәте һәм яшәве белән ишанга охшау сизелеп тора иде. Алдан күрүчән, саф һәм белемле иде. Яхшы китапларга ия булып, күп укый һәм дөрес фикер йөртә торган кеше иде. Гали ишанның шәкерте, кияве... Ишан вафатыннан соң үзе генә калып, милкенә дә эшләренә дә хуҗа булды. 1292 (1875) елда хаҗга китеп, 1293 (1876) елда шуннан кайтканда, Истанбулда вафат булды".

35. Әбүҗаһилләр, Әбүләһәпләр янына китте – Әбүҗаһил, Әбүләһәп—Мөхәммәд пәйгамбәргә Мәккә шәһәрендә ислам динен таратуда төрле киртәләр корган, комачаулаган тарихи шәхесләр. Иң зур зыян китергән Әбүҗаһил Мөхәммәд пәйгамбәрнең әтисенең туган кардәше. Бәдретдин Җәлалетдиннең дә изге эшләргә аяк чалуын, Г. Бубый Әбүҗаһилләр гамәле белән тиңләп, образлы итеп, үз ишләре янына (тәмугка) китте, дип яза.

36. Мөхәммәдьяр мөфти – Мөхәммәдьяр Мөхәммәдшәриф углы Солтанов (1827-1915). Казан университетының юридик факультетын тәмамлаган. Төрле кантоннарда урядник, башлык булып торган. 1866 елда подпоручик дәрәҗәсенә житеп гаскәри хезмәтне куйган. Соңыннан Бәләбәй өязендә мировой посредник булып эшләгән. 1886 елда патша тарафыннан Оренбург мөфтилегенә расланган һәм Диния нәзарәте тарихында бишенче мөфти булып, вазифасын вафатынача башкарган.

37. Әхмәджан Габделкәрим углы – (?-1908). Бубыйда эре жир биләүче, мәдрәсә урнашкан жирне вәкыф итүче.

38. Кышкар – хәзерге Татарстан Республикасының Арча районындагы авыл.

39. Ибтидаия тәртибе – белем бирү системасының башлангыч баскычы. Ибтидаи — башлангыч.

40. Зәкят – шәригать тәртипләре буенча, байлыкның ярлыларга һәм дин файдасына бирелергә тиешле кырыктан бер өлеше.

41. Фидия – вафат булган кешенең гөнаһын йолып алу өчен бирелгән мал (йолым).

42. Шиһаб хәзрәт – Шиһабетдин Мәржани (1818-1889), - мәшһүр татар мәгърифәтчесе, тарихчы галим, дин, фәлсәфә белгече.

43. Түнтәр Ишми – Ишмөхәммәд Динмөхәммәдев (1839-1919) — Түнтәр авылы мулласы, төрле мәсьәләләргә караган китаплар авторы.

44. "Тәрҗеман" – 1883-1918 елларда Бакчасарайда чыгып килгән төрки-татар газетасы, мөхәррире – Исмәгыйль бәк Гаспринский (1851-1914).

45. Грек-төрек сугышы – 1897 елда Крит утравы өчен булган сугыш. Грециянең жиңелүе белән тәмамлана. 1897 елның 4 декабрендә ике арадагы солыхка кул куела.

46. "Сәрвәтел-фөнун" – Төркиядә чыккан газета.

47. Ысуле жәдид – яңа ысул белен укыту системасы.

48. Гобәйдулла Мөхәммәдфәйзи – Бу турыда Җ. Вәлиди болай дип яза:"Аның чын исеме — Гобәйдулла, ә Фәйзи төрек өстәмәсе (мәхләс). Төрекләрдә һәрбер, азмы-күпме танылган яки укымышлы кешенең өстәмә исеме бар, шул ук вакытта ул, бездәге фамилия ролендә йөри.

Төркиядә укыган татар шәкертләре дә шундый өстәмә исемнәр белән купшыланырга яраталар". ("Очерк истории образованности и литературы волжских татар (до революции 1917 г.") - М. -Петроград: Госиздат, 1923. - С. 81.

49. Мулла Җәлал – Җәлалетдин Дәвәни. Атаклы ислам белгече, догматика буенча китаплар авторы.

50. "Мәктәбе милкияи шаһанә" – Төркиядә солтан карамагындагы хосусый уку йорты.

51. Бөре өязе Сәйтәк авылы – хәзерге Башкортстан республикасында.

52. Борай авылы – хәзерге Башкортстан республикасында.

53. Игъдадия – мәдрәсәдә югары белем алуга хәзерләү класслары

54. Әгерже Каюм мулланың атасы Фәттах мулла Халиков – Габделфәттах Габделхалитов. 1868 елдан башлап Әгерженең 1 нче җамигъ мәчетендә имам-хатыйб вазыйфасын башкарган.

55. Вәкыф – берәр кешенең үз милкеннән җәмәгать файдасы өчен биргән малы.

56. Рөшдия – ибтидаидән югарыгы сыйныф.

57. Уфада рәсми җәмгыять – 1905 елның апрелендә Уфа шәһәрендә Диния нәзарәте каршында мөселман руханиларының һәм татар зыялыларының зур җыелышы уздырылган.

58. Шам – Димәшкъ шәһәре.

59. Татарча хотбә – Г. Бубыйның 1908 елда Казанда "Татарча хөтбә уку дөрестме?" дигән китабы да басылып чыккан.

60. Әнкәй – Бәдрелбәнат Имәнкол кызы Нигъмәтуллина (1909 елда Иж-Бубыйда вафат). Гобәйдулла, Габдулла һәм Мөхлисә Бубыйларның әнисе.

61. Фәтва чыгару – нинди дә булса бер эшнең, дини яктан, шәригать буенча дөресме-түгелме икәнлеге хакындагы күрсәтмә.

62. Каракүл – хәзерге Пржевальск шәһәре.

63. Пишпәк – хәзерге Кыргызстанның башкаласы Бишкәк шәһәре.

64. Касыйм – Рязань өлкәсендәге Касыйм шәһәре.

65. Зайсан – Казакъстанда Зайсан күле янындагы поселок.

66. Абзыйның җәмәгате Нәсимә – Гобәйдулла Бубыйның тормыш иптәше, мөгаллимә.

67. Хөснефатыйма (1884-1941) — Габдулла Бубыйның тормыш иптәше Хөснефатыйма Гыйззәтулла кызы Бубый (кыз чагындагы фамилиясе Гыйззәтуллина). Бубыйда, Голҗада мөгаллимәлек иткән.

68. Мөхлисәнең Троицкига китүе – Мөхлисә Бубый (1869-1937) 1912 елда Бубыйда хатын-кызлар мәктәбе ябылгач, Троицкига китә һәм Габдрахман Әхмәрев тарафыннан ачылган кызлар мәктәбендә мөгаллимә вә мөдирә вазыйфасын башкара.

69. Каргалы – Оренбург шәһәреннән 25 чакрым ераклыкта урнашкан, үзенең мәдрәсәсе белән дан казанган зур татар авылы.

70. Мордыбый – хәзерге Татарстанның Әгерҗе районындагы Мордывый авылы.

71. Оренбургта "Хөсәения" мәдрәсәсе – XX йөз башында дан тоткан татар мәдрәсәләренең берсе, 1889-1918 елларда эшләгән.

72. Фәйзулла Мөхәммәд — Иж-Бубый мәдрәсәсендә укыткан Төркия гражданины. Чыгышы белән татар, XIX гасырда Төркиягә күчеп киткән татар-мөһаҗирләр гаиләсендә туган.

73. Габдулла Фәхри (1923 елда вафат булган) — журналист, мөгаллим. Истанбулда медицина мәктәбе тәмамлаган. "Хөсәения" мәдрәсәсендә, соңрак Бубыйда укыткан.

74. "Хөсәения"нең 35-40 шәкерте килделәр — Бу хакта, Казанда 1907-1909 елларда чыккан "Әл-Ислах" газетасының 1908 ел, 48 нче санында (13 октябрь) "Мәдрәсәи Хөсәениядә"н чыккан 33 шәкерттән аталарына ачык хат" басыла. Анда шәкертләрнең "Хөсәения"дәге тәртипләр белән килешмәүләре хакында язылa һәм ахырында болай диелә: "28 шәкерт туры Бубыйга китәр өчен вокзалга китәбез. Калганнарыбыз русча укырга китә. Бубыйга киткәннәребез: Рәхимҗан Атнабаев, Габделхәбир Габдеррәшитев, Гаяс Максудов, Габдулла Мостакаев, Әюп Мирсәлимев, Җиһанша Габдиев, Габдулла Мохтаруллин, Әхмәд Мәүлүдев, Сәлимгәрәй Гыйльметдинев, Габдулла Габдуллин, Мөхәммәдсәед Яруллин, Закирҗан Сиражетдинев, Гаясетдин Сәйфетдинев, Ислам Мәмлиев, Салих Әхмәдев, Хәйрулла Мифтахетдинов, Бәдретдин Фәтхуллин, Зариф Фәхретдинев. Хәсән Мирсәлимев, Хәмзә Мөхәммәдев, Тәрҗеман Диванов, Хаҗимохтар Гомәрев, Ибраһим Галимов, Хәлиулла Яруллин. Әхмәдфуад Айтигин, Садрый Вәлидев, Мөхәммәдвафа Габдиев.

Вәкилләре: Рәхимҗан Атнабаев, Габдулла Мостакаев".

Шул ук "Әл-Ислах" газетасының 49 санында (26 октябрь, 1908) язылганнар да игътибарга лаек. "Сентябрь 23ендә мәдрәсәи Хөсәения"дән 33 шәкерт Бубый мәдрәсәсенә китте. Шулкадәр вәкыфләр, бай мөтәвәллиләр белән матди җәһәте тәэмин ителгән, бөтен Русия татарлары күз тегеп торган бер мәдрәсә, үзенең иң иҗтиһадлы [тырыш] шәкертләрен икънагъ итә [канәгатьләндерә] алмады... Шәкертләр Бубый мәдрәсәсенә киттеләр. Бу ни дигән сүз? Зур бер шәһәрнең электриклар белән яктыртылган, зур вәкыфләр белән тәэмин ителгән мәдрәсәсеннән бу хасиятләрнең берсенә дә малик [ия] булмаган, бер авыл мәдрәсәсенә баралар... Гомерләрен коткарыр өчен шул бер кечкенә авыл мәдрәсәсенә качалар! Шул бер-ике, өч гайрәтле, эшлекле, зыялы татар яшьләре тарафыннан иҗат ителеп тә, аз бер микъдар акча белән идарә ителә торган мәктәпләр хәзер үзенә укырга тели торган яшь татарларны җәлеп итә, монда ни хикмәт соң? Бу нинди "фатиха" бәрәкәте соң? Эшлекле зыялылар эш башында булгач, кечкенә бер авылда, бер-ике әһел һиммәте сәясендә [бер-ике кеше тырышлыгы нәтиҗәсендә] үзенә укырга теләүче яшьләрне җәлеп итәрлек мәктәп вөҗүдкә [барлыкка] килеп тәрәккый итте, итә һәм (халкыбыз тәкъдир итә ала башласа) итәчәктер.

75. Әхмәдфаиз Сөләйман углы Даутов (1871 - ?) — мөгаллим, гарәп теле белгече. Мәдинә шәһәрендә мәдрәсә тәмамлаган. Русиягә кайткач Троицки һәм Оренбург мәдрәсәләрендә, 1909 елдан башлап Бубыйда гарәп телен, әдәбиятын укыткан.

76. Мәктәп көтепханәсе — Бубый мәдрәсәсенең шактый бай китапханәсе булган. Аны төрле китаплар, газета-журналлар белән баетуда мәдрәсә идарәсе зур тырышлык куйган. Шулай ук төрле нәшриятлар да

мәдрәсә китапханәсенә күп санлы китаплар бүләк итә торган булганнар. Мәсәлән, Орск шәһәрендәге татар басмаханәсе хуҗасы Әхмәд Исхакыйга Бубый мәдрәсәсе китапханәсенә бүләк иткән китаплары өчен "Әл-Ислах" газетасында (1908, 20 нче сан) Бубый шәкертләре исеменнән рәхмәт игъланы басылган.

Мәдрәсә китапханәсеннән тентү вакытында алынган китаплар арасында мондыйлары да бар: М. Гафури "Милли шигырьләр"; Нежданов "Хезмәт һәм капитал"; төрек телендә "Интернациональ партияләр"; "Француз революциясе" һ. б. һ. б.

77. Капал – Копал. Казакъстанның Талды-Курган өлкәсендәге поселок.

78. Бозаулык – элекке Самара губернасы (хәзерге Оренбург өлкәсендәге) Бозаулык шәһәре.

79. Галиәсгар Чыгытай-Гафуров (1867-1942) – Бозаулык мулласы, язучы һәм журналист. 1920 — 30 нчы елларда дингә каршы рәхимсез көрәш ачкан "Фән һәм дин" (Мәскәү) исемле журналның редакторы була.

80. "Исабәт" – хакыйкатькә ирешү, Коръәнне дөресләү мәгънәсендә. Бу китап ислам динен, Алланы, Мөхәммәд һ. б. пәйгамбәрләрне шактый нык тәнкыйтьләп чыга. Диннең, Коръәннең күктән иңүен кире кага, ислам диненең килеп чыгуын, нигезләрен Г. Чыгытай стихияле материалист буларак тикшерә. "Исабәт" тирәсендә матбугатта, динчеләр арасында зур шау-шу күтәрелә. Диния нәзарәте Чыгытайның указын ала. Шуннан соң Чыгытай үзенең китабыннан баш тарта һәм башка ике кисәгенең бастырылмаячагын белдереп тәүбә итә. Аның тәүбә хаты "Йолдыз", "Вакыт" газеталарында, "Мәгълүмат" журналында басылып та чыга. Чыгытайның мондый аумакайлыгы үз вакытында Г. Тукай, Фатих Әмирхан һ.б. яшь әдипләр тарафыннан күп тәнкыйтьләргә дучар була.

81. Протест һәм нәфрәт белдердек – "Йолдыз" газетасында (1909, 476 сан, 2 декабрь) Гобәйдулла, Габдулла Бубыйлар, мөгаллимнәрдән Фәйзулла Мөхәммәд, Г. Фәхри, М. Галиев, Габделхак, Габдессамад, Садыйк, Әхмәтшәриф, Фаиз имзалары белән "Исабәт хакында исабәт" дигән мәкалә басылып чыга.

Бубый мөгаллимнәренең бу язмасын Ф. Әмирхан "Идел" газетасында (1909, 214 сан, 22 декабрь, 1910, 220 сан, 12 январь) "Затымызга монасыйб сыйфатларымыз" исемле мәкаләсендә бик ачы тәнкыйтьли. Галимҗан Ибраһимов та соңрак чордагы язмаларында, җае чыккан саен Бубыйларны бу эшләре өчен начар яктан телгә ала, тозлап-борычлап сүгә. Әмма Габдулла Бубыйның "Әгәр без бу китап хакында бер нәрсә язмасак, дәшмәсәк, ул вакыт бу китапның зарары бөтен яңаларга җитәчәк иде" дигән фикеренә игътибар итәргә кирәк. Бубыйлар бөтен яңалар, җәдитчеләрне, алдынгы фикерне кадимчеләр һөҗүменнән яклап калу өчен язганнар да. Бубыйларның үткен сәясәтче, дипломатик алымнар, алдан күрә белүчәнлек хасиятләренә ия булганлыклары шушы фикер белән тагын бер кат раслана.

82. Инспектор – Русиядә мәгариф системасының халык мәктәпләре белән шөгыльләнүче рәсми чиновник.

83. Исправник – жандарм идарәсенең өязләрдә эшләүче рәсми чиновнигы.

84. 1910 елда Петербургта... җәмгыять – 1910, 1914 елларда Петербургта Мәгариф министрлыгы, Эчке эшләр министрлыгы, Синод чиновниклары панисламизм турында фикер алышу өчен махсус киңәшмә уздыралар. Бу киңәшмәнең "Журнал Особого Совещания" исемендәге җыентыгы да басыла.

85. Малов – Малов Е.А. (1835-1918). Төрки телләр белгече, миссионер, Казан Духовный Академиясе төрки-татар бүлегенең профессоры булган.

86. Рәхимҗан Атнабаев, Юныс Вәлидев – Бубый мәдрәсәсендә белем алып чыккан мөгаллимнәр. Ю. Вәлидев (1929 елда вафат) совет чорында җир эшләре буенча Татарстанның беренче наркомы.

87. Беренче дәрәҗә мөкяфәт – мәдрәсәне бик яхшы билгеләргә тәмамлаган, дигән мәгънәдә. Гаяс Максудов – Максудов Гаяс Гыйсам улы (1891-1942). Төркиядә лицей тәмамлагач, 1913 елда Бельгиядәге Льеж университетына укырга керә һәм ике курсын уңышлы тәмамлый. Танылган математик. 1920 нче елларда Татнаркомпрсста эшли, 1922-25 нче елларда Академия үзәгенең рәисе, "Мәгариф" журналының мөхәррире, 1937 елда НКВД тарафыннан кулга алына һәм 1942 елда лагерьда вафат була.

88. "Сыйрател-мөстәкыйм" – Төркиядә нәшер ителгән атналык фәнни, әдәби журнал.

89. Хәлим Сабит – Төркиянең XX йөз башында танылган журналистларыннан берсе, "Ислам мәҗмугасы" журналы мөхәррире.

90. Солоник – ул чорларда Төркия кулы астында булган Солоники шәһәре.

91. Габдеррәхим Габденнасыйров (1918 елда вафат) – Әгерҗе авылының имамы һәм мөдәррисе.

92. Әхмәд Тимкин – Әгерҗе авылы сәүдәгәре. Әгерҗе мәчете һәм мәдрәсәсе матди яктан аның тарафыннан тәэмин ителгән.

93. Риза казый – Ризаэтдин Фәхретдин (1859-1936). Мәшһүр татар тарихчысы, галим, ислам белгече, публицист. 1908-1917 елларда Оренбургта татар телендә чыккан фәнни, әдәби, иҗтимагый "Шура" журналының мөхәррире.

94. Дарелмөгаллимин – мөгаллимнәр хәзерли торган уку йорты.

95. Әхмәд хаҗи – Әхмәд Тимкин.

96. Садыйк Галикәев – Казанда Яңа Бистәдә яшәгән эре татар сәүдәгәрләреннән.

97. Галия, Ситдыйка – Габдулла Бубыйның кызлары.

98. Фидаи, Зыяи – Гобәйдулла Бубыйның уллары.

Әхмәуфаиз Сөләйман улы Даутов (1871 — ), мөгаллим. Гарәп теле белгече. Мәдинә шәһәрендә мәдрәсә тәмамлаган. Русиягә кайткач Троицк һәм Оренбург мәдрәсәләрендә, 1909 елдан башлап Бубыйда гарәп телен, әдәбиятын укыткан.

99. Коддус Габдрахманов – Бубый мәдрәсәсен тәмамлаган мөгаллим. Бер ел чамасы (1906 елда) Каһирә һәм Константинополь шәһәрләрендә гарәп теле буенча белемен камилләштергән.

100. Безгә каршы шәһадәт бирделәр – 1911 елның 2 март көнендә допрос вакытында Фаиз Даутов "мәдрәсәдә хөкүмәткә каршы пропаганданың төп сәбәпчеләре — бертуган Бубыйлар" дигән мәгълүмат бирә. Соңыннан үзенең шәһадәтләрен үзгәртә, объективрак бирергә тырыша. Әмма жандарм чиновниклары беренче шәһадәтенә генә игътибар итәләр.

Коддус Габдрахмановның Бубыйларга каршы биргән шәһадәтләре архивта табылмады, бәлки аның шәһадәтләрен Сөнгатулла Гарифуллин шәһадәтләре белән бутаганнардыр.

С. Гарифуллин Казанда Татарская учительская школаны тәмамлаган, Әгерҗедәге рус-татар мәктәбенең укытучысы булган. Аның жандарм идарәсенә биргән шәһадәтләре Бубый мәдрәсәсенә һәм Бубыйлар эшенә каршы юнәлтелгән.

101. Вятка – хәзерге Киров шәһәре.

102. Хафиз Сәйманов – Әхмәдхафиз Сәйманов. Чыгышы белән Уфа губернасының Тәкермән авылыннан, типтәр сословиесеннән.

103. 102 статья – дәүләткә, хөкүмәткә каршы алып барылган эш һәм пропаганда турындагы статья.

104. Панисламизм – Көнбатыш илләре тарафыннан Көнчыгышны колонизацияләүгә каршы XIX гасырда башланган көрәшү өчен мөселман халыкларын рухи бердәмлеккә өндәгән идея-сәяси тәгълимат. Бу өйрәтмәнең нигез салучысы булып Җәмалетдин Әл-Әфгани (1839-1897) санала. Панисламизм – милли азатлык идеологиясенең бер формасы. Патша Россиясендәге рәсми оешмалар, бигрәк тә жандарм идарәсе, бу тәгълиматны бөтендөнья мөселманнарын сәяси яктан берләштереп, бер дәүләт оештырырга омтылыш, рус дәүләтенә каршы булган бер хәрәкәт, дип ялган рәвештә аңлаткан. Панисламизмга каршы көрәш исеме астында жандармерия Русиядәге алдынгы мөселман фикер ияләрен, шул исәптән татар зыялыларын да, эзәрлекләгән.

105. 103 нче пункт – император (патша) галиҗәнапләренә тел тидерү, аны кимсетү хакындагы статья.

106. 132 нче пункт – китап яки вакытлы матбугат органнарын властьларга каршы һәм хөкүмәткә каршы фикер уздыру өчен файдалану турындагы статья.

107. Егоров – адвокат.

108. Бать – Бать А.Г., Казанның присяжный поверенные.

109. Ибраһим Әхтәмев (1880-1931) — юрист, адвокат, 1903 елга хәтле "искра"чы, соңыннан меньшевик-социалист.

110. Маклаков – Маклаков В.А. (1869-1957), адвокат, кадетлар фиркасенең лидеры. 2, 4 нче Дәүләт Думалары әгъзасы. 1917 елда Франциядә Русия илчесе. Соңыннан эмиграциягә китә. Русиянең иҗтимагый фикер тарихына багышланган фәнни хезмәтләр язган галим.

111. Аппаков – Шәһимәрдан Аппаков. Иж-Бубый авылы крестьяны, отставкадагы солдат, кечкенә кибет хуҗасы. Бубыйларга каршы шәһадәт биргән кешеләрдән.

112. Ардашев – Ардашев Александр, рус, итекләр тегүче. 4 яшеннән Иж-Бубыйда торуы сәбәпле татар телен бик яхшы белгән. Бу елларда Бубыйда тагын ике рус гаиләсе яшәгән. Ардашев, шаһит буларак, Бу-

быйлар патшага каршы шәкертләр арасында пропаганда алып баралар дип шәһадәт биргән.

113. Аппаков углы – Мөхәммәд Аппаков, Бубый мәдрәсәсе шәкерте, Шаһимәрдан Аппаковның улы.

114. Ишмөхәммәд мулла – сүз Ишми ишан турында бара.

115. "Марсельеза" – француз революцион җыры, Франциянең дәүләт гимны. "Марсельеза"ның сүзләре һәм музыкасы XVIII гасыр ахырында, француз буржуаз революциясе елларында, 1792 елның 26 апрельгә каршы төнендә хәрби инженер К.Ж. Руже де Лиль тарафыннан иҗат ителгән.

116. Катанов – Катанов Николай Федорович (1862-1922), атаклы тюрколог-галим, чыгышы буенча хакас, профессор. Казан университетында, Казанның Духовная Академиясендә укыткан, Жандарм идарәсенең үтенече буенча Жузе белән бергә, тентү вакытында конфискацияләнгән китап, кулъязмалар, журналларны тәрҗемә иткәннәр.

117. Жузе – Жозе Пантелеймон, (1871), атаклы шәрыкны өйрәнүче галим. Чыгышы буенча — Сүрия гарәбе. Казанда Духовное Академиядә гарәп һәм француз телләрен укыткан.

118. Казанның Мөхәммәджан Хафиз – Мөхәммәджан Әхмәрев, Казан сәүдәгәре. Иске фикерле кеше буларак танылган. Аның сатирик образы татар әдәбияты классиклары иҗатында да еш очрый.

119. Арыслан Моратов – Арыслангәрәй Моратов (1865-?), укытучы. Шаһит буларак, допрос вакытында Бубыйларга каршы шәһадәт бирүчеләрдән.

120. Нәҗип Думави – Туктамышев Нәҗип (1883-1938), танылган татар шагыйре, мөгаллим. Бубый мәдрәсәсе ябылгач, беренче бөтендөнья сугышында катнаша, балалар укыта.

121. Меньшиков Н. – Вятка губернасының Сарапул өязендәге халык уку йортлары инспекторы.

122. "Мең бер хәдис" – бу исемдәге китап Казанда беренче тапкыр 1906 елда, Кәримевләр матбагасында, Шәриф бәй шәрхе-аңлатмасы белән басылган. 1907 елда Петербургта Габдеррәшит Ибраһимовның царизм сәясәтенә каршы үз фикерләрен үткәрергә тырышкан шәрехаңлатмасы белән яңадан басылып чыга һәм 1911 елда цензура тарафыннан дәүләткә каршы юнәлтелгән дип табыла, конфискацияләнә. Шуңа күрә бу китапның мәдрәсә китапханәсендә табылуы, жандарм ротмистрына, Бубыйларны гаепләү өчен өстәмә сәбәп булган.

123. Мәктәпләр ябылды... – бу хакта "Йолдыз" газетасында "Бубый мәктәпләренең ябылуы" дип исемләнгән мондый хәбәр басылган: "Бубыйдан идарәбезгә язылуына күрә: 18 нче гыйнварда Вяткада булган мөшавәрә (киңәшмә) мәҗлесе, Бубыйдагы ирләр һәм кызлар мәктәпләрен ябарга карар биргән. Директор Вяткадан бу карарны телеграм илә инспекторга белдергән. Инспектор моны Бубыйга хәбәр биреп, 21 нче гыйнварда ирләр һәм кызлар мәктәпләре ябылган. Сәбәбе хәзергә мәгълүм түгел икән. Мәктәпләрнең ябылуы укудагы балалар өчен бик уңайсыз булган вә халыкка бик начар тәэсир иткән". ("Йолдыз". 1912. № 796. 21 февраль).

124. Мөхлисә Троицкига китте... - 1912 елда кызлар мәктәбе ябылгач, көз көне Мөхлисә Бубый Тройскига китә. Анда Габдулла Әхмәрев тарафыннан 1910 елда ачылган мәктәпкә мөгаллимә булып урнаша.

125. Габдулла Әхмәрев — атаклы фабрикант Яушевларның приказчигы, алдынгы карашлы татар зыялысы. Үзбәкстанның халык рәссамы Чыңгыз Әхмәревнең атасы.

126. Яркәнд — Кытай халык республикасындагы Яркәнд (Шачэ) шәһәре.

127. Гаспринский — Исмәгыйль Гаспринский (Гаспралы) (1851-1914), бөтен төрки, мөселман дөньясында атаклы мәгърифәтче, Русиядә җәдидчелек хәрәкәтен башлап җибәрүчеләрнең берсе, Бакчасарай шәһәрендә чыккан "Тәрҗеман" (1883-1918) газетасының нашире һәм мөхәррире. Чыгышы белән кырым татары. Мөселман мәктәпләрендә аваз ысулы белән укытуны беренче булып оештырган.

128. Газеталарның... кара нумерлары — И. Гаспринскийның вафатын хәбәр иткән татар газета-журналлары. Гаспринский 1914 елның 12 сентябрендә вафат була. Аның вафаты мөнәсәбәте белән "Тәрҗеман" газетасында йөзләгән тәгъзиянамә (хәсрәт уртаклашу телеграммалары, хатлары) басыла. Алар арасында "Голҗа мөселманнары" имзасы белән газетаның 18 октябрь (№ 214) санында мондый телеграмма басылган (теле җинелләштерелде): "Исмәгыйль бәкнең вафаты без, Голҗа мөселманнарының күңелләрен бик нык тетрәндерде. Мәрхүмгә Аллаһының рәхмәтен, якыннарына зур сабырлык телибез".

129. "Хуҗаи сыйбъян" — аваз ысулы белән укыту буенча И. Гаспринский язган дәреслек. Беренче басмасы 1890 елда нәшер ителгән.

130. Мисыр... Һиндстанга чаптың — 1907, 1908 елларда И. Гаспринский Мисырга барып кайта. Анда җәмәгатьчелек алдында чыгышлар ясый. 1906 елда Мисырда гарәп телендә, Русия мөселманнарының хәлен яктырта торган "Ән-Нәһзәтү" (Яңарыш) газетасын оештыра. 1911 елда исә Һиндстанга барып андагы мөселманнар арасында ысуле җәдидне пропагандалый, бу ысул белән дәресләр бирә.

131. Төркичә газета — сүз "Тәрҗеман" хакында бара.

132. Хөррият — ирек. Монда 1917 елның февраль революциясе күздә тотыла.

133. Гариф Габид, Ситдыйк Юски, Йосыф Хуҗасәед, Йосыф Лаеш, Гани шәкерт, Фатыйма Янсыб Мәсгуд әфәнде, Шакир Юашев — Бубыйлар гаиләсе белән Голҗада яшәү дәверендә якыннан аралашкан, хезмәттәшлек иткән мөгаллимнәр, татар зыялылары.

134. Кәбир Бәкер (1880-1941) — журналист, язучы, драматург, театр тәнкыйтьчесе, Габдулла Тукайның дусларыннан. Октябрь революциясеннән соң Ташкентта чыккан "Олуг Төркестан" газетасының мөхәррире.

135. Садрый Максуди — Садретдин Низаметдин улы Максудов (1878-1957), татар иҗтимагый хәрәкәтенең лидерларыннан берсе, Парижда университет тәмамлаган. Дәүләт Думасы әгъзасы. Эмиграциядә, Төркиянең Истанбул университетында профессор булган.

136. Баттал — Габделбарый Габдулла улы Сәетбатталов (1873-1959), тарихчы, әдәбият белгече, публицист. Октябрь революциясеннән соң

эмиграциягә китә. Анда да фән белән шөгыльләнә, төрки-татарлар тарихына кагылышлы хезмәтләр авторы.

137. Сөнгатулла Бикбулат – Сөнгатулла Нигъмәтулла улы Бикбулатов (1886-1954), Оренбургтагы "Хөсәения" мәдрәсәсендә мөгаллим булган, ислам тарихы белгече, фәнни хезмәтләр авторы. Революциядән соң Казан университетында гарәп теле укыткан.

138. Бу уңайдан газеталарда түбәндәге хәбәрләр чыккан:

"4 нче апрельдә русча-татарча мәктәп бинасында булган Ташкент татарларының гомуми җыелышында... "Иттифак" җәмгыяте ачылды... Җыелган халык имамлыкка Габдулла Бубый җәнабләрен чакырырга тиеш табып, шунда ук срочный телеграм җибәрде. Габдулла Бубый җәнабләре җавабында үзенең май аенда Ташкәндә булачагын белдергән".

("Олуг Төркестан".– 1917.– 25 апрель (№ 1).

"14 май көн "Иттифак" җәмгыятенең гомуми җыелышы булды... Җыен Габдулла Бубый белән сөйләшеп, аны ничек тә булса, Ташкәндтә алып калырга идарә әгъзаләренә тапшырды".

("Олуг Төркестан".– 1917.– 20 май (№ 6).

139. Борһан Шәрәф – Борһан Шәрәфетдин улы Шәрәф (1883-1942), журналист, әдәбият тәнкыйтьчесе. Татар телендә чыккан "Казан мөхбире", "Вакыт", "Аң", "Шура", "исемле газета-журналларның редакцияләрендә эшләгән. Революциядән соң "Оренбург хәбәрләре" газетасының редакторы. Утызынчы елларда Ташкентта, Карагандада, Алма-Атада нәшрият органнарында эшли.

140. Харис Фәйзи – Харис Зариф улы Фәйзуллин (Харис Фәйзи-Чистапули, 1870-1933). 1907-1908 нче елларда "Әхбар" исемле газета оештыра. "Хөсәения" мәдрәсәсендә төрле фәннәр укыта, күп санлы дәреслекләр авторы. Октябрь революциясеннән соң "Кызыл Татарстан" газетасында эшләгән. Күренекле татар композиторы Җәүдәт Фәйзинең атасы.

141. Габделхәмид Мөслими – Габделхәмит Гатаулла улы Мөслими, шул чор татар вакытлы матбугатында укыту-тәрбия мәсьәләләренә караган күп санлы мәкаләләре белән катнашкан мөгаллим. Соңыннан Эстәрлетамак, Уфа шәһәрләрендә укытучы булып эшләгән.

142. Галимҗан хәзрәт – Галимҗан Мөхәммәдҗан улы Галиев-Баруди (Галимҗан Баруди, 1859-1921), күренекле дин галиме, имам-хатыйб, Казандагы "Мөхәммәдия" мәдрәсәсенең оештыручысы һәм җитәкчесе. Казанда чыккан "Әд-дин вәл-әдәп" (1906-1908, 1913-1917) журналының нашире һәм мөхәррире. 1917 елда Диния Нәзарәте тарихында беренче тапкыр тавыш бирү юлы белән сайланган мөфти. Коръән, хәдис, гомуми ислам мәсьәләләре буенча китаплар һәм мәкаләләр авторы.

143. Зариф Хөсәен улы Әмирхан (1852-1921) – Казан мулласы, милли, мәдәни, дини хәрәкәттә прогрессив роль уйнаган шәхес. Күренекле татар язучысы Фатыйх Әмирханның атасы.

144. Салихҗан Мөхәммәдҗан улы Галиев – Казан мулласы, җәдидче, Галимҗан Барудиның бертуган энесе.

145. Мөфтилеккә сайлау мәҗлесе — мөфти Бөтенроссия мөселманнарының Беренче Корылтаенда, 1917 елның 1-11 маенда Мәскәүдә сайлана.

146. Муса Бигиев — Муса Ярулла улы Бигиев (1875-1949), ислам философы, гарәп әдәбияты белгече. Революциядән соң Петербург ахуны. Соңыннан эмиграциягә китә, күп фәнни, фәлсәфи хезмәтләр авторы. Язучы Заһир Бигиевнең туганы.

147. Зыя Кәмали — Пәрвәзетдин Җәмалетдин улы Кәмалетдинев (1878-1942), ислам философы. Каһирәдә "Әл-Әзһар" университетын тәмамлагач, Уфага кайтып, 1906 елда "Галия" мәдрәсәсен оештыра. Мәдрәсә 1906 елдан 1916 елга кадәр эшли. Атаклы мәгърифәтче-педагог, фәлсәфи хезмәтләре белән танылган галим.

148. Ягъкуб Хәлил — Ягъкуб Ибраһим улы Хәлили (1877-1945), тумышы белән Бубый авылыннан. 1910-1917 елларда Казанда чыккан "Сөембикә" исемле хатын-кызлар журналының мөхәррире. Дәреслекләр авторы. Революциядән соң төрле оешмаларда, нәшриятта эшли, Буада китап кибете мөдире булып тора, Казанда китапханәче вазыйфасын башкара. 1937 елда кулга алына.

149. Нияз әфәнде — Нияз Максудов, Америкада укып кайтып, Троицкидагы Яушевлар мәктәбендә мөгаллим булып эшләгән. Революциядән соң эмиграциягә киткән.

## Габдулла Бубыйның "Бубый мәдрәсәсенең кыска тарихы" хезмәтендә телгә алынган дәреслекләр һәм дәрес атамалары

(Куштырнаклар эчендә күрсәтелгән китаплар башлыча кадим (иске тип) мәдрәсәләрдә дәреслек буларак кулланылганнар)

Әгъмале әрбәга — арифметикада дүрт гамәл (алу, кушу, бүлү, тапкырлау).

Әлифба.

"Әнмүзәҗ" — гарәп теле синтаксисы буенча дәреслек.

"Әсраре тәсауыф" — фәлсәфә буенча.

Әхлак (гамәли-практик, назари-теоретик).

"Ахунд Йосыф" — ислам тәгълиматына багышланган әсәр.

Бәлягать — дөрес сөйләү кагыйдәләре, орфоэпия.

Бәлягате төркия — төрки (татар) теленең сөйләм кагыйдәләре.

Вөҗүде бәшәр — кешелекнең, тереклекнең килеп чыгуы.

"Гавамил" — гарәп теле синтаксисы буенча дәреслек.

"Гайнел-гыйлем" — дини-әхлакый китап.

"Гакаид" — Аллага ышану, инануның нигезләрен бәян иткән китап.

Гарәп нәхүе — гарәп теле синтаксисы.

Гарәп сарыфы — гарәп теле морфологиясе.

Гарәп теле.

Гарәп әдәбияты.

Гасры сәгадәт – пәйгамбәрләр заманы тарихы.
Голуме гарәбия – гарәп теле буенча гыйлемнәр.
Гыйльме сәрвәт – экономика.
Гыйльме халь – ислам гыйбадәтләрен, нигезләрен эзлекле рәвештә аңлата торган дәреслек.
Гыйльме әшья – физика.
Җәбер – алгебра.
Җәгърафия.
Җәгърафияи гыймрани – география.
"Җамигыйр-рөмуз" – "Мәхтәсарел-викая" исемле гарәпчә дини-әхлакый һәм хокук мәсьәләләрен эченә алган китапка шәрех, ягъни аңлатмалар рәвешендә язылган әсәр.
"Зөбдәтел-әсрар" – фикъһ буенча дәреслек.
Игътикад – иман, инану.
Идарәи бәйтия – хуҗалык, итү.
Илаһи вә милли шигырьләр.
Имля – орфография, дөрес язу кагыйдәләре.
Имляи төрки – татар теле орфографиясе.
Инша.
Иншаи төрки – татарча инша.
"Исагуҗи", "Ногман", "Исагуҗи Ногман" – мантыйк буенча дәреслек.
"Ихъяи голум"
Кавагыйд – синтаксис кагыйдәләре.
Кавагыйде төркия – татар теленең язу кагыйдәләре.
Кавагыйде фарсия – фарсы теленең язу кагыйдәләре.
"Казый Бәйзави" – тәфсир китабы.
Карыйдан мәкам – көйләп уку.
Кафия – рифма, шигырь төзелеше.
Кимия – химия.
Коръән.
Коръән мәкам белән – Коръәнне көйләп уку.
Кул эшләре.
Кыйраәт – уку, уку кагыйдәләре.
"Кәлям" – ислам тәгълиматы.
Кәсер – арифметикадагы вакланмалар.
Мантыйк – логика.
"Мирсәед" – мантыйк китабы
"Мишкятел-мәсабих" – хәдисләр китабы.
"Мулла Касыйм" -
"Мулла Җами" – гарәп теле синтаксисы буенча.
"Мулла Җәлал" – ислам тәгълиматы буенча.
"Мәүла Җәлалетдин"
Мәгълүмате шифаһия – телдән сөйләү.
Мәкам – көй, көйләп уку.
Мөдафәга
Мөсәлләсат – тригонометрия.
Мөфассаль кавагыйде гарәбия – гарәп теле грамматикасының тулы кагыйдәләре.

"Мөхтәсар" — кыскача дини кагыйдәләр китабы.
"Мөхтәсарел-викая" — гарәпчә дини-әхлакый шәригать кануннары, хокук мәсьәләләренә багышланган китап.
"Мөхтәсар һәндәсә — кыскача геометрия.
Нәбатат — ботаника.
Нәхү — синтаксис.
Нәхү гарәби — гарәп теле синтаксисы.
Нәхүдән кавагыйд — синтаксис кагыйдәләре.
Педагогика.
Русча — рус теле.
Рәсем.
Сарыф — морфология.
Сарыфы гарәби — гарәп теле морфологиясе.
"Сахихел-Бохари" — хәдисләр китабы.
"Сиражия" — фараиз буенча.
Сияреннәби — Мөхәммәд пәйгамбәрнең холык, гадәтләре, тормышы турындагы әсәр.
Сүрәләр ятлау.
"Сөллям казый " — логика буенча дәреслек.
"Тарикаи Мөхәммәдия" — әхлак буенча дәреслек итеп кулланылган.
Тарих.
Тарихе гомуми — гомуми тарих.
Тарихе ислам — ислам тарихы.
Тарихе әнбия — пәйгамбәрләр тарихы.
Татбыйкать.
Телдән мәгълүмат.
"Тәлхыйс" — гарәп грамматикасы.
"Тәләвих" — фикъһ буенча.
Тәрбияи әүлад — балалар тәрбиясе.
Тәфсир — Коръәнгә язылган аңлатма.
"Тәүзих" — ислам дине методологиясе.
Тәҗвид — Коръәнне дөрес уку буенча орфоэпик кагыйдәләр.
Төрек теле.
Төрек әдәбияты.
Төркичә уку — татарча уку.
Төрки әдәбияты — татар әдәбияты.
Төрки имлясы — татар орфографиясе.
Фәраиз — мирас һәм варислар хакындагы шәригать кагыйдәләре.
Фикъһ — ислам дине кануннары, хокуклары фәне.
Французча.
Фәлсәфә.
Хикмәт — философия.
Хикмәте табигыя — физика, табигать белеме.
Хисап (назари-теоретик) — арифметика.
Хифзы — ятлау, күңелдән белү.
Хифзы сыйххәт — гигиена, сәламәтлек саклау.
Хәдис.
Хәйванат — зоология.
"Хөлли мөшкилят".

"Хәялый".

Холясател-хисап — кыскача арифметика.

Хөсне хатт — матур язу.

Шифаһия — телдән.

"Шәмсия", "Шәмсияи Мирсәед" – Коръәнне дөрес укырга өйрәтә торган дәреслек.

"Шәрхе Габдулла" – гарәп теле морфологиясе буенча.

"Шәрхе мулла Җами" – гарәп теле синтаксисы буенча.

Ысул, ысуле фикъһ – ислам юриспруденциясе, шәригать кануннары.

Ысуле тәгълим вә тәрбия – педагогика.

# Мөхлисә Бубый мәкаләләре

## Бубыйда кызлар өчен тәрбияханә

Читтән килгән кызлары тәрбия өчен Бубыйда тәрбияле бер кадын идарәсе тәхтендә бер тәрбияханә ачылды. Кыз башына унбиш сум вирелгәннән соң хосусый караватт, таза ятак хәзер улачак. Өстләре—башларының тазалыгына вә әдәп — әхлакларының мөселманча төзек улуына тәмам дикъкать ителәчәк. Кызларга махсус салынмыш интизамлы мәдрәсәйә якын.

Мәдрәсәдә голуме диния вә адабе исламиядән башка хисап вә тарих вә җәгърафия кеби фәннәрдән дә тәгълим вар. Эстәян улса, төрле кул эшләре дә өйрәтелер.

Варачак адәм Кама кырындагы Сарапула пароход илә варып, аннан Бубыйга илле чакрым мосафәне ат илә рәхим итсеннәр. Сентябрь ахырына кадәр мәдрәсәйә кабул улыныр.

Унбиш сумга икътидары улмайан адәмнәре шәһри йиде рубләйә кадәр махсус кызлар җыеп, ашау илә өст-башларына карый торган кадыннар бар.

[Мөхлисә Бубый].

«Өлфәт» газетасы. - 1906. - 6 сентябрь (№ 38).

килән — килгән
кадын — хатын
тәхтендә — астында
таза — чиста, пакь
интизам — тәртип, яхшы
голуме диния — дини гыйлемнәр
адабе исламия — мөселман әдәбе-әхлагы
тәгълим — укыту
эстәян — теләүче
мосафә — ара
сума — сумга
икътидары улмайан — көче житмәгән
шәһри — айлык

## Идарәгә мәктүб

Мөхтәрәм мөхәррир әфәнде!

Без бу игъланымызы газетаңызның бер йиренә сыйдырмакыңызы рижа идәмен.

Бубый каръясендә кызлар мәдрәсәсендә имтихане гомуми апрель 25 дә булачак. Голум вә мәгариф һәвәсе улан ханым әфәнделәр тәшриф идәрләрсә, мәмнүн улырмыз.

Пароход пристане Сарапулда. Бубый каръясе Сарапулдан 50 чакрым мосафәдәдер.

Бубый дарелмөгаллиматендә мөдирә

Мөхлисә Бубый.

«Әхбар» газетасы. - 1908. - 28 март (№ 45).

мәктүб — хат
рижа идәм — үтенәм
имтихане гомуми — гомуми имтихан
голум — гыйлемнәр
тәшриф идәрләрсә — рәхим итсәләр
мәмнүн улырмыз — шат булырбыз
мосафә — ераклык

## Ислам дөньясында хатыннар*

Бу кадәр күп еллардан бирле ислам диненең сәламәт сакланып торуында вә һич үзгәрми вә имгәнми безләргә килеп житүендә ирләрнең зур хезмәтләре булды. Монда шөбһә юк. Мондый ирләр берлә бу көнге ислам дөньясының ифтихар кылуы, әлбәттә, урынлы. Ләкин ислам диненең дәвам итүе вә дөньяга җәелүе хакында ирләр берлә бер сафта торып хезмәт итүче хатыннар да булды. Болар берлә дә ифтихар кылу урынсыз түгел.

Рисаләт вазыйфасын йөкләве сәбәпле, кавем-кабиләсе хәтта бәгъзе бер мәхрәм карендәшләре тарафыннан кимсетелгән вә арадан чыгарылган рәсулуллаһ хәзрәтләре гакыллы вә гафиф, сабырлы вә латыйф булган хатыны хәзрәти Хәдичәнең әсәрле вә мәгънәле тәслияләре берлә юанадыр вә үзенең вазыйфасын үтәү тугрысында моның ярдәме вә моның булышлыгы берлә файдаланадыр иде.

* Мәкалә бераз кыскартып бирелә (төз).

[...] Хезмәтләрнең зурлыгы вә азлыгы, файдалы булуы ихтыяҗга карап йөри. Дөньяда шундый урыннар вә шундый вакытлар була — башка бер урында вә башка бер заманда санга алынмый торган бер хезмәт бик кирәкле вә бик файдалы булып чыгадыр.

Безнең шушы өлкәбездә вә шушы көннәребездә хатыннарга йөкләнә торган авыр түгел, әмма үзләре бик кирәкле вә файдалы хезмәтләр бар. Шул хезмәтләрне итү алар өстенә төшкән бер бурыч. Әмма бурычны түләү чиксез рәвештә садакалар өләшүгә күрә дә файдалы вә саваплы булуында шөбһә юк.

Ул бурычлардан берсе — үзебезнең дини гадәтләребезне вә рәсемнәребезне саклаудыр.

Үзебезнең дини бәйрәм көннәребезне, җомга, динебездәге ел башы һәм дә мәүлед көннәрен гаилә башлыгы булган хатыннар вакытларыннан элек белеп торырга, көч җиткән кадәр шул вакытларда өй эчендә булганнарның күңелләрен ачарлык итеп иркенлек бирергә кирәк буладыр. Моның өчен зур мәсрафлар хаҗәт түгел. [...]

Ул бурычлардан икенчесе — тел саклау. Бу көн безнең юлга салынган вә дөньявый йомышларын гына түгел, хәтта дин вә гыйлем тугрысындагы йомышларыбызны үтәрлек үз арабызда куллана торган телебез бар.

Гәрчә арада читләрдән кергән сүзләр күп булса да, ул сүзләр инде үз малыбыз булып киткән, төркичә булып саналу тиешле күрелгән.

Димәк, бик яхшы вә җитеш телебез бар. Сөйләшәсе килгән кеше аптырап торырлык түгел. Эш шулай була торып, авылларда кирәгеннән артык, хәтта бөтенләй кирәкми вә килешми торган урыннарда рус сүзе истигъмаль ителенә башлаганлыгы күреләдер.

Бер кеше: "Дим буенда "..." авылында булдым. Рус мәктәпләрендә укып чыккан ике яшь егет озын вакыт сөйләшеп утырдылар. Сүзләре бөтенләй нур кичә дисәм, урынлы. Шул урында ике авыл агаеның сөйләшеп утырганда ватып-җимереп катнаштырган русча сүзләре өчтән бере булды дисәм, арттырып сөйләү булмас",- диде.

Халкыбыз русча белсен, кулыннан килсә, башка телләр берлә дә ашна булсын, белү бик кирәк, әмма үз сүзебез арасына урынлы-урынсыз, кирәкле-кирәксез чит телләрне катнаштыру инде бер дә килешми.

Мондый эш үз телебез юлга салынмастан борын ярыйдыр иде, хәтта инде үз ана теле мәктәпләрдә генә түгел, хөкем йортларында вә хөкүмәт даирәләрендә рәсми вә кануный тел булып йөртелә башлады.

Инде бик тәртипле телебез бар. Моннан соң бу эш ярамый.

Үзенең өендә бик күп русча сүз катнаштырып сөйләп тә, руска йомышы төшкәч, тылмач аркылы сөйләү һөнәр булмаса кирәк.

Бу көнге безнең бу өлкәдәге, бигрәк тә, башкорт хатыннарының беренче вазыйфалары — үзләренең ана телләрен саклау, оныттырмау, өй эчендә тел хуҗасы булып торудыр. Бу хезмәт аның өчен авыр түгел.

Дөньяда булган һәр төрле кавемнәрнең телләрен саклаучылар шул кавемнәрнең аналары вә телләре булган хәлдә, безнең халкыбызның телләрен саклаучылар да үзләренең аналары вә хатыннары булырга тиешле. Безнең халкыбызның аналары, хатыннары зирәклек вә һиммәт тугрысында башкалардан ким түгел.

Мөхлисә Бубый.
«Ислам мәҗәлләсе».– 1924.– № 1.– Б. 28-30.

ифтихар – мактану, горурлану
мәхрәм карендәшләр – якын кардәшләр
гафиф – саф, пакь
ләтыйф – гүзәл, мөлаем
тәслия – кайгылы кешене юату
мәсраф – чыгым
истигъмаль – кулланылу
ашна – таныш, хәбәрдар

## Хатын-кызларга гаид

Хөрмәтле җенестәшләрем хатын-кызларга каратып берничә сүз.

Аллаһы тәгаләнең җир йөзендә яраткан һәм җир йөзенә хуҗа булган кешеләренең яртысы хатын-кызлардыр. Шул сәбәпле мин гаҗизә җенестәшләремә карап, әхлакый вазыйфалардан берничә генә сүз сөйләп узуны үземә бурыч санаймын.

Кешеләрнең чын мәгънәсе илә кеше булулары күркәм холык сәбәбеннән булуы һәркемгә мәгълүм. Күркәм холыклы булу кешенең үзенә йөкләнгән бер мөкатдәс бурычтыр. Ягъни бер кеше әхлагын төзәтергә, күркәм холыклы булырга гайрәт итсә, шөбһәсез, тәрбияле вә әхлаклы була аладыр.

Күркәм холыкларның бүлемнәре күп. Ләкин мин монда гаилә төзү өчен хатын-кызларыбызга иң хаҗәт булганнарыннан берничәсен генә әйтеп узамын.

[...] Бу көндә бөтен җир йөзендәге милләтләрне тәфтиш итеп карасак, һәрбере гаилә төзиләр вә гаиләви тормыш илә яшиләр, хайваннарча яшәгән милләт бер дә юк.

Гаилә төзү нәсел саклауга һәм адәмнәрнең бәхет вә сәгадәтле булуына иң куәтле сәбәп булганлыктан, безнең ислам динебез дә гаилә төзүгә зур кыйммәт бирәдер. Коръәни кәримдә һәм хәдисе шәрифләрдә ир, хатын, бала вә ата-аналар вә кабиләләр хакында ачык бәян кылынган. [...]

Гаиләләрнең төзек вә тәртипле булуы бөтен өммәтнең низамлы вә төзек булуына сәбәптер. Бер милләтнең урын тотуы һәм бәхет вә сәгадәтле булуы өчен ул милләтнең балалары вә гаиләләре тәрбияле булулары ляземдер.

Гаиләләрнең тәрбия вә әхлаксыз булулары милләтнең тамыры бозык вә черек булуга беренче сәбәптер, чөнки милләт шул гаиләләрдән төзелгән вә оешкандыр.

Гаилә дигән кечкенә оешма ир илә хатынның кушулуыннан (издиважыннан) башлана. Ир илә хатын хилкать (яратылыш) вә табигатьтә дә бер-беренә кушылырга мәҗбүрдер. [...]

Кирәк ир, кирәк хатын булсын, өйләнмәй ялгыз торулары табигатькә муафыйк тормыш түгелдер. [...] Гаилә тәшкил итү (өйләнү) кешенең яшәү тарихында бик зур алмашыну булганга, бик яхшы тикшереп вә уйлап эш йөртергә кирәк. Өйләнү кешенең гомерлек иптәшлеккә берәүне алуы, яхуд берәүнең баруы дигән сүз. Безнең ислам дине бу хакта ошбу биш төрле шартны ригая итәргә кушкан:

1) Ир илә хатын бер-беренә әхлак вә тәрбиядә муафыйк вә көфу булсын.

2) Алачак иптәшен дә тәрбия итәрлек байлыгы вә икътисадый җитешлеге булсын.

3) Боларның бере тәрбия җәһәтендә түбәнрәк булып чыкса, югарырак булганы түбәнрәк булганына күркәм юлдашлык итеп өйрәтергә тырышсын.

4) Ир илә хатын яшь ягыннан бер-беренә якын булсын.

5) Кушылачак ир илә хатын һәр икесе тышкы (төс) матурлыгыннан бигрәк, мәгънәви, рухани яктан булган (әдәп, тәрбия, хөсне әхлакый яктан булган) матурлыкларны алда тотарга кирәк. Төс никадәр матур булса да, әхлаксыз вә тәрбиясез иптәштә бер файда да юк. [...] Ир илә хатынның бер-беренә каршы әхлакый бурычларының иң кирәклесе дүрттер.

1) Садакать (бер-берсенә ышанычлы булу). Иргә йортның тышында хезмәт кылып, гаиләсен туйдырырга тугры килгәне кеби, хатынга да йорт эчендә хезмәт кылып, гаиләдәге әгъзаларын тәрбияләргә тугры киләдер. Димәк, ир илә хатын бере йортның эчендә вә бере тышында хезмәт кыла. Бу вакыт-

ларда боларга бере-береннән ничә көннәр вә атналар аерылып торырга тугры килә. Менә ошбу вакытларда ир вә хатын һәр икесе берсе берсенә аз гына да хыянәт кылмавы, ир хатынын вә хатын ирен күңеленнән чыгармавы тиеш вә ляземдер. Әгәр ир илә хатын икесе бер әгъза булып, бере икенчесен кайгыртса, вә күңелләре дә бер булса, менә шул гаилә бәхет вә сәгадәтледер. Чөнки болай булганда, бере икенчесеннән аслан шөбһәләнмәй, камилән бере-беренә ышана вә һәр икесенең дә җаннары рәхәт булып, мәхәббәт илә гомер кичерүгә сәбәп була. Әгәр дә боларның арасында аз гына хыянәт булса, ир илә хатынның арасы бозылу вә салкынлануга сәбәп булып, бөтен гаиләнең бәхете вә сәгадәте җимерелә, чөнки никахның төп мәгънәсе дә бер-беренә садакатькә гаһед алышудан гыйбарәттер.

2) Әминият. Ир илә хатын бере береннән камил әмин булырга кирәк, әгәр ир хатыннан, хатын ирдән әмин булмаса, арада бер төрле дә өлфәт вә мәхәббәт дигән нәрсә урнаша алмай, билгакес, ике арада төрле фетнәләр чыгуга вә гаилә бозылуга зур сәбәп була.

3) Хәтер саклашу. Ир илә хатын һәрвакыт бер-берен ригая кылырга вә хәтерләрен калдырырлык бер кәлимә сүз вә бер эш кылмаска тиеш. Әгәр, Аллаһы сакласын, бере берен ригая кылмасалар вә хәтерләрен калдырырлык сүздә вә фигыльдә булсалар, ул вакыт гаилә тормышының тәме вә ләззәте китеп, ул гаиләнең рәхәте китәчәгендә шөбһә юктыр.

4) Могавәнәт. Никах дигән гакыдның иң кадерле җимеше дә ир илә хатынның кай урында вә кай вакытта гына булса да, бер-беренә җиңеллек кылулары вә ярдәмләшүләредер. Әгәр ир хатын эшенә, хатын ир эшенә бер дә ярдәмләшмәй, бу минем эш түгел, дип торса, боларның арасында өлфәт вә мәхәббәт дигән нәрсәнең бөртеге дә булмас. Киресенчә, араларында гадавәт вә салкынлык заһир булыр.

Хатын илә ирнең берсенең икенчесе өстендә аерым бурычлары да бар. Ирнең хатынга эшләргә тиешле булган бурычлары. Табигать ягыннан ир хатыннан куәтле булып яратылган. Шуның өчен ирнең өстенә күп кенә авыр эшләр йөкләнә. Боларның берсе ир хатынының ашау-эчүен, кием-салымын, тора торган урынын тәэмин итәргә тиеш. Боларны эшләй алмаганда шәрган вә низамән өйләнүдә мәгънә юк.

Икенчесе: ир рафикасының (мәңгелек иптәшенең) намус вә вөҗүден үз намусы вә үз вөҗүде кеби күреп сакларга, гүзәл нәсыйхәтләрдә булырга һәм Аллаһы тәгаләнең "Хатыннарга күркәм мөгамәләдә булыгыз!" дигән сүзен онытмаска тиеш. Дәхи дә Кәляме шәрифтә "Ирләр хатыннарның һәрбер әмерендә эш башкаручылардыр" диелгән. Чөнки бәдән куәте

ягыннан ирләр хатыннардан артыктыр. (Нәзакәт вә хис ягыннан хатыннар ирләрдән артыграк) һәм дә хатыннарга нәфәка бирү дә ирләр өстендәдер. [...]

Хатыннарның иргә эшләргә тиешле бурычлары.

1) Хатыннар ирләре табып китергән ашау, эчү вә башка кием вә йорт нәрсәләрен исраф кылмаска, ватмай вә чәчмәй саклап тотарга тиеш. Ирләрнең маңгай тирләре илә хезмәт кылып эшләп тапкан акча вә башка нәрсәләрен кирәксез киемсалымга вә башка бик хаҗәт булмаган урыннарга тоту, хатыннарның нәзакәт вә тәрбиясезлеге саналып, идарәсез (йорт тота белмәгән) хатын хисапланадыр вә бу эш шәригать һәм халык кашында мәзмүм бер сыйфат. Күбесенчә андый хатыннарның гомерләре фәкыйрь вә мохтаҗлыкта үтә вә бөтен гаиләне бәхетсез кылуга сәбәп буладыр. Матди яктан ир хатынның ярдәмчеседер. Ошбуларны уйлап, хатын да иренә чын иптәш булып, күңеле иреңдә вә гаиләсендә генә булырга тиеш.

2) Ир илә хатын арасында аз гына өлфәт китү (салкынлык булу) илә аерылуны сорамаска кирәк, чөнки бу аерылу гаять күңелсез фаҗигадер. Мондый вакытта ике араны төзәтерлек карендәшләргә мөрәҗәгать итәргә тиеш. [...]

Менә минем җенестәшләрем хатын-кызларга карап әйтә торган нәсыйхәтләремнең бер кыйсеме ошбулардыр. Тәүфыйк Аллаһыдан.

Диния нәзарәтендә әгъза Мөхлисә Бубый.

«Ислам мәҗәлләсе».– 1925.– № 11-12.– Б. 438-442.

гаид — бәйләнешле
тәфтиш итеп — тикшереп
лязем — кирәк, тиеш
ригая итү — игътибарга алу
көфу — тиң, пар
аслан — һич
камилән — тулысынча, бөтенләй
гаһед — килешү
әминият — ышаныч
әмин — ышанычлы
өлфәт — бердәмлек
билгакес — киресенчә
могавәнәт — ярдәмләшү
гакыд — сүз бирешү, килешү төзү
гадавәт — дошманлык, нәфрәт
заһир булу — пәйда булу
шәрган вә низамән — шәригать буенча һәм рәсми
вөҗүд — гәүдә; яшәеш
нәфәка — яшәү өчен кирәк булган мал
мәзмүм — начар, бозык күрелгән
кыйсем — өлеш

## Садрый әфәнде Максудовның Дәүләт Думасында 13 март мәҗлесендә Дахилия Вәзараты сметасы каралганда сөйләгән нотыгы

(Стенографический отчеттан тәрҗемә. "Россия" газетасыннан)

Мөхтәрәм халык вәкилләре! Гәрчә минем унынчы буларак язылганлыгым бик яхшы хәтеремдә булса да, хатибларны язу тәртибендә иттифакый бер тәртипсезлек сәбәпле хатиблар җәдвәлендә беренче булганмын. Шуның өчен сез, иң әүвәл сөйләүчедән хөкүмәтнең Дахилия Вәзараты тугрысында тоткан сәясәтен гомуми рәвештә интикад итүне таләп итәргә хаклысыз. Ләкин мин сезнең өметегезне бушка җибәрергә мәҗбүрмен. Мин Дахилия Вәзаратының мөселман халкына мөтәгаллыйк эшләре хакында гына сөйләячәкмен. (Бу вакытта бәгъзе депутатлар арасында тавыш вә сөйләшү башланганлыктан, рәис аларга тәнбиһ итә).

Әфәнделәр! Без мөселман фракциясенең вәкилләре бу мөнбәрдән мөселман халкы тугрысында сөйли башлагач, сезнең күбегез, мадамә ки хөкүмәтнең миллият вә дин аермасына карамый һәммә халыкка мөгамәләсе бертигез, ни өчен мөселманнар хакында булган сәясәтен генә аерып сөйләргә кирәк, дисез. Әфәнделәр, бу фикер бөтенләй үк дөрест түгел. Без гомуми Русия халкы күрә торган кысынкылыклардан башка, фәкать мөселманнарга гына махсус кысынкылыклар күрәбез. Әфәнделәр, һәр халыкның үзе өчен кыйммәтле вә мөкаддәс нәрсәләре була. Гадәттә хөкүмәт никадәр гакселхәрәкәт тарафдары булса да, халыкның бу мөкаддәс эшләренә катышмый, аларга тими. Бер халыкның ана теле, әдәбияты, мәктәбе вә башка нәрсәләре – ул халыкның мөкаддәс нәрсәләредер. Менә соңгы вакытларда мәэмүрләр, безнең шушы мөкаддәс нәрсәләребезгә тәҗавыз итәләр. Безнең

мәктәпләребезне, әдәбиятыбызны һәм безнең иң әүвәл дөнья вә галәм илә таныткан вә без кечкенә вакытта ук анабыз сөйләшкән телне кыса башладылар.

Безнең фракция әгъзалары бу мөнбәргә бик сирәк чыгалар. Фәкать эчтә әллә никадәр нарасыйлык, кайгы җыелгач кына чыгалар. Шуның өчен без салкын кан илә генә сөйли алмыйбыз.

Әфәнделәр, хөкүмәтнең безнең хакта тоткан сәясәтенең сәбәпләрен һәм аның нәтиҗәләрен сөйләүдән мөкаддәм, мин фәкать бер ел эчендә генә мәэмүрләрнең безгә никадәр низамга мөхалиф кысынкылыклар ясаганын санап чыгуны үземә бурыч дип беләм. Мин һәммәсен санамыйм, фәкать зурракларын гына зикер итәм, югыйсә минем нәтиҗәләремне бушка хисапларлар.

Фәкать бер ел эчендә ошбу кешеләрдә тентү вә хәбесләр ясалды. Москва институтында төрки теле мөгаллиме Хәсән Сабрый Айвазовта әүвәл тентү ясап, соңра хәбес кылып нәфи кылдылар. Соңра Казан муллаларыннан Габдулла Апанаев һәм Галимҗан Галиевтә тентү ясалып, әллә никадәр язу, вә китаплар мөсадәрә ителде. Вятка губернасы, Сарапул өязе, Бубый авылында мөдәррисләрдән Габдулла һәм Гобәйдулла Нигъмәтуллиннар һәм 9 мөгаллим хәбес кылындылар. Алар шушы кешеләр: Нәҗип Думави, Мирзамозаффар Галиев, Габдулла Фәхри, Габделхак Ильясов, Фатыйх Фәйзуллин, Фәхрелислам Рәшидев, Әхмәдфаиз Даутов, рус теле мөгаллиме Шәриф Габдесаттаров. Бу кешеләрдән 500 ләп китап мөсадәрә кылынган.

Рәис:

— Кыскарак сөйләсәгез лә?

— Яхшы, миңа рәис һәммә фактларны санап чыгарга рөхсәт итми. Андый фактлар миндә бер дәфтәр. Хасыйль, бер ел эчендә мәгълүмрәк мулла вә мөгаллимнәрдән бары 150 дән артыграк җирдә тентү ясалды, әллә ничә мәктәп, берникадәр матбага, нәшре мәгариф җәмгыятьләре ябылды. Хәбесләр хакында сөйләмим дә. Фәкать ябылган нәшре мәгариф мөәссәсәләрен генә күрсәтәм. Хукандта мәхәлли инпспекторның әмере илә 20 ләп мәктәп ябылып, мөгаллимнәре куылды. Бөгелмә өязе, Урсай авылындагы мәктәп ябылды, мөгаллиме нәфи кылынды. Уфа губернасы, Минзәлә шәһәрендә "Сәгадәт" көтепханәсе ябылды, Казанда "Үрнәк" матбагасы ябылды. Варшауда бер мәктәп ябылды. Верхний Одинда мөгаллим чыгарылды. Петропавел мәдрәсәсе ябылып, имам Хәсән Пономарев хәбес кылынды. Уша шәһәрендә мөдәррис Мөхәммәдәмин укытудан мәныг ителде. Бакчасарайда Гали Тарпиның китап

кибете ябылды. Әлмәттә иске мәктәп урынына яңа бина салырга рөхсәт ителмәде. Царицын шәһәрендә Ихсанов илә Янгалычев балалар укытудан мәныг ителделәр. Казанда мәдрәсәи "Мөхәммәдия" мөдәррисләреннән өч кеше: Мостафин, Шәрәф һәм Зәбирев мөдәррислектән мәныг ителделәр, хатыннар мәктәбендә мөгаллимә Нәфисә Казакова укытудан мәныг ителде. Ташкентта Мөнәүвәр карыйга мәдрәсә янында русский класс ачарга рөхсәт итмәделәр. Нәмәнганда Хөсәен Макаевны укытудан туктаттылар. Әстерхан, Казан, Сембер вә башка шәһәрләрдәге җәмгыятьләрне ябарга Сенат карар бирде. Казанда 17 нче мәсҗид янындагы мәктәп ябылды. Казан губернасында, бу да сәбәпсез, администрация тәртибенчә, 20 мулла ләвазимнарыннан чыгарылдылар. Рәис әфәнде кыскарак сөйләргә үтенгәнгә күрә, мин артык санап тормыйм. Газеталар хакында ошбу сүзләрне әйтә алам: Баку шәһәрендә нәшер ителә торган көндәлек "Күнеш" газетасы туктатылды. Шул ук шәһәрдә "Һилал" һәм "Мәгълүмат" журналлары ябылдылар. Бер ел эчендә "Вакыт" газетасына 800 сумнан артыграк штраф салынды. Бакуда "Сада" һәм Мәгълүмат"ка, кыргыз газетасы "Айкап"ка штрафлар салынды.

Мин һәммә фактларны санап бетермим. Бары зурракларын гына зикер итәм. Хасыйль, бер ел эчендә 150 ләп мөселманда тентү ясалган, 70 тән артыграк зур мәктәпләр ябылган, иң зур газета вә журналлар туктатылган. Фәкать шушы бер ел эчендә шулкадәр муллаларны борчыганны, шулкадәр мәктәпләрне япканны күргәч, ихтыярсыз түбәндәге ике фикергә киләсең: яисә рус хөкүмәте безнең мәдәниятләшүебез һәм алга баруыбызны теләмичә, ничек булса да шуңа каршы тормакчы була, яисә мөселманнар арасында Русия дәүләтенә каршы бер хәрәкәт, бер фикер бар, һәм гадәттән тыш чаралар илә шуңа каршы торырга кирәк дип ялгышыла. Минемчә, бу фикернең һәр икесе дөрест. Гомумән, күптән бирле хөкүмәт безнең мәдәниятләшүебезне басарга тырыша. Хөкүмәт Русия мөселманнарының тәрәкъкый итүен, алга баруын теләми. Ләкин безнең мәдәни хәрәкәтләребез хәзер бигрәк гакыл илә эшләнә. Чөнки безнең бу хәрәкәтләребезгә каршы тору өчен кылынган тәдбирләр панисламизм бар дип уйланганнандыр.

Хәзер уңнар һәм хөкүмәт, мөселманнар арасында панисламизм дип атала торган куркынычлы бер хәрәкәт булганга күрә, без хәзер мөселманнарны кысу хакында каты тәдбирләр кылабыз диләр. Мөселманнар арасында шундый куркынычлы бер хәрәкәт, хөкүмәткә каршы берләшкән бер фирка бармы дигән сөальгә каршы алар – бар, без – юк, дибез.

Әфәнделәр, соңгы вакытларда уң газеталар һәм аның язучылары панисламизмга каршы тору өчен төрле чаралар күрсәтәләр. Шул газеталардан һәм хөкүмәт мәнбәгъләреннән моны ишетеп, без таныш муллаларыбызга, мөгаллимнәргә, хәтта бәгъзе байларга мөрәҗәгать итеп, панисламизм нәрсә һәм халык арасында шундый бер хәрәкәт бармы дип сорадык. Алар бу сөальгә каршы аптырап калудан башка бер нәрсә әйтә алмадылар. Шуннан соң панисламизм хәрәкәтенең барлыгы һәм халык арасында таралганлыгы исбат кылынган хөкүмәт мәнбгъләренә мөрәҗәгать итәргә туры килде. Мин хөкүмәт документларының берсендә панисламизмның тәгърифен шушылай таптым: Бу һәммә мөселманнарны мәдәният һәм сәясәт җәһәтеннән берләштерергә тырыша торган бер хәрәкәт. Ул документларда панисламизм дип атала торган бу хәрәкәтнең бигрәк Волга-Кама әтрафында таралганлыгы бәян ителгән, (димәк бездә панисламизм бар дип гаепләү), Волга-Кама татарларын һәммә мөселманнарны мәдәни вә сәясәт җәһәтеннән берләштерергә тырышалар дип гаепләү буладыр.

Әфәнделәр, мин белмим, мәдәни җәһәтеннән артта, администрация ягыннан кысылган, икътисади җәһәттән ярлы булган 4-5 миллионлы Волга-Кама буендагы татарларның бөтен җир йөзендәге мөселман халкын берләштерергә тырышулары мөмкинме? Бөтен мөселман халкын берләштерү ни дигән сүз? Бу – Филиппин мөселманнарын, һиндстан мөселманнарын һәм Азия, Африка вә башка җирдәге мөселманнарны берләштерү дигән сүз. Мәдәният җәһәтеннән артта, икътисади җәһәттән ярлы булган 4-5 миллионлы Волга-Кама буендагы мөселманнарның Азия илә Африканы берләштерү шикелле шундый зур бер мәсьәлә илә шөгыльләнүләре мөмкинме соң? Бу эш Александр Македонский һәм Наполеон шикелле даһиларга да мөмкин булмаган. Мондый буш сүзгә ничек ышанырга кирәк. Аннан соң безне, истикълял ясарга тырыша торган халык дип тә гаеплиләр. Истикълял ясау, минемчә, нәрсәдән булса аерылырга тырышу дигән сүз. Димәк, безне Русиядән аерылырга тырышалар димәкче булалар. Берничә минут кына башка фикерләрдән аерылып торып, зыялы адәмнәр буларак уйлап карыйк, (бу арада уңнардан "нәрсә дисез?" һәм алырга каршы рәиснең тәнбиһләре ишетелә. Пуришкевич, сез әле үзегез үк без мәдәниятле түгел дип әйткән идегез ич, дип кычкыра).

Миңа дәвам итәргә рөхсәт итсәгез лә. Идел буендагы икътисад вә мәдәният җәһәтеннән артка калган 44 миллион мөселманның 100 миллион рус эченә кысылган һәм 16 нчы гасырда Русия тәбәгалеген кабул итеп, шул дүрт гасыр эчендә

тыныч һәм иттифак илә яшәгән мөселманнарның кинәттән Азия илә Африканы сәяси һәм мәдәният җәһәтеннән берләштерергә тырышулыры мөмкинме соң? Әфәнделәр, мондый сүзләрне уйнап кына сөйләргә мөмкин, әмма чынлап әйтергә ярамый. Бигрәк тә шул уен сүз аркасында тыныч кына тора торган бер халыкны кыса башласалар. Мондый эш ул вакытта зарарлы бер ялгышу булгандыр.

Әфәнделәр, әгәр дә панисламизмның вөҗүде хакындагы ялгыш фикерләр шул кысуларга сәбәп булмаса иде, мин һичбер вөҗүде булмаган хыялый панисламизм хакында сөйләп тә тормас идем. Соңгы елларда булган бу кысуларның һәммәсенең баш сәбәбе панисламизм бар дип гаепләүдәдер.

(Бу вакытта Пуришкевич: "Сез Евдокимовны укыгыз. Кирәк булса, мин Сезгә биреп торырмын",-дип кычкыра, рәис аңа икенче мәртәбә тәнбиһ ясый).

Шулай, әфәнделәр, һәммә мөселман халкын мәдәният вә сәясәт ягыннан берләштерү мәгънәсендә булган панисламизмны 4 миллионнан гыйбарәт булган Идел буе мөселманнарына сылтарга һич мөмкин түгел. Мондый зур фикерле без, зыялылармы, әллә андый зур фикерләргә һәрвакытта ерак тора торган гавам халкымы уйлап чыгарган. Мөселман зыялылары эшкә ашмавы күзгә бәрелеп тора торган мондый фикер илә бер дә мәшгуль була алмыйлар.

Әфәнделәр, панисламизм бер хыял, ул сәясиләнеп маташкан миссионерларның уйлап чыгарган нәрсәләре. Панисламизмның һич булганы да юк һәм хәзерендә дә юк. Бу фәкать әсасән мөселманнарга дошман булган сәяси миссионерларның мәкаләләрендә генә мәүҗүд.

Әфәнделәр, сез хәзер ул панисламизм фикере кайдан чыккан, һәм аның вөҗүде булмагач, ни өчен соңгы вакытларда уң газеталар аның хакында күп яза башладылар? - дип сорый аласыз. Менә мин мәгаль-мәмнүният шуңа җавап бирәчәкмен. Панисламизм сәясиләнгән рус миссионерлары уйлап чыгарган нәрсә. Әлбәттә, үзләреннән уйлап кына чыгарган нәрсә түгел, ул фикер әүвәлдә дә булган. Ул хакта, үзләренең мөселман тәбәгаләре булмаган, шәрык галәмен тикшерүче кешеләр күптән язганнар. Алар пангерманизм, панславизм булгач, ни өчен панисламизм гына булмаска кирәк, дип уйлаганнар. Ләкин ачыктан-ачык панисламизм фикере бар димәгәннәр, бәлки булырга кирәк дип фараз гына кылганнар. Безнең миссионерлар шул сүзне ишетеп алганнар да, бик осталык илә үз җәмгыятьләре файдасына куллана башлаганнар. Мин коры лаф кына булмасын өчен моны исбат кылачакмын. Әфәнделәр, бездә миссионерлар җәмгыяте дип атала торган зур бер фирка

бар. Боларның иң зурысы, православие миссионерлары җәмгыяте дип атала торганыдыр. Моның сәрмаясе дә бик күп. Ләкин эшлеклесе Казандагы "Братство Святого Гурия" җәмгыятедер.

Мин боларның әдәбиятын күптән бирле, хәтта яшь вакытымнан бирле, укып киләмен.

Әфәнделәр, 1908 елга кадәр, сез миссионерлар әдәбиятында панисламизм дигән сүзне бер дә очрата алмассыз. Алар безне миссионерлар әдәбиятына чит күз илә карыйбыз һәм рус мәктәпләренә керергә теләмибез дип гаеплиләр. Безнең муллалар христианлыкның таралуына каршы киләләр, диләр. Хәтта мөселманнарны көчләп православиегә чыгаруда мөсаһәлә кылган өчен бәгъзан хөкүмәтне дә гаеплиләр. Боларның һәммәсе языла килә. Ләкин 1908 елга кадәр панисламизм хакында бер сүз дә булмый. Фәкать шул елдан соң гына миссионерлар тарафыннан нәшер ителә торган рисаләләрдә, журналларда панисламизм хакында төрле мәкаләләр, хәбәрләр языла башлый. Моны ничек итеп аңларга кирәк, ни өчен 1908 елдан соң гына панисламизм хакында яза башладылар? Менә аның сәбәбе шушы:

Гомумән, миссионерлар, бигрәк тә Казан миссионерлары, күптән бирле Русиядә сәяси роль уйнарга һәм рус хөкүмәтен агрессивный политика юлына куярга телиләр. Бу максатларына алар үзләре теләгән микъдарда ирештеләр. Һәм Русиядә мәшрутыять игълан кылынганга кадәр, мөселманнар хакында нинди сәясәт тоту турысында хөкүмәткә тәлкыйн биреп тордылар. Мин шуны да әйтергә тиеш ки, миссионерларның рус хөкүмәтен агрессивный политика юлына куярга тырышулары Столыпин баш вәзир булып торган вакыттагы шикелле яхшы вакытка туры килмәде. Столыпинның миллият сәясәте тоткан-лыгы мәгълүм булгач та, һәм Думада милләтчеләр партиясе ясалып Крупинскийлар һәм Бобринскийлар баш булганны күргәч тә, безнең сәясиләнүче миссионерларыбыз үзләренә эш эшләргә вакыт җиткәнлекне һәм инородецлар хилафына нинди сүз сөйләсәләр дә Петербургта ышаначакларын аңладылар. Менә шуның өчен алар 1908 елдан соң, хөкүмәтне панисламизм бар дип куркыта башладылар. Казан миссионерлары Дахилия вәзиренә берсе артыннан берсен докладлар яздыра башладылар. (Бу докладлар миндә бар). Бу докладларында мөселманнар арасында рус хөкүмәте өчен хәвефле бер хәрәкәт бар, аңа каршы торырга кирәк вә башка шуның шикелле сүзләр язганнар. Шуннан соң, 1910 елда, Казанда миссионерлар съезды ясала.

Бу съездда да, шул ук докладларда язылган нәрсәләрне тәкрар итәләр, һичбер төрле дәлилгә бина кылмыйча, бездә шундый куркынычлы бер хәрәкәт бар дип гаеплиләр.

Әфәнделәр, төрле документларны чагыштырып карау өчен, Казанда булган миссионерлар съездының бәгъзе карарларын укып чыгуны лязем дип беләм. Менә съездның безнең хакта булган карарлары. Гәрчә анда, башка халыклар хакында да сөйләнсә дә, күбрәк мөселман мәсьәләсе тугрысында сүз бара. Монда зикер ителгән тәдбирләр панисламизмга каршы тору өчен булган чаралардыр. Беренче чара, епископ Гурий ярлы булганга күрә, һәр елны хәзинәдән ярдәм бирелүне сорарга. Панисламизмга каршы тору өчен булган икенче чара – Вяткадагы миссионерлар курсының тәрбиясе өчен хөкүмәттән ярдәм сорарга. Өченче чара, исламияткә каршы тору өчен мәкруһ татарлар арасында чиркәү мәктәпләрен күбәйтүне сорарга һәм Казандагы мөтәрҗимнәр комиссиясенә 5 мең, Сембернекенә 2 мең, Самара, Оренбург, Тобол һәм Омскинықына бирәр мең сум хәзинәдән ярдәм бирелүне хөкүмәттән сорарга. Дүртенче чара, инородецлар булган епархияләрдә һәр өязгә окружной миссионерлар тәгаен итәргә. 5) Миссионерлар җәмгыятенә руханилардан башка, земстволарда һәм хөкүмәт мөәссәсәләрендә хезмәт итә торган дөньяви кешеләрне чакыру да матлуб. 6) Инородецлар һәм инородецлар арасында тора торган руслар өчен "Закон божий" тугрысында христианлыкның әсасы һәм исламияткә каршы дәлилләр бәян ителгән рисаләләр чыгару да бик матлуб. Бу да панисламизм хилафына. 7) Кырымда, Кавказда һәм кыргызлар арасында бәгъзе фамилияләргә бирелгән артыклыкларны бетерүне югары начальстводан үтенергә. 8) Яшь татар матбугатында панисламизм фикеренә каршы тору өчен журнал чыгарырга. 9) Русиядәге һәм читтәге мөселман матбугатында нинди фикерләр барлыкны белдерү өчен даими бер газета нәшер итәргә. 10) Татар газета вә журналларының татарча илә бергә русча да басылуын хөкүмәттән сорауны Синодтан үтенергә. Болар да панисламизмга каршы. 11) Сайлау вакытында мөселманнар христианнар илә бер куриягә кермичә, аерым курия ясасыннар иде. 12) Хәзердә мәүҗүд мөселман мәктәпләрен хөкүмәт нәзаратына тапшырырга.

Менә әфәнделәр, панисламизмга каршы тору өчен җыелган миссионерлар съездының карарлары шушылар. Мин монда, халис миссионерлар табигатендә булган карарлар һәм панисламизмга каршы тору өчен булган карарлар бармы дип сорар идем. Бу карарларның берсе дә панисламизмга каршы түгел. Бәлки турыдан-туры исламиятнең үзенә каршы. Әгәр миссионерлар съезд ясап, ниндидер карарлар чыгарып та, ул карарлар

кәгазьдә генә калса, һәм хөкүмәткә мөселманнар хакында нинди сәясәт тотарга кирәклеген тәлкыйн итмичә, тыныч кына үз фикерләрен таратсалар, бер нәрсә дә булмас иде. Без моңар разый да булыр идек, ләкин, мәгат-тәәссеф, безнең миссионерлар аның илә генә шөгыльләнмиләр, аңа гына канәгать итмиләр. Алар хәзер бигрәк хөкүмәтнең сәясәтенә тәэсир итәргә тырышалар. Һәм, мәгат-тәәссеф, Столыпин вакытында бу максатларының күбесенә ирештеләр дә, алар Столыпинның инородецлар хакында йомшаклыгын һәм инородецларга каршы төрле тәдбирләр кылырга хәзер икәнлеген күреп, аны агрессивный политика юлына кертмәкче булдылар. Икенче яктан, алар Столыпинның баһадирлыгын да беләләр. Әгәр аңа мөселманнар тыныч тора дисәләр, гәрчә муллалар христианлыкны тарату эшендә миссионерларга каршы торсалар да, Столыпин агрессивный юлга кермәс иде. Менә Столыпинны шул юлга кертү өчен дә мөселманнар арасында шундый куркынычлы фикер вә хәрәкәт бар дип күрсәтергә тиеш тапканнар. Шуның өчен алар панисламизм дигән хыялны уйлап чыгарганнар да. Менә миссионерлар съездының шул карарлары һәм Дахилия вәзире Столыпинга биргән докладлары аркасында хөкүмәтнең инабәтен җәлеп итеп, Дахилия вәзаратында панисламизмга каршы тәдбирләр табу өчен махсус совещание ясатуга муәффәкъ булдылар.

Бу совещаниедә әгъзаларның күбрәк шул фикерне уйлап чыгарган Казан миссионерлары иде. Менә шул совещание панисламизмга каршы бик күп чаралар эшләп чыгарды. Панисламизмга каршы тору өчен дип зур исем бирелгән бу чаралар, төбендә панисламизмга каршы түгел, бәлки исламиятнең үзенә каршы.

Миссионерлар безнең илә башка диндәге халык булганнан түгел, бәлки башка бер милләттән булганга күрә каршы торалар.

Мин хәзер дөньяви мәэмүрләрдән тәшкил ителгән совещаниедә, панисламизмга каршы тору өчен табылган чараларны зикер итәчәкмен. Шул вакытта бу документлар илә миссионерлар съездында бирелгән карарлар арасында аерма юклыгын мин сезгә күрсәтәчәкмен. Дөньяви мәэмүрләр совещаниесе илә миссионерлар съездында бирелгән карарлар, түгел мәфһүм җәһәтеннән генә, хәтта заһири сүзләре илә үк бер-берсенә охшашлы. Хасил, миссионерлар съездында панисламизмга каршы тору өчен ясалган чаралар, дөньяви мәэмүрләр тарафыннан бөтенләй кабул ителгән. Дахилия вәзаратындагы совещаниенең башы, хәзерге Дахилия вәзире мөгавине грузин иде. Ул шаять үзләре эшләгән нәрсәләрне икърар итәр. Мин Столыпин һәм

башкалар тарафыннан имза кылынып, панисламизмга каршы тору хакында вәзирләр шурасына бирелгән докладны бөтенләй укып чыкмаячакмын.

Менә шул документта әйтә:

"Югарыда зикер ителгән нәрсәләргә бинаән, ягъни, панисламизмның вөҗүденә бинаән совещание уйлыйдыр.

1) Мөселман халкы илә аралаш булган Идел буе губерналарындагы миссионерлар һәм рухани мәгариф тарату өчен булган җәмгыятьләр (мәсәлән, Казандагы "Братство Святого Гурия" шикеллеләргә) акча илә ярдәм итәргә. Менә бу дөньяви мәэмүрләр тарафыннан панисламизмга каршы тору өчен булган беренче чара.

2) Казан Духовный Академиясендә мәүҗүд Әлсинәи Шәркыя дәресеннән башка, укучылар мәхәлли шивәләр илә гамәли рәвештә танышсыннар өчен, мәхәлли шивәләрне тәгълим кылырга махсус шөгъбә арттырырга.

Икенче төрле әйткәндә, бу да шул миссионерлар академиясенә ярдәм бирергә кирәк дигән сүз була.

3) Мәзкүр шөгъбәгә керү, гомуми кагыйдәләргә бинаән (нигезләнеп), академиягә керергә хакы булган кешеләрдән башка икенче разряд илә Духовный семинарияләрне һәм урта мәктәпләрне бетергән кешеләргә дә мөмкин булсын.

4) Академиянең шул шөгъбәсен бетергән кешеләргә инородецлар булган җирләргә кәшиш һәм миссионерлар булудан башка Духовный семинарияләрдә тел һәм дин мөгаллиме булуда да артыклык бирелсен.

5) Казанда хәзер мәүҗүд миссионерлар курсына, Идел буенда дини вә әхлакый ихтыяҗларны үтәгәнгә күрә, үзенә бина алу һәм шуның тәрбиясе өчен ярдәм бирелсен. Менә боларның да һәммәсе иганә бирү тугрысында бу да панисламизмга каршы тору өчен дип уйланган чара.

6) Мөселман халкы булган епархияләрдәге Духовный семинарияләрдә, инородецларның телләре мәҗбүри дәресләр шикелле тәгълим ителсен.

7) Православныйларга исламга каршы тору максаты илә:

а) мөселман халкы булган җирдәге чиркәү учительский школаларында "Закон божий" дәресендә ислам дине һәм аңа каршы христиан дине ноктаи нәзарыннан җаваплар да тәгълим ителергә тиеш;

б) иҗмали мөселманнар тарихын һәм гакаиде исламиягә рәддия (ислам дине өйрәтмәләрен кире кага торган язма) нәшер итәргә вә бу хакта иң яхшы язучыга һәдия бирелергә тиеш.

8) Инородецларга мәдәни вә дини рәвештә матбугат илә тәэсир итү өчен Казан Духовный академиясе тарафыннан гавам аңларлык рәвештә православие рухында бер газет я журнал чыгарырга имкян бирергә вә моның өчен 3.200 сум кадәр ярдәм тагәен итәргә.

9) Мөселман халкы күп булган шәркый епархияләрдәге һәм мөһаҗирләр булган җирләрдәге епископлар мөселманнарның һәм мөһаҗирләрнең бигрәк күп утырган җирләрендә торсыннар.

10) Мөселман халкы булган җирләрдә мәдәни вә дин хезмәтен арттыру һәм тәкъвия өчен: а) православие руханиларга махсус ярдәм биреп һәм дини вә дөньяви мәэмүрләр тарафыннан рөхсәт алып, зурлар һәм балалар өчен православие чиркәве рухына муафыйк дини мәсьәләләр хакында мөсахәбәләр ясалсын; б) мәктәпләр янында көтепханә вә кыйраәтханәләр ясалсын; в) инородецлар бар җирдәге авылларда православие руханиларына мөгайян бер микъдарда мәгашлык тәгаен итеп, икътисади якларын яхшыландырырга. Бу да башкалар шикелле иганә бирү һәм панисламизмга каршы бер чара.

11) Мөселманнарның мәхәллә мәктәп вә мәдрәсәләреннән дингә тәгаллекъле булмаган гомуми фәннәрне, шул җөмләдән, рус телен дә чыгарырга. Аларда фәкать ислам дине генә тәгълим итәргә һәм бу эшне тикшереп торуны гомуми мәктәпләр нәзарәтенә тапшырырга. (Бу вакытта уңнардан "җитәр инде, сәгать бер булды" дип кычкыралар).

Рәис миңа артык сөйләргә рөхсәт итми, шуның өчен мин хәзер тuктыйм. (Рәис илә сөйләшәләр). Тагын берничә минут кына сабыр итегез, әфәнделәр. Шулай, мин ул документларның һәммәсен укып чыкмыйм. Бары зурракларын гына зикер итәм. Казандагы татар мәктәпләрен хәзергечә калдырып, рухани һәм мәктәпләр нәзараты вәкилләреннән мөрәккәб попечительләр советы ясарга.

12) Мөселман халкы күп булган җирләрдәге мондый мәктәпләрне православный духовный ведомствосы нәзарәтендә ясарга (мондый урыннарны санап чыга). Оренбург Идарәи руханиясе кул астында бик күп халык булганлыктан һәм бөтен халыкның эшен бер идарәгә генә тапшыру дәүләт мәнафәгы ноктаи нәзарыннан муафыйк булмаганлыктан, мөселман Идарәи руханиясен төрле җирләрдә ясау ысулынча ислах кылу мәсьәләсен тикшерүне Дахилия вәзаратына тапшырырга.

Мәҗлескә фасыйлә бирелә.

Бер сәгать чирек фасыйләдән соң Максудов яңадан сөйли башлый.

Әфәнделәр, фасыйләдән мөкаддәм мин, панисламизмга каршы чаралар табу хакындагы документны укыдым. Бу чараларның нәрсәдән гыйбарәтлеген, шаять, сезнең күбегез ятлап алгандыр. Совещаниенең панисламизмга каршы торырга ясаган тәдбирләре арасыннан бигрәк бер маддәсенә сезнең әһәмиятегезне җәлеп итмәкче булам. Ул маддә 11 нче маддәдер ки, анда әйтә:

"Мөселманнарның мәхәллә мәктәп вә мәдрәсәләреннән дингә тәгаллекы булмаган гомуми фәннәрне, шул җөмләдән, рус телен дә чыгарырга. Аларда фәкать ислам дине генә тәгълим итәргә һәм бу эшне тикшереп торуны гомуми мәктәпләр нәзарәтенә тапшырырга". Әфәнделәр, бу карардан мөкаддәм, мөфассаль бер доклад зикер ителеп, бу эшнең ни өчен кирәклегенә дәлилләр китерелгән. Ул докладта әйтә: "Мөселманнар шикелле хосусиятле бер халыкның руханиларына дини мәгълүмат бирү кирәк табылганлыктан, совещание андый мәктәп вә мәдрәсәләрне, шөбһәсез, дәвам итәчәк дип белә. Ләкин шуның илә бәрабәр бу мәктәп вә мәдрәсәләр фәкать дини халәтләренә генә кайтарылырга тиешле. Һәм голуме дlittle ния илә башка фәннәр арасында ачык чик куюны совещание тиешле табадыр. Голуме динияне тәгълим эшен мөселман руханилары карамагына тапшырып, бу эшкә хөкүмәт вәкилләре катышмаячактыр. Ләкин шуның илә бәрабәр мондый дини мәктәпләрдә гомуми фәннәрне укытуга юл калдырмаска кирәк. 1907 нче ел, 26 нчы мартта падишаһ хәзрәтләре тарафыннан тасдыйкъ кылынган правила буенча мәктәп вә мәдрәсәләрдә русский класс ясау мәҗбүри ясалган иде. Совещание бу мәсьәләне дә мөзакәрә кылды. Мәктәп вә мәдрәсәләрдә рус теле тәгълимен мәҗбүри итү хосусый бер максатка бина кылынган иде ки, ул да хәзердә мәүҗүд мөселман мәктәпләрен гомуми мәктәпләр рәтенә кертеп җибәрү иде. Ләкин бу максатны бик үк дөрест дип әйтеп булмый. Чөнки шуның аркасында мөселман мәктәпләренең хакыйкатен гомуми мәгариф бирә торган мәктәпләргә әверелеп китүе ихтимал. Ләкин ул бер дә матлуб түгел. Аннан соң рус теле тәгълимен мәҗбүри ясау артык мәкъбүлияткә дә кичмәде. Мөселман халкы аңа дингә тәҗавыз һәм көчләп руслаштыру өчен ясалган эш дип карадылар. Югарыда зикер ителгән фикерләргә бинаән, совещание мәктәп вә мәдрәсәләрдә хәзердә мәүҗүд русский классларны бетерүне һәм киләчәктә ачарга рөхсәт бирмәүне матлуб табадыр. "

Менә әфәнделәр, дәүләт мәнафәгы өчен тирәнтен уйлап эшләнгән бу документларны укыгач, ирекле-ирексез, без, Русия мөселманнары, безгә дошманлык күзе илә карый торган мис-

сионерлар идарәсендә, һәм мәэмүрләр безнең хакта тоткан сәясәтләрендә һәрвакыт миссионерлар тәлкыйн иткән рәвештә хәрәкәт итәләр дигән фикергә киләсең.

Казанда булган миссионерлар съезды доклады илә хөкүмәт мәэмүрләре тарафының ясалган докладлар икесе бер хакта, боларның һәр икесе миссионерлар җәмгыятенә ярдәм бирү, мөселман мәктәпләрендә җәгърафия, тарих, рус теле вә башка фәннәрне укытудан мәныг кылу, мәктәпләр ачарга рөхсәт бирмәүдән гыйбарәт. Боларның һәммәсе "панисламизмга каршы тору өчен" дип эшләнә. Әйтсәгез лә, зинһар, моның кайсы төше панисламизмга каршы тору өчен? Юк, бу бердән исламияткә каршы тору өчен, икенчеләй, мөселманнарның тәрәккый хәрәкәтенә каршы тору өчен эшләнгән чаралар.

Менә әфәнделәр, шушы докладлар һәм миссионерларның даими тәлкыйннәре аркасында Дахилия вәзараты панисламизмның барлыгына ышанды. Һәм губернатор вә башка мәэмүрләргә моңа ничек каршы тору тугрысында юллар күрсәтте. Шуннан соң мәхәлли мәэмүрләр, губернаторлар вә башкалар панисламизм эзли башладылар һәм һәр нәрсәдә панисламизм шәүләсе күрә башладылар. Һәм һәммә губернатор, хәтта һәрбер становой пристав та панисламизмның мәркәзен табуда беренче булырга тырыша башлады. Тентүләр, хәбесләр, нәфи кылулар башланды. Хосусан, бу эштә Вятка губернасы мәэмүрләре имтияз күрсәттеләр. Алар да панисламизмның мәркәзен эзләделәр. һәм таптылар да. Ләкин сез кайда дип уйлар идегез? Алар йөз елдан бирле дини мәдрәсә дәвам итеп килгән Бубый исемле бәхетсез, ярлы бер авылда панисламизмның оясын таптылар. Бу мәдрәсәдә голуме диниядән башка җәгърафия, тарих һәм рус теле дә тәгълим итәләр.

Вятка жандарм идарәсе бу мәдрәсәдә шундый гомуми фәннәр тәгълим ителгәнен ишеткәч, монда нәрсә дә булырга кирәк, мөселман мәдрәсәсендә үз ихтыярлары һәм үз акчалары илә русча укыталар, җәгърафия дә укыталар, монда панисламизм булырга кирәк, дип уйлый башладылар. Шуннан соң тирә-як муллаларыннан Бубый муллалары панисламизм илә маташмыйлармы дип сораша башладылар. Җәгърафия һәм рус теле укытуга хилаф булган муллалар да анда панисламизм булырга кирәк дип җавап бирделәр. Анда, Җирне Кояш тирәсендә һәм үзенең кучәрендә әйләнә дип укыталар, җирнең нинди кучәре булмак кирәк, бу, әлбәттә, панисламизм галәмәте, диештеләр. Бер доноста бу сүзләр шул рәвештә зикер ителгән.

Вятка жандармнары Бубый тирә-ягындагы дошман муллаларның сүзләренә ышанып, югары мәэмүрләргә ирештерә баш-

лаганнар. Хәзер инде шул бәхетсез Бубый муллалары хөкемгә бирелделәр. Иң әүвәл аларны бөтенләй мәхкәмә тикшерүеннән башка хәбесханәгә япканнар иде. Аннан соң инде килешсез эш булмасын өчен генә мәхкәмәдә эш башладылар. Бу зур эш "панисламизм эше" дип аталадыр. Гүяки, бу бәхетсез муллалар шул Бубый авылында бөтен Русиягә панисламизм фикере таратып торганнар. Хәзер шуның өчен хөкемгә бирелделәр. Хөкем кайчан булчагы миңа мәгълүм түгел, ләкин алар ел ярымнан бирле Сарапул хәбесханәсендә ябылып яталар. Мәэмүрләр уйлап чыгарган панисламизмның юкка чыгачагына, мөселманнар арасында фәкать рус мәдәниятына якынлашу, тәрәккый итүгә тырышу хәрәкәте генә барлыгы мәгълүм булачагына без хәзердән үк ышанып куйган инде. Шиксез, бу хөкемнән соң мәэмүрләрнең панисламизм дип тапкан нәрсәләре юкка чыгачак.

Әфәнделәр, вак мәэмүрләр һәм бездәге мөтәгассыйб адәмнәр, хөкүмәтнең панисламизмны тикшерүе, безнең алга таба баруыбызны, җәгърафия, рус теле вә башка шундый нәрсәләр тәгълим итүне мәныг кылудан гыйбарәт дип белеп, зуррак җирләрнең һәммәсендә төрле доносчылар заһир була башлады, һәм ул доносчыларны вак мәэмүрләр бик яратып кабул иттеләр. Бер нәрсәгә сорау күп булса, шуны эшләүчеләр күп табыла. Шуның өчен һәр җирдә панисламизм хакында донос ясаучылар бик күбәйде.

Бәлки сез күптән түгел "Речь" газетасында басылган бер хатны укыгансыз. Анда әйтә: Кубань чиркәсләреннән Хаҗи Теләши исемле кеше Парижда "Мусульманин" исемле газета нәшер итеп, шунда мөселманнарга панисламизм хакында төрле киңәшләр бирә башлаган. Кубань чиркәсе дип йөри торган шул ук Хаҗи Теләши "Офицерская жизнь"дә куркынычлы панисламизм хәрәкәте турысында мәкаләләр язган. Бу нәрсәләрне язарга Хаҗи Теләшине нәрсә сәвекъ иткәнлеге миңа мәгълүм түгел. Ләкин шул кадәресе бик ачык мәгълүм ки, Хаҗи Теләши бер газетада панисламизм хәрәкәте бар дип куркытып язып, шул ук вакытта икенче җирдә мөселманнарга панисламизм хакында төрле киңәшләр биреп язган. "Речь" газетасының үткән сәнә 24 нче декабрьдә чыккан 357 нче номерын укыган кешеләр, әлбәттә, моңа ышаначаклар.

Хасил, әфәнделәр, шундый вак агентлар, төрле мөтәгассыйб мөселманнар һәм нәмәгълүм адәмнәрнең донослары сәбәпле төрле җирләрдә хәбесләр, тентүләр, мәктәпләрне ябулар башланды. Бу эшләр хәзергә кадәр дәвам итәдер. Бу сәясәт бигрәк Столыпин вакытында башланып, хәзергә кадәр бара. Совещаниедә уйланган тәдбирләр гамәли рәвештә һаман ижра ителә

баралар. Бу шулай кирәк дип эшләнәме, яхуд доносларбашлангач, үзеннән-үзе бару тәртибе белән эшләнәме, анысын без белмибез. Ләкин һәр ничек, югарыда әйткәнчә, шул ялгыш фикер аркасында безне кысалар, мәктәпләребезне ябалар, муллаларны, мөгаллимнәрне куалар, газета вә матбагаларны ябалар. Мин үзем дә һәм бу эшкә битарафлык илә караган кешеләр дә дәүләт мәнафәгы ноктаи нәзарыннан бу сәясәтнең ялгышлыгына, ялганлыгына һәм рус дәүләтенең крепостена бик зур зарар китерәчәгенә ышаначаклар. Сез шул панисламизм аркасында яңа гына уянып килә торган мөселманнарның алга баруларына, тәрәккъый вә мәдәният юлларына сәдд чигәсез. Бу сәясәтнең төбе нәрсә икәнен хәзер күп кеше белә, күптән түгел миңа бер мулла бу хакта становой пристав илә сөйләшкән сүзләрен нәкыль итте. Пристав, никадәр тентүләр ясасак та, сезнең арада панисламизм дигән нәрсә таба алмадык. Ләкин ул нәрсә безнең рус зыялылары арасында бик күп артык, дип әйтә, ди. Ягъни, пристав бу сәясәтнең панисламизмга каршы тору өчен түгел, бәлки мөселманнарның тәрәккъый хәрәкәтенә каршы икәнлеген үзеннән-үзе бик яхшы аңлаган. Һәм ул хаклы да, ул үзенең аңлавында бер дә ялгышмаган.

Әфәнделәр, сез бик зур ялгышлык эшлисез, һәм шуның илә Русиянең мөстәкъ бәленә зур зыян китерәсез. Мөселманнарның тынычлык һәм садыйк тәбәгалек ягыннан әллә кайчан артыклыклары мәгълүм булганны бу урында сөйләп торырга хаҗәт юк. Бу инде бик искергән вә шуның илә бик дөрест сүз. Бу шулай булган, һәм башка сәясәт тотмасалар, хәзердә дә шулай булган булыр иде. Ләкин, әфәнделәр, дөньяда шундый нәрсәләр бар ки, халыкның иң садыйк өлешен дә чуалта, иң тыныч гакылларны да дөрест юлыннан чыгара ала һәм иң тыныч халык арасында да ышанычсызлык пәйда иттерә аладыр. Әфәнделәр, һәр көнне күреп торасың, бер авылда һич сәбәпсез бер мулланы нәфи кылганнар, икенче авылда мәктәпне япканнар, өченчесендә бер дә зарарсыз дини китапны мөсадәрә кылганнар вә башкалар. Бу эшләр һаман тәкрар итеп торалар. Ләкин, әфәнделәр, шуның аркасында рус халкының үзе өчен дә һәм без, мөселманнар өчен дә бер дә матлуб булмаган хәлләр заһир булачактыр. Бу эшләр ике елдан бирле һәр көнне тәкрар итеп киләләр.

Әфәнделәр, мин сезгә ачыктан-ачык әйтәмен ки, Русия мөселманнары арасында Русия дәүләтенә зарар китерерлек һәм аның мәнәфагына мөхалиф һичбер төрле хәрәкәт вә теләк юк. (Мәркәздән бәгъзеләр "дөрест" дип кычкыралар). Әгәр моның

дөрес түгеллеген исбат кыла алсалар, шушы мөнбәрдән хөкүмәт вәкилләренең берәрсе, яисә берәр депутат исбат кылсын иде.

Бу панисламизм дигән нәрсә хыялый бер нәрсә генә. Аны мөселманлыкка дошман миссионерлар һәм шул миссионерларга чынлап ышанып йөри торган кешеләр генә уйлап чыгарган бер нәрсә. Тәкрар әйтәм әфәнделәр, бездә дәүләткә каршы һич бер фикер, һичбер хәрәкәт юк. Фәкать бездә бер теләк бар ки, ул да олуг Русия империясенең камил хокуклы хөр гражданы булуны теләүдән гыйбарәттер.

Без бу максатыбызга ирешәчәкбез дә. Чөнки теләсә генә нинди каршы тәдбирләр кылынса да, 20 миллионлы бер халык, гомергә кысылган хәлдә кала алмаячактыр. Кайчан булса да хаклык өскә чыгачак. Һәм һичбер вакытта хаклыкка каршы килми торган рус халкының шатлыгы илә бәрабәр, камил хокуклы граждан булачакбыз. Моннан фәкать хөкүмәт мәэмүрләре һәм миссионерлар гына куркалар.

Мин уйлыймын ки, безнең милли тормышыбыз илә рус дәүләте арасында берсе-берсенә хилаф килерлек эш юк. Без һәрвакыт Русия дәүләтенең алга баруы, зураюы өчен, Русия гражданы буларак, җәмәгать эшләрендә бергә йөриячәкбез. Ләкин безгә үзебез теләгәнчә бабайларыбыздан урынлашып калган милли рухларыбыз илә үз халкыбыз һәм үз гаиләбез арасында тыныч яшәргә ирек кенә бирегез. (Суллар кул чабалар).

«Йолдыз». - 1912. - 22 - 29 март (№№ 809-812).

иттифакый — очраклы
интикад — тәнкыйдь
мөтәгалликъ — бәйле
тәнбиһ итү — кисәтү ясау
мадамә ки — чынлыкта
гакселхәрәкәт — реакция
тәҗавыз итәләр — тыкшыналар
мөкаддәм — элек
мөхалиф — каршы
зикер итәм — әйтеп үтәм
нәфи кылдылар — сөрделәр
хасыйль — кыскасы
мәгариф мөәссәсәләрен — мәгариф оешмаларын
мәхәлли — җирле
Верхний Одинда — Верхнеодинск шәһәре
Уша — Ош
мәныг ителде — тыелды
ләвазим — хезмәт
тәдбир — чара
мәнбәгъ— чыганак
тәгърифен — анлатмасын
истикълял — сепаратизм
тәнбиһ — кисәтү
тәбәгадеген кабул итеп — кул астында калып
вөҗүде — барлыгы
әсасән — нигездә
мәүҗүд — бар
мәмнүният — шатлык
тәбәгаләр — подданныйлар
мөсаһәлә кылган — әһәмият бирмәгән
бәгъзан — кайчак
рисалә — брошюра
мәшрутыять — конституцион идарә

тәлкыйн — киңәш
бина кылмыйча — нигезләнмичә
лязем — зарур
мөтәрҗим — тәрҗемәче
матлуб — таләп ителә
халис — саф
мәгат-тәәссеф — кызганычка каршы
инабәт — ышаныч
мәфһум — эчтәлек
заһири — ачыктан-ачык
хасил — кыскасы
мөгавин — ярдәмче
бинаән — нигезләнеп
вөҗүденә — барлыгына
мәхәлли шивәләр — җирле диалектлар
тәгълим кылырга — укытырга
иҗмали — кыскача
һәдия — бүләк
имкян — мөмкинлек
тәкъвия — куәтләндерү
мөсахәбә — киңәшмә
мөгайян — билгеле
мәгашлык — вазыйфа
тәгаллекъле — бәйләнешле
мөрәккәб — оештырылган
мәнафәгы ноктаи нәзарыннан — мәнфәгатьләре карашыннан
фасыйлә — тәнәфес
мөфассаль — җентекле
голуме диния — дин гыйлемнәре
тәгълим — укыту
мәкъбүлияткә кичмәде — кабул ителмәде
тәҗавыз — һөҗүм
имтияз — өлгерлек
мөтәгассыйб — фанатик
заһир була — күренә
сәвекъ иткәнлеге — этәргәне
нәмәгълүм — билгесез
крепостена — ныклыгына
сәдд чигү — киртә кору
нәкыль итте — сөйләп бирде
мөстәкъбәл — киләчәк
садыйк тәбәгалек — гражданнар
кылганнар — сөргәннәр
матлуб — кирәк
заһир булу — килеп чыгу

# Иж-Бубый авылы, мәдрәсәсе һәм бертуган Бубыйлар турында мәкаләләр, чыганаклар

Ревизские сказки о ясашных татарах Сарапульского уезда ИжБобинской волости за 1811 г. (мужского полу).

Иж-Бобья

По прежней ревизии [1795 г.] — 157.
Ныне — 237

Государственный архив Кировской области (ГАКО). Ф. 176. Оп. 2. Д. 325.

В селении Ижбобье мечеть соборная, построенная иждивением всего прихода татар при ней. Мулл — 1. Прихожан — 234.

Ведомость о числе духовных чинов и прихожан при оных. 1826 г.; ГАКО. Ф. 582. Оп. 45. Д. 884. Л. 29.

Мулла Нигматулла Абдулсалимов в селении Ижбобье имеет мечетей — 1.

Сведения за 1826 г.; ГАКО. Ф. 582. Оп. 45. Д. 884. Л. 30.

В деревне Ижбобье Агрызской волости при соборной мечети начальная магометанская медреса. Мулл — 1. Прихожан: муж. — 473, жен. — 451. Существует школа с 1857 г. Мулла имам и мугаллими сыбиан Абдул[гал]лям Нигаметуллин из крестьян

Казанского уезда деревни Верхней Бараши. Число учеников: местных — 10, посторонних — 40. Медреса помещается в устроенном обществом дер. Ижбобья доме, отопляется и освещается учащимися. Принадлежностей школы и особенных вакифов нет.

Сведения за 1869 г.; ГАКО. Ф. 574. Оп. 1. Д. 324. Л. 48 об., 49.

Население по переписи 1890 года:

Иж-Бобья.

Разряд крестьян — государственные.

Народность: татары, черемисы.

Число дворов: 219 тат., 4 черем.

Мужской пол: 673 тат., 13 черем.

Женский пол: 637 тат., 20 черем.

Деревня Иж-Бобья расположена при речке Бобье, в 60 верстах от уездного города, в 4 верстах от волостного провления и ближайшего училища. Жители — татары, бывшие государственные крестьяне, магометане. Возникло селение более 200 лет тому назад. Земля разделена по наличным душам мужского пола. В деревне насчитывается до 30 штук веялок. Общество имеет две водяные мельницы.

Материалы по статистике Вятской губернии.
Т. VII: Сарапульский уезд. Часть II: подворная опись. — Вятка, 1892.

Медресе Ижбобинское. Помещение в собственном доме. Указный мулла Галлям Мухамеджанов Нигматуллин. Число учащихся — 18.

Мектебе Ижбобинское. В собственном доме. Указный мулла Галлям Мухамеджанов Нигматуллин. Число учащихся — 17.

Сведения за 1895 г.; ГАКО. Ф. 205. Оп. 2. Д. 2189. Л. 23 об., 24.

Деревня Иж-Бобья.

Соборная мечеть. Мечеть открыта в 1892 г.

1) Губайдулла Абдул Галямов Нигматуллин. Из крестьян, имам, хатып, меодоррис. Утвержден в должности 1 декабря 1895 г.
2) Абдулла Абдул Галямов Нигматуллин, из крестьян, имам, хатып, меодоррис. Утвержден в должности 8 октября 1901 г.

Список за 1905 г.; ГАКО. Ф. 237. Оп. 76. Д. 1363. Л. 44.

**М.В.Д.**
**Казанский учебный округ**
**Инспектор народных училищ**
**Сарапульского уезда**
**11 февраля 1912 г.**
**№ 503**
**г. Сарапул**

Его Высокородию
Господину директору
народных училищ
Вятской губернии

Вследствие предложения, от 7 сего февраля за № 55, имею честь представить при сем Вашему Высокородию копию распоряжения моего о закрытии магометанских мектебе и медрессе в деревне Иж-Бобье, от 28 января с.г. за № 380, посланного Залалетдинову.

Инспектор народных училищ Вл. Ивановский.

С копией распоряжения посланного Залалетдинову, от 28 января с.г. за № 380.

ГАКО. Ф. 205. Оп. 4. Д. 2927. Л. 3.

Копия

**М.В.Д.**
**Казанский учебный округ**
**Инспектор народных училищ**
**Сарапульского уезда**
**28 февраля 1912 г.**
**№ 380**
**г. Сарапул**

Доверенному Иж-Бобинского
общества крестьянину деревни
Иж-Бобья, Сарапульского
уезда, Вятской губернии
Бадретдину Залалетдинову

Вследствие распоряжения г. Директора народных училищ Вятской губернии от 18 сего января за № 47 впредь до особого со стороны г. Директора распоряжения, закрываю находящиеся в деревне Иж-Бобья женские медрессе и мектебе и мужское мектебе (татарские училища), о чем и прошу Вас сообщить для исполнения учительницам женских медрессе и мектебе и учителям мужского мектебе.

Подлинное подписал Инспектор народных училищ
Сарапульского уезда Вл. Ивановский.

ГАКО. Ф. 205. Оп. 4. Д. 2927. Л. 4,4об.

## Из отчета
### инспектора Н. Меньшикова, 1904 г.:

Мужское училище в деревне "Ижбобие" Агрызской волости.

"В 11 часов дня 23 ноября я прибыл в медресе в деревне "Ижбобие", рассчитывая посетить эту школу до полдневной молитвы магометан.

В школьном дворе было довольно больших два одноэтажных здания. Я направился к более отдаленному, около которого стояли ученики, и вошел в помещение. Против входа был большой полутемный и довольно грязный зал, в который спереди и с боков выходило несколько больших комнат. В зале на стенах висела одежда, а около стен стояли небольшие сундуки. Боковые комнаты были устланы кошмой и уставлены низкими продолговатыми столами, покрытыми разноцветными коврами, на которых лежали подушки, и также сундуками. Это было общежитие, в котором помещалось до 60 учеников из других селений. Везде толпились взрослые юноши-ученики и мужчины до 30 лет – учителя. Я сообщил о цели посещения и просил послать за заведующим "медресе" муллой. Меня привели в переднюю комнату, совершенно свободную от мебели, в которой также было немало учеников и учителей. Эта комната служила для занятий муллы со старшими учениками.

Поджидая муллу, я стал расспрашивать окружающих об организации школы. Большинство довольно свободно владели русским языком, но все отвечали на мои расспросы очень неохотно, говоря, что о всем я могу узнать от муллы. Тем не менее я узнал, что школа разделяется на 4 отделения, в каждом из которых ученики обычно учатся по три года. Прошедший все отделения может впоследствии поступить в муллы, а предварительно должен в течении трех лет прослужить в медресе бесплатным учителем (таких постоянных учителей 12). Тем временем посланный возвратился от муллы с приглашением к нему в дом.

Встретили меня указный мулла Абдулла Нигматуллин, молодой человек 29 лет, служащий муллой уже 8 лет, и его старший брат Губайдулла, тоже мулла служащий 6 лет. Оба муллы прекрасно говорят по-русски. Образование они получили в местном "медресе", очень начитаны.

Губайдулла до службы много путешествовал: был в Константинополе, Аравии и вообще за границей. На мое сообщение о цели посещения они ответили, что теперь едва ли уже есть занятия, и что скоро муэдзин будет звать правоверных на мо-

литву. Я возразил, что в таком случае я попрошу познакомить меня с медресе во время послеполдневных занятий.

Через час мы отправились в медресе – первое здание во дворе. Медресе оказалось громадною школой, в которой в 1-ом отделении, большой комнате, сплошь уставленной обычными партами со скамьями, сидело более 60 мальчиков, (мулла утверждал: "человек 40" и добавлял, что у них списков не ведется), в том числе некоторые лет пяти. Когда я обратил на это внимание, мулла сообщил, что родители очень рано отдают в школу детей, и хотя это очень вредно, отказывать от школы неудобно из опасения вызвать раздражение.

По установке парт в первом отделении, по количеству учеников и по предметам занятий в одно и то же время – видно было, что здесь обучаются три совершенно различные группы: одна начинающих учиться грамоте, другая учащихся не менее года, а 3-я двух лет. В другой большой комнате помещалось две группы, ученики одной группы сидели спиной к ученикам другой, при чем одни – под руководством учителя занимались географией, другие читали с учителем алкоран; учащихся здесь было не менее 40. Далее в небольшой комнате сидело до 20 учеников без учителя, какое это отделение, выяснить не удалось. А одна комната, сплошь уставленная партами в две группы (человек по 40), была без учеников, так как старшие ученики по случаю уразы в послеобеденные часы могут не заниматься, как объяснил мне мулла. Всего обучается в школе не менее 150 учеников, хотя по словам мулл-братьев, человек 80. Осталось не осмотренным мною одно помещение, чрез сени общежития; посещение его, как и общежития мулла отклонил, сказав, что там ничего особенного нет. И вообще, следует отметить, мулла неохотно показывал свою школу и говорил о ней, неоднократно подчеркивая, что в их школе "определенного порядка нет", "для порядка нужны средства" и т.п. В этих заявлениях есть большая доля правды, Ижбайкинское, например, медресе, благоустроенное, однако, по общей постановке медресе "Ижбобие" стоит значительно выше, почему учителя русско-татарских школ сравнивают его с магометанской академией.

Но как указный мулла Абдулла, так и брат его много говорили о том, что в их деревне большая нужда в двухклассном училище, которое однако, не преследовало бы миссионерских целей: "миссионерское общество", по их словам "всего более вредит сближению магометан с русскими", только первый класс такого училища, по их мнению, необходимо организовать в виде подготовительного к второму трехгодичный курс 1-го класса для учеников, знающих татарскую грамоту, говорили

они, слишком продолжителен, т.к. такие ученики быстрее могут овладеть русскою грамотой, чем вновь поступающие в школу. О школе мулла Губайдулла предполагал обстоятельно переговорить со мною в Сарапуле, выяснив предварительно, в какой мере может проявится при открытии училища материальное участие местного населения. Открытию же русского класса при медресе мулла не сочувствует. Сообщили, что на лето они приглашали в свою семью учительницу для обучения своих детей русской грамоте, после чего вышедшая девочка лет 8 почитала несколько по книге "Вешние всходы" Тихомирова, но, не зная ничего по-русски, читала без понимания содержания. Очень охотно, наконец обе муллы говорили о вере и о том, как много вредит их темному народу фанатизм, который сильно задерживает их образование, хотя сами они выражают очень фанатическое настроение и проявляют больше подозрительности, чем многие из необразованных мулл, с которыми мне пришлось познакомиться при обозрении других магометанских училищ.

НА РТ. Ф. 92. Оп. 2. Д 3324. Л. 30-32.
(Из отчета по осмотру во второй половине
1903 года магометанских школ Сарапульского уезда).

## Бубый мәдрәсәсендә укыткан мөгаллимнәр (1908 елда)

| мөгаллим | укыткан фәннәре |
|---|---|
| Габдулла Бубый | логика, фикъһ, ысуле фикъһ, тәфсир, хәдис, ислам тәгълиматы |
| Гобәйдулла Бубый | политэкономия, табигать фәннәре (физика, ботаника, минералогия һ.б.), әхлак, французтеле |
| Галиев Әхмәдзәки | география, гомуми география, сызым, әхлак, табигать фәннәре, ысуле фикъһ |
| Музалиев Мирза | арифметика, хисап, ислам тәгълиматы |
| Мөхәммәд Фәйзулла | ислам тарихы, гомуми тарих, фәлсәфә, арифметика, хисап, немец теле |

| мөгаллим | укыткан фәннәре |
|---|---|
| Саттаров Садыйк | рус теле, методика, бухгалтерия (рус телендә) |
| Саттаров Әхмәдшәриф | рус теле |
| Урманчиев Габдулла Фәхри | геометрия, тригонометрия, физика, химия, астрономия, хөсне хат (матур язу), гигиена. |
| Урманчиев Мирза | фикъһ, гыйльме халь |
| Ахунжан Хафиз | Коръән |

ТР МА. 41 ф., 11 тасв., 3 эш, 7 б.

## Из доклада
## Попечителю казанского учебного округа инспектора народных училищ Елабужского уезда Вятской губернии Я.Коблова

6 июня 1908 г.

"... образованных мугаллимов для Елабужского уезда доставляют новометодные медресе в деревнях Иж-Боби и Агрызе Сарапульского уезда и частью Тюнтерское медресе Малмыжского уезда. Иж-Бобинское медресе занимает выдающееся место среди других магометанских школ, оно служит центром просвещения, а в отношении распространения панисламистских идей нисколько не уступает, если не превосходит вышеупомянутые казанские медресе. В виду того, что большинство мугаллимов в Елабужском уезде из Иж-Бобинского медресе, мне представляется, что более или менее подробное ознакомление с ним неизлишне. Иж-Бобинское медресе было основано лет десять тому назад (или преобразовано в новометодное) двумя братьями Габдулла и Губайдулла Буби (Нигматуллины). Эти два брата - сыновья деревенского муллы. Один из них учился в Константинополе, где изучал высшие магометанские науки и получил светское образование. По возвращении на родину, он вместе с братом основал медресе. На помощь им пришел богатый татарин Мухаммедзян Ахматшанов, жертвующий ежегодно на со-

держание медресе до 15-ти тысяч рублей - в качестве, положенной магометанским законом, милостыни - зякат.

Сверх этого медресе пользуется субсидией Сарапульского земства в размере до 700 рублей. В медресе основательно изучаются богословские науки и восточные языки: арабский, турецкий, турецкая литература. Но что очень важно и что редко бывает в медресах, преподаются в Иж-Боби и светские науки общеобразовательного характера: математика, физика, химия, всеобщая история - главным образом история мусульманских народов и французский язык. Преподавание всецело ведется на татарском и турецком языке. И хотя при медресе есть классы русского языка, но в самом медресе русский язык не преподается и мугаллимы русского языка не знают. Иж-Бобинское медресе пользуется широкой известностью среди магометанского населения. Сюда приезжают учиться магометане из разных губерний, навещают Иж-Боби любители магометанского просвещения из средне-азиатских владений и из Турции. Вообще, это центр магометанского просвещения и центр небезопасный в отношении пропаганды сепаратизма и распространения панисламистских идей. Отсюда выходят всесторонние образованные люди, тщательно изучившие ислам и убежденные националисты. Иж-Бобинское медресе стало выпускать мугаллимов нового типа года три тому назад. В последние годы стали появляться мугаллимы из Иж-Бобинского медресе и в Елабужском уезде"

"... 4) В виду того, что Иж-Бобинское медресе Сарапульского уезда занимает выдающееся место по своему влиянию на магометанское население и это медресе посещают разные проходимцы из Бухары, Константинополя, в недоброжелательности которых к русскому государству не может быть никаких сомнений, полезно было бы это медресе иметь всегда под особым надзором как неблагонадежное в смысле распространения панисламистских идей. По этой же причине полезно было бы затруднить доступ на должность мулл, кончающих курс в Иж-Бобинском медресе. Такому же надзору следует подчинить и Агрызское медресе, однородное с Иж-Бобинским, хотя и не имеющее такого значения.

НА РТ. Ф.92. Оп.2. Д.8777. Л.58об.-61.

***

Сарапул өязе Әгерже волосте уездной съездга Думага сайлаучыларны сайлау җыены булып, берсе әрбабе мәгарифтән Бубый имамы Фәйзи әфәнде, икенчесе мәгариф сәүән байлардан Әгерже сәүдәгәре Муллаәхмәд Габдиев сайланды.

Дәхи Сарапулда уездной съезда вилаятькә (Вяткага) сайлау җыены булып, хазир булмыш сайлаучылардан 15 рус, 2 ар, 1 мөселман (мәзкүр Бубый имамы Фәйзи әфәнде) сайланды. Өяз сайлавында сайлаучылар арасында бары 3 кенә мөселман булмыш исә дә, әлхәмделиллаһи, кәнделәренең гайрәт вә иҗтиһадлары сәясендә бер мөселман сайланды.

«Казан мөхбире» газетасы. — 1906. — 12 апрель (№ 67).

әрбабе мәгариф — мәгариф әһелләре
Фәйзи әфәнде — Гобәйдулла Фәйзи-Бубый
сәүән — сөйгән, яратучы
дәхи — тагын
вилаять — губерна
хазир булмыш — катнашкан
кәнде — үзе
иҗтиһад сәясендә — тырышлык нәтиҗәсендә

## Бубыйдан мәктүб
### Таләбәи кирам дикъкатенә

Беренче майда Бубыйның рөшди, игъдади сыйныфларының имтиханы улыб, шәкерт вә мөгалимнәрнең иҗтиһадларыннан әһали тәмам мәмнүн булдылар.

2 нче майда «Әл-Иттихад» комитетының гомуми җәмгыяте улыб, 4 нче майга кадәр дәвам итте. Җәмгыятьтә Тымытык, Чакмак, Биклән, Теләнче Тамак, Нөркәй, Борай, Бәйрәкә, Бәдрәш, Пермь вә Уфа кеби мәшһүр мәдрәсәләрдән, гомум таләбә исеменнән 60 вәкил улыб, матлублары:

*«Бөтенрусия татар таләбәсе җыелып бер тарызда хәрәкәт итүләре вә бөтенрусия мәктәп вә мәдрәсәләренең бер програм тәхтендә булмак»* улдыгыннан җәмгыять үзенең карарыны ике вәкил васитасы илә «Әл-Ислах» җәмгыятенә гарыз итмәкче улыб, телеграм илә хәбәр сорады, «Ислах» җәмгыяте 5 нче майда таралачак дәйү, җавап килгәч, вәкилләр йибәрелмәде, әмма «Ислах»ың бөтен программаларыны вә әгъзаларыны дикъкат илә тәфтиш итеп, үзенең матлубына муафыйк тапса, ягъни ислах тәмам милли улса гына, катышачак улып, «Ислах»

бу көнгә кадәр улдыгы кеби әгъзалары һәм матлублары мәҗһүл вә шөбһәле улдыкта аларга катышмаска, бәлки бөтенрусия таләбәсене «Әл-Иттихад» флагы (байрагы) астына җыеп, милли сурәттә бер эздән хәрәкәт итәргә чакыра, җәмгыятең беренче дәрәҗәдә майдане мөзакәрәйә куярак вирдеке карар иде.

Җәмгыятьтә карар вирелән маддәләр:

1) Иске ысулда улан мәктәп вә мәдрәсәләре яңы ысул үзрә ислах итмәк;

2) ибтидаи мәктәпләре мәдрәсәләрдән аерып, мәдрәсәләре күп шәһәр вә каръяләрдә мәдрәсәләре бер-беренә кушып, бәгъзесен рөшди, бәгъзесен игъдади итмәк;

3) гомум мөселман мәктәп, мәдрәсәләренең мөмкин кадәр програмнарыны берләштермәк;

4) таләбә истифадәсе өчен мәктәп, мәдрәсәләрдә көтепханәләр ачмак;

5) мәктәп, мәдрәсәләрең мәсарифене вәкыф, әһалинең гомуми вәрадәте вә земство кеби мәнбәгъләрдән тәсвия итмәк;

6) мәктәп, мәдрәсә нәзарәтенең хөкүмәт кулыннан алынып, милләт кулына вирелмәсе;

7) татар шәкертләренең хокукта рус шәкертләрилә мөсави улмасы;

«Әл-Иттихад»ның идарәи мәркәзиясе Бубыйдан Уфайа күчерелмәсе хосусында хәйли мөзакәрә ителсә дә, каттый сурәттә карар вирелмәй калды.

«Өлфәт» газетасы. - 1907. - 26 май (№82).

таләбә — шәкертләр
әһали — җыелган халык, мәхәллә халкы
матлуб — таләп
тарыз — ысул, юнәлеш
васита — арадашчы
гарыз итү — җиткерү
дәйү — дип
тәфтиш итү — тикшерү
мәҗһүл — билгесез
мәйдане мөзакәрә — фикер алышу, киңәш мәйданы
истифадә — файдалану
мәсариф — чыгым
вәрадәт — керем
мәнбәгъ — чыганак
тәсвия — тигез алу
мөсави — бертигез
идарәи мәркәзия — үзәк идарә
хәйли — күп

## Бубыйлар эше хакында
(хосусый мөхбиребездән)

Бубый мәхдүмнәрнең хөкемгә бирелүләренә уң газеталар бик сөенеп язалар. "Безнең Русиядәге сул фикерле татарлар мөселманнар арасында панисламизм, пантюркизм мәсләген тараталар иде. Соңгы елларда аларның максудлары хөкүмәткә мәгълүм булды. Вә шул сәбәптән күп җирдә мөселманнар арасында тентүләр ясалып бик күп язулар мөсадәрә кылынды. Сарапул өязендә панисламизм хакында башлап йөргән кешеләрдән Бубый мөдәррисләре хәбескә алындылар. Имди андый кешеләрнең башка җирләрдә дә тамырларын корытырга кирәк" диләр, вә башкача гакылга сыймаслык сүзләр язып, зурларга яхшы атлы булырга тырышалар. Хәлбуки, аңлы кешеләр фикеренчә, анда бик зур әһәмият бирерлек эш юк. Чөнки безнең Русия мөселманнары арасында панисламизм фикере булганы да юк, булачак та түгел. Андый булмас хыяллар белән гомер үткәрүнең мәгънәсезлеген һәр аңлы кеше белә инде. Бәлки бәгъзе кешеләр минем ул сүземә игътираз кылырлар. "Соң алай булгач, Бубыйлар ни өчен хөкемгә бирелделәр?" — диярләр. Аларга җавап шул: ул хосусый эш. Аны гомумгә иснад итәргә ярамый. Аннан соң аларның панисламист булулары катгый мәгълүм түгел әле. Хакыйкать мәхкәмәдә мәгълүм булыр.

Русиядә ихтилал башланган заманнарда суллык фикере күп кешегә тәэсир иткән иде. Ул вакытта могтәдил мәсләктәге кешеләр дә суллыкка мәел итеп киткән иделәр. Бәлки шул заманнарда Бубый мәхдүмнәр дә низамга сыймаслык нәрсәләр язып ташлаганнардыр. Ләкин аңа тәэсире заманнан килгән хәл дип карарга кирәк.

Соңгы елларда Русиянең күп җирендә мөселманнар арасында тентүләр ясалды төрле язулар, китаплар мөсадәрә кылынды. Ләкин гаепле нәрсәләр табылмады. Шул сәбәптән китап вә язуларның гарәпчә һәм татарча белүче мәэмүрләр тарафыннан укылганнары кире ияләренә кайтарылдылар. Әгәр дә уң газеталар яккан гаепләр булса, кайсыбер җирдән "Иттихад вә тәрәкъкый" комитетының печатьләре һәм Төркия флотына иганә җыйганны язган дәфтәрләр вә башка кәгазьләр табылыр иде. Хәлбуки, андый нәрсәләрнең барлыгы һич тә ишетелгәне юк. Дөрест, соңгы елларда бәгъзе бер муллалар Төркия флотына иганә җыюда мөттәһим булып урыннарыннан чыгарылдылар. Ләкин аларның ул хәлгә дучар булуларына донос сәбәп булды. Кайсыбер муллалар вә байгуралар дошман имамнары өстеннән мәэмүрләргә сигаять кылып ачуларын алдылар.

Бәгъзе мәэмүрләр исә андый кешеләрнең доносларын ватанпәрвәрлекләреннән күреп, һәммә сүзләренә әһәмият бирделәр.

Шулай итеп, шәхси ачулар сәбәпле, күп имамнарның указлары алынды, күп гаиләләр тәрбиясез калды... Әгәр дә ул эшнең хакыйкате хөкүмәткә мәгълүм булмаса, доностар һәм указ алулар һаман дәвам итәчәк иде. Ниһаять мәэмүрләрнең күбесе доносларның ни сәбәптән ясалганлыгын аңлады. Доносчыларга илтифат калмады. Бәгъзе җирләрдә ялган донос ясаучылар үзләре хөкемгә бирелә башладылар. Чөнки Русиядә гадәләт низамы буенча кешене һичбер төрле тарикъ илә җәберләргә юл юк.

Мин могътәбәр имамнарның берсеннән Төркия флотына акча җыю мәсьәләсе кайдан чыкты диеп сораган идем. Ул хәзрәт Духовный Собраниенең игътибарсызлыгыннан бераз шикаять итте, "Мәхкәмәи Шәргыя әллә нинди чуалчык гыйбарәләр илә язылган циркуляр җибәреп, имамнарга Төркия флотына иганә җыймаска кушкан иде. Аны русча белми торган муллалар түгел, русча яхшы укый торганнарының да күбесе аңлый алмады. Бәлки, бәгъзе имамнар, "Духовный Собрание иганә җыярга куша дип аңлаганнардыр" диде һәм шулай булырга да тиеш. Чөнки мәзкүр циркуляр таралганчы, ул хакта имамнарга бер нәрсә дә мәгълүм түгел иде. Уң газеталарда "Һиндстан мөселманнары төрек флотына иганә җыялар. Безнең Русия мөселманнары да җыя торганнардыр" дип язылганлыктан, Дахилия вәзараты ул мәсьәләне игътибарга алган иде.

***

26 майда иртән сәгать 11дә Сарапулга килеп җиттек. Пароходта Бубый мәхдүмнәре эше хакында хәбәр алырга теләсәм дә мөмкин булмады. Чөнки ул эшкә әһәмият биргән кеше юк иде. Фәкать Тройский ягыннан килгән бер мөселман гына Түнтәр Ишми мулланың Сарапулга барган вакытта бик курыкканлыгын сөйләде. "Ул үзен саклап бару өчен солдат сораган икән. Бирелгәнен яки бирелмәгәнен белмим"- диде.

Пристаньга килеп төшкәч, иптәшем номерларның бик тыгыз булу ихтималын сөйләп, багажларымны пристаньда калдырырга киңәш бирде. Соңра аның илә бергә өч сәгать кадәр йөреп, Сарапулга килгән кешеләр хакында мәгълүмат алдык. Шаһитләрнең күбесе килеп җиткән инде. Казанда Ишморатов белән Мөхәммәджан Хафизны иртәгә килеп җитәр, диләр. Ишми мулла кичә иртә белән килеп, үзенең якын мөридләреннән Ягъкуб Тимкинның йортына төшкән. Ул үзенең

мөәзине Әхмәджан белән килгән. Алар җомгага кадәр килеп җитсәләр дә, Ишми җомга намазына кермәгән. Бер кешедән: "Ник кермәде?" – дип сораган идек, "Курыкканлыктан булырга кирәк", – диеп җавап бирде.

Бергә килгән кешеләрнең сөйләүләренә караганда Ишми пароходта бер дә сөйләшмәгән, һаман пароходның бер почмагында мөрәкабәгә киткән хәлдә килгән. Фәкать аның мөәзине генә бераз сөйләшкәләгән. "Хәзрәт бер дә русча белми, мин мәхкәмәгә тәрҗеманлык кылырга барам" дигән.

Соңгы сәнәләрдә халык арасында зур "шөһрәт" казанган ишан җәнабләрен күреп сөйләшү безнең өчен әһәмиятле иде. Шул сәбәптән иптәшем белән ул төшкән йортка киттек. Урамның чатында тәрәзә төпләренә "Сәламәтил-инсани фи хифзыль-лисани" кеби язулар, аятьләр һәм шәмаилләр куелган бер йортның янына килеп туктагач, шушы булырга кирәк дип уйлаган идек. Шул арада урамнан узып бара торган бер марҗа "Тимкин йорты шул", диде. Иптәшем миңа карап "кыйнап чыгармасыннар тагы" дигән иде. Шулай булса да ишек алдына кереп киттек. Анда тулы гына битле бер татар йөри иде.

Аны йорт хуҗасы булырга кирәк, дип уйладык. Без үзебезнең газета мөхбире икәнлегебезне сөйләгәч, ул кеше безгә илтифат итә төште һәм ачык йөз илә: "Хәзер кереп әйтәм. Шаять күрергә мөмкин булыр", – диде һәм карточкабызны алып кереп китте. Без максудыбыз була ахры, дип көтеп торсак та, өметебез бушка чыкты. Биш минуттан соң теге кеше чыгып, кабул итәсе килмәгән вакытта һәр кеше тарафыннан әйтелә торган сүзне тәкрар итте. "Ул хәзер йоклый әле. Кайчан торасын белмим", – диде. Без, кичкә табарак яки иртәгә керергә мөмкин булмасмы дип сорасак та, "белмим"нән башка җавап ала алмадык. Ул кеше безгә ялганлаган булырга кирәк, чөнки өйлә намазы вакытында ишан хәзрәт йоклап ятмас, дип хәтергә килә.

Халык арасында сөйләнгән сүзләргә караганда, Ишми Бубыйлар эше хакында ошбу сүзләрне сөйләгән имеш: "Мин Русиядә иттихады ислам фикере барлыгын беләм, ләкин Габдулла вә Гобәйдулла Бубыйларның панисламист икәнлекләрен әйтә алмыйм. Шулай булса да, Аларның һәммә эшләре Коръәнгә һәм шәригатькә хилаф. Шулай булгач хөкүмәткә дә хилаф булырга кирәк" – дигән, имеш. Ләкин аның хакыйкате мәхкәмәдә сөйләгәннән соңра мәгълүм булыр.

## Палата мәхкәмәсе

Казан палата мәхкәмәсенең күчмә һәйәте берничә көннән бирле Сарапул шәһәрендә төрле эшләр карау илә мәшгуль. 28ендә Бубыйларның эшләре каралачагы хакында язу бар.

Без мәхкәмәгә керергә урын алып калу хакында сөйләшергә мәхкәмәнең канцеляриясенә барган идек. Мәхкәмәнең сәркятибе безне ачык йөз илә кабул итте. Ләкин мәхкәмәгә керер өчен хәзердән үк урын тәгаен кылырга мөмкин булмаячагын игълан кылды. "Мәхкәмәнең ябык ишектә, яки ачык ишектә булачагы хәзергә мәгълүм түгел. Анысы рәис ихтыярында. Бәлки бәгъзе мәҗлес ябык, кайсылары ачык булыр. Аны вакыт җитмичә әйтеп булмый", - диде.

## Шаһитләр

Ишетелгән хәбәрләргә караганда мәхкәмәгә прокурор тарафыннан 12, Бубый мәхдүмнәре тарафыннан 32 шаһит чакырылган. Соңгылар арасында Сарапул земствосының сабикъ рәисе һәм хәзерге көндә нотариус булып торучы Тунин, Сарапул купецы гласный Смагин һәм мәхәллә училищеләренең инспекторы кәшиш Ананьин да бар. Алар моннан мөкаддәм земство мәҗлесендә Бубый мәдрәсәсенә акча бирү хакында иҗтиһад иткәннәр. Шуның сәясендә "училищный совет земстводан пособиене Бубый мәдрәсәсенә генә, яки Бубыйдан укып чыккан, яки шунда имтихан тоткан имам вә мөгаллимнәрнең мәктәпләренә генә бирергә мөмкин" дип карар биргән. Имди хәзердә шул кешеләр Бубый мәхдүмнәрнең хөкүмәткә хилаф булмаганлыкларын сөйләр өчен чакырылганнар. Аларның башка шаһитләре Бубый халкыннан һәм Бубый мәдрәсәсендә укыган шәкертләрдән гыйбарәт.

Мәхкәмә тарафыннан чакырылган шаһитләр арасында Бубый авылының Шаһимәрдан Аппаков исемле кеше белән углы бар. Ул кеше хакында Бубый авылыннан килгән бер кешене күреп сорашкан идем. Әгәр дә аның сүзе дөрес булса, Аппаков белән Бубый мәхдүмнәр арасында шәхси дошманлык булган. Мин сорашкан әфәнде ул хосуста ошбу сүзләрне сөйләде: "Аппаков ул һәрвакыт бәйләнеп йөрергә ярата торган куштан кеше. Аның хәзрәтләргә ачуы бар. Бубый авылында 1910 елда ваба булган вакытта Гобәйдулла әфәнде земствога мөрәҗәгать итеп табиблар сораган иде, шул вакытта Шаһимәрдан табиблар китерүгә каршы торды. Шулай булса да табиблар килделәр. Алар авыруларны аерып куяр өчен барак ачарга фатир сораган-

нар иде. Шаһимәрдан һаман халыкны котыртуында дәвам итте. Докторлар дару биреп минем энемне һәм сеңелемне үтерделәр дип сөйләде. Шуның өчен аның өстеннән протокол куелды һәм аны Вятка губернаторының карары белән бер айга хәбес кылдылар. Аннан соң Аппаковның углы низамга һәм програмга мөхаләфәт кылганлыгы өчен Бубый мәдрәсәсеннән сөрелгән иде. Аппаков аның өчен дә Бубый мәхдүмнәрне ачуланды.

Бубый мәхдүмнәрнең аңа күп яхшылыклары да тиде. Мәсәлән, Бубый авылы янгач, Шадимәрдан аларга мөрәҗәгать итеп, йорт салырга акча сораган иде. Акчаны, йортына шәкертләрне һәм мөгаллимнәрне фатирга җибәреп, җыйганнан соң түләргә вәгъдә иткән иде. Бубыйлар аңа акча бирсәләр дә, Шаһимәрдан вәгъдәсендә тора алмады. Шул ачудан Шаһимәрдан мәхдүмнәргә янып йөргән иде, һәм Бөре өязендә мәхдүмнәрнең якыннарыннан Бәдретдин Җәлалетдиневтә тентү ясалуда аның дәхеле булганлыгыннан шөбһәләнгәннәр иде" диде.

Шагыйрьләребездән Нәҗип Думави да мәхкәмә тарафыннан шаһитлеккә чакырылган. Нәҗип әфәнде үзе аңа гаҗәпләнә. Мин прокурор ягыннан чакырылганымны Казанга баргач кына белдем, ләкин сәбәбе миңа ачык мәгълүм түгел", ди.

Сарапулга Бубый авылыннан барысы 20 кадәр кеше килгән.

## Габдулла һәм Гобәйдулла әфәнделәр

Хәзерге көндә хәбесханәдә ята торган Бубый мәхдүмнәр хакында хәбәр алырга муәффәкъ булдым. Күргән кешеләрнең сөйләүләренә караганда, аларның сәламәтлекләре ярыйсы икән. Мин сораган кеше аларның хәбесханәдә ничек торганлыкларын сөйләде. "Алар хәзерге көндә бакча эшләре илә шөгыльләнәләр. Кай вакытта үзләре агачлар һәм яшелчә утырталар һәм анда эшләүче кешеләргә нәзарәт итәләр. Аларга язарга һәм мөселман китапларын укырга мөмкин түгел. Хәбесханәнең көтепханәсеннән русча китаплар бирелә. Алар шул китапларны укыйлар. Мәхдүмнәрнең җәмәгатьләре чәршәмбе саен Сарапулга килеп, күрешеп китәләр. Ике арадагы мөсафә 50 чакрым булса да, атнада бер мәртәбә килмичә калганнары юк. Бубый авылында аларның сату эшләре искечә дәвам итә. Аны Зыя әфәнде карап, алып бара", – диде. Хәбесханәдә ятучы кешеләрнең бер-икесе сәяси мәхбүсләр, калганнары башкача җинаять эшләүдә мөттәһим булган кешеләрдән гыйбарәт икән. Мәхдүмнәр икесе бер

бүлмәдә торалар һәм ашларны үзләренә аерым пешертәләр икән.

## Мөдафигъләр

Бубый мәхдүмнәрне Дәүләт Думасы әгъзаларыннан Маклаков, Казан адвокатларыннан Бать һәм Сарапулның Егоров мөдафәга итәләр. Ибраһим Әхтәмевнең киләчәге хәзергә мәгълүм түгел. Алкин җәнабләренең дә килүен ихтимал тоталар.

Маклаковның 27 майда Нижнийдан килергә чыкканлыгы хакында телеграм алынды. Мөдафигъләр иртәгә килеп җитсәләр кирәк.

## Шәһәрдә

Сарапул шәһәрендә читтән килгән халык бик күп. Номерлар һәммәсе мөсафирлар белән тулган.

"Йолдыз" һәм "Бәянелхак"ка башка газетлардан мөхбирләр килгәнлеге хәзергә мәгълүм түгел.

Шәһәр халкы, гомумән, Бубыйлар эше хакында сөйләшергә курка. Ике-өч кеше урамда җыелып торырга да шикләнә. Хәфияләр бар дип шөбһәләнәләр, ахры.

Бубый мәхдүмнәрнең анасы белән хатыннары һәм балалары сишәмбе көннән бирле монда торалар. Алардан мөттәһимнәрнең эшләренә ничек караганлыкларын сораган идем. "Без, котылырлар дип өмет итәбез. Чөнки аларның гаепләре юк. Ул мескеннәрне нахак бәла белән генә судка тарттылар" дип җавап бирделәр.

## Май-27

Бүген мәхкәмәгә тәгаллекъле кешеләрнең күбесе килеп җитте. Кичке пароход белән мөдафигъләрдән Маклаков белән эксперт Катанов җәнабләре килгән иделәр. Аннан соң көндез белән икенче пароход илә Бать һәм Ибраһим Әхтәмев җәнабләре килделәр. Алар белән бер пароходта мәхкәмә тарафыннан чакырылган шаһитләрдән казанлы Мөхәммәдҗан хафиз да килде. Мин аның кая төшкәнлеген урамдагы бер кешедән сораган идем. Кая төшкәнен белмим, дип җавап бирде.

Соңра тәсадефи уларак, аны урамда очраттым, "Ник килдегез?" дип сораган сөалемә каршы Мөхәммәджан хафиз:

— Мин үз ихтыярым илә килмәдем, чакырып китерделәр ич, — дип җавап бирде. Казанда вакытта мин аны һәрвакыт күрә идем. Ул һаман үзенә махсус каһкаһәсе белән кычкырып көлеп йөри иде. Бүген, ни сәбәптәндер, ул миңа кайгылырак күренде. Соңра мин аннан, "Сез Ишмөхәммәд хәзрәт белән күрешкәнегез бармы, аның белән мөнәсәбәтегез ничек?" — дип сорадым. Мөхәммәджан хафиз:

— Мин аның белән таныш түгел, күрешергә дә теләмим... Мин һичбер кешегә катышмыйм. Һәрвакыт үз фикерем белән йөрим, — диде.

Кичә Ишми Сарапулның ахуны Хөсәен хәзрәтнең ханәсендә миһман булган. Ахун хәзрәтне күреп, аның мәҗлестә Бубыйлар хакында нәрсә сөйләгәнлеген вә үзенең аңа нинди күз белән караганлыгын сораган идем. Хәзрәт:

— Бер нәрсә дә сөйләмәде. Ул хәзер 72 яшьлек карт кеше. Мин аңар могтәдил караш белән назар итәм. Чөнки ул гасаби авыру белән мөбтәля. Үзе күп вакытта бер-берсенә хилаф сүзләр сөйләп ташлый, — дип җавап бирде.

Кичкә таба газета мөхбирлеге өчен күңелсез хәбәр халык арасында сөйләнә башлады. Бәгъзе кешеләр ышанычлы мәнбәгъләрдән алып, мәхкәмә мәҗлесләренең ябык булачагын сөйләделәр. Ул исә, безнең өчен бик үк күңелле түгел, чөнки без иттиһамнамәгә, шаһитләрнең сүзләренә һәм мөдафигъларның нотыкларына зур әһәмият биргән идек. Мәҗлесләр ябык булса, мөхтәрәм укучыларга Бубый мәхдүмнәр эше хакында тәфсилле мәгълүмат бирү уңайсыз булыр.

Хәзердә Сарапул шәһәре читтән килгән мөселманнар белән тулды диярлек. Урамнарның һәммә җирендә фатир эзләп йөрүче, яки сөйләшеп торучы мөселманнарны күрергә мөмкин.

## Мәхбүсләр хакында

Ахун Хөсәен Әбүбәкерев җәнабләренең сөйләвенә караганда, Сарапулның хәбесханәсендә төрле җинаять белән мөттәһим булган 20 ләп мөселман бар икән, Ахун хәзрәт атнада, яки ике атнада бер мәртәбә килеп, аларга намаз укыткан. Ләкин Бубый мәхдүмнәргә башка мөселман мәхбүсләргә катышырга мөсагадә бирелмәгән.

Узган кыш Хөсәен хәзрәт Габдулла һәм Гобәйдулла мәхдүмнәргә башка мәхбүсләрне ияртеп гыйбадәт кылдырырга

рөхсәт бирү хакында хәбесханә начальнигына мөрәҗәгать иткән икән, начальник:

— Алар сәяси эш белән мөттәһим булган кешеләр. Шул сәбәптән, аларны башка мәхбүсләргә катыштыру мөмкин түгел, — дип җавап биргән.

## Харис Сәйманов

1911 ел, 29 гыйнварда Сарапул өязе Бәйки авылында 7 ел имам һәм соңгы ике елда учитель булып торган Харис әфәнде Сәймановның ханәсендә тентү ясалып, бәгъзе хатлары һәм халыкка сөйли торган вәгазь китабы мөсадәрә кылынган икән, соңра үзе хәбескә алынып Сарапулга җибәрелгән һәм анда 10 ай ябылып ятканнан соңра чыгарылган.

Ул Бубый мәдрәсәсендә укыганлыгы өчен Бубыйлар белән бер фикердә булуда мөттәһим булып хәбескә алынган. Аның вәгазь китабында "мөселманнар бер-берсенә кардәшләр, шул сәбәптән бер-берегезгә ярдәм итәргә тырышыгыз!" мәфһүмендә бәгъзе сүзләр язылган икән, мәхкәмә мөфәттише ул сүзләр өчен генә Харис әфәндене хөкемгә тартырга мөмкин булмаган. Шулай булса да, аның китабы һәм хатлары бүгенгә кадәр кире кайтарылмаган. Үзе хәбескә ябылганнан соңра аның учительлек хокукы алынган икән, соңра хәбесханәдән чыккач, муллалыкка бирелгән указын да алганнар.

Хәзер шул әфәнде мәхкәмәдә Габдулла вә Гобәйдулла мәхдүмнәр ягыннан сөйләр өчен Сарапулга китерелгән.

Харис әфәнде үзенең учительлек хокукын алырга мөмкин булуы яки булмавы хакында Маклаков җәнабләрен күреп сөйләшкән икән. Маклаков аңа Петербургка кайтканнан соңра хәбәр җибәрергә вәгъдә кылган.

## Әхмәдфаиз Даутов

Бубый мәдрәсәсенең сабикъ мөгаллимнәреннән Әхмәдфаиз Даутов прокурор тарафыннан мәхкәмәгә чакырылган иде. Ул килгәне юк әле. Петербургтан чыкканлыгы хакында телеграм алынган дип таралса да, хакыйкате мәгълүм түгел, бәгъзе кешеләр аңа повестка бирелмәгән имеш, дип сөйлиләр.

## Суд көне

Бүген шәһәргә иртәнге пароход белән янәдән йөз кадәр мөселман килде. Аларның күбесе Бубый мәхдүмнәрнең эшләре белән танышыр өчен килгән иде.

Иртәге сәгать 7дән үк палата мәхкәмәсе мөзакәрә итә торган Окружной суд бинасы һәм Бубый мәхдүмнәр яткан хәбесханә янына бик күп халык җыела башлады. Алар арасында читтән килгән мөсафирлар булган кеби, якын авыллардан җыелган крестьяннар, хатын-кызлар һәм руслар да күп иде. Сәгать 8дә мәзкүр эшнең ябык ишектә каралачагы, мәҗлескә газета мөхбирләреннән һәм чит кешеләрдән берәү дә җибәрелмәячәге мәгълүм булды. Хәтта Сарапул окружной мәхкәмәсенең прокурор мөгаувиненә дә керергә мөсагадә бирелмәде. Шулай булса да халык китми, ерактан гына булса да Габдулла вә Гобәйдулла мәхдүмнәрне алып килгәнне күрергә тели, кайсылары мәхкәмәнең рәисе килгәч, керергә рөхсәт бирелүне өмет итәләр. 9.30 да мәхбүсләрне сакчы солдатлар белән мәхкәмәгә алып килделәр. Бубый мәхдүмнәр үз киемнәрен кигән иделәр. Аларның алдында мәхкәмә тарафыннан каторга хөкем ителгән ике арестант та бар иде. Бәгъзе кешеләр шуларны Бубый мәхдүмнәр дип фараз кылсалар да, соңра эшнең хакыйкатен белделәр.

Халык көн буенча мәхкәмә янынннан өзелеп тормады. Бер җиргә табын-табын хатыннар, икенче җиргә авылдан җыелган крестьяннар вә башка халыклар утырган иделәр.

Сарапул шәһәренең руслары ул кадәр күп кеше җыелудан бик гаҗәпләнделәр. Мин мәхкәмәнең хезмәткәреннән "Монда шулкадәр күп халык җыелганы бар идеме?" — дип сораган идем. Ул "мин бу мәхкәмәдә 7 елдан бирле торам, һичбер вакытта андый күп кеше килгәнне күргәнем юк иде" дип җавап бирде.

Мин бу тирәдәге кара русларның Бубый мәхдүмнәр хакында нинди фикердә булганлыкларын белү өчен бер-ике рустан "монда нинди кешеләргә хөкем итәләр соң?" — дип сорадым. Алар: "Бубый муллаларына хөкем итәләр. Алар Мәккәдә укып кайткан бик галим кешеләр. Хәтта 12 төрле тел беләләр. Бубый авылында аларның университетлары бар. Хәзердә сәясәткә катышканлыклары өчен хөкем ителәләр", — дип җавап бирделәр.

Кичке сәгать 4.30да шаһитләрдән сорау тәмам булганлыгы аңлашылды. Алар мәхкәмәдән чыгарылдылар. Ишми мулла да мәхкәмәдән чыккан иде. Казаннан шаһит булып барган бер кеше аның кулын үбеп күреште. Башка кешеләр аны тәхкыйрь кылып, төрлечә сүзләр әйтеп артыннан калдылар.

Мәхкәмәдә сөйләп чыкканнан соңра казанлы Мөхәммәджан Әхмәревнең күңеле ачылды. Үзе мәхкәмә тирәсенә янадан килергә курыккан булырга кирәк. Кичке сәгать 10нарда аның Сарапул пристаненнән ерак бер урамда саташып, Каминский пристанен эзләп йөргәнен күргәннәр. Ул бер кешегә, бик шәп сөйләдем дип мактанган.

Мәхкәмәдә эш бетәргә якынлашканлыктан, кичке сәгать 9дан ук янәдән бик күп халык җыела башлады. Аларның барысы тәхминән 600 кадәр булыр иде. Мәхкәмәнең карары игълан ителгән вакытта халыкка керергә мөмкин булыр дип көтелгән иде. Ләкин көткәнчә булмады. Атлы стражниклар, полицейскийлар җыелган кешеләрне мәхкәмәнең яныннан ук куа башладылар. Шул сәбәптән халык бик зур тәшвишкә төште. "Ахры, зур җәза бирә торганнардыр" дип сөйли башладылар. Ниһаять, сәгать 11дә мәхкәмәнең карары игълан ителгәнлеге мәгълүм булды.

Соңра, халык арасында "берсенә алты ай, берсенә өч ай төрмә" дигән хәбәрләр таралса да, мөдафигълар чыккач, Габдулла әфәнденең алты айга, Гобәйдулла әфәнденең ике айга, хокукларыннан мәхрүм ителмичә, крепостька ябылырга хөкем ителгәнлекләре һәм ике айга хәбесханәдән чыгарылачаклары мәгълүм булды. Бераздан мәхдүмнәрне алып чыгып, хәбесханәгә төшерделәр. Мөттәһимнәргә бик үк авыр җәза бирелмәве халыкка бик яхшы тәэсир итте. Һәр җирдә сөенеп сөйләнгән сүзләр ишетелде. Шул төнне, яңгырява башласа да, мәхбүсләрне чыгарырлар дип хәбесханә янына байтак халык җыелып торды. Ләкин аларга шул төнне үк чыгарга мөмкин булмады. Җыелган халыклар әкренләп фатирларына таралдылар.

## Габдулла вә Гобәйдулла әфәнделәр

Бубый әфәнделәр 29 нчы майда көндезге сәгать 11 дә хәбесханәдән чыгарылдылар. Каршы алырга килгән кешеләрнең, атлы вә җәяүле булсын, хәдде вә хисабы юк иде: хәбесханәдән полиция идарәсен кадәр урам бөтенләй халык белән тулган иде. Хәбесханәдән полициягә вә аннан фатирларына кадәр атлы стражниклар халыкны ике якка аерып килделәр вә берничә вакыткача ишек төбендә тәртипне саклап, күрешергә килгән кешеләрне берәм-берәм кертеп тордылар.

Соңра мәхдүмнәр балалары һәм җәмәгатьләре илә бергә Бубыйга кайтып киттеләр.

Мин аларның указлары бирелүе яки бирелмәве хакында Ибраһим Әхтәмев җәнабләренең фикерен сораган идем. Ул ошбу рәвештә җавап бирде:

— Судның карары буенча мөттәһимнәр хокукларыннан мәхрүм ителмәделәр. Ләкин аларга указларын янәдән бирү яки бирмәү губернский правление ихтыярында, — диде.

Мәхкәмәдә эше каралган вакытта жандармский вахмистр, китаплары мөсадәрә кылынган мулла вә мөгаллимнәргә нәрсәләрен килеп алырга кушты. Бубый мәхдүмнәрдә һәм башка кешеләрдә тентү ясалган вакытта өч йөктән артык төрле китаплар конфисковать ителгән икән. Гарәпчә һәм татарча белә торган кешеләргә күрсәткәннән соң, ул китапларда матбугат низамына хилаф сүзләр язылмаганлыгы мәгълүм булган. Шул сәбәптән хәзердә аларның һәммәсен хуҗаларына кайтарып бирелергә тиешле.

Сарапулның кара байларыннан берсе мәхдүмнәргә авыррак җәза бирелсә, фәкыйрьләргә йөз сум садака өләшергә вәгъдә кылган икән, аз җәза бирелүдән байның кәефе киткән булырга кирәк: суд соңында сорашырга барган теләнчеләрне ачуланып җибәргән.

## Маклаков белән мосахәбә

Бик ашыгыч вакытта гына Дума әгъзасы Маклаков белән бераз сөйләшергә муәффәкъ булдым. Маклаков җәнабләре мәхкәмәдә нотык сөйләп чыкканнан соңра кичке пароход белән китәргә хәзерләнеп йөри иде. Шулай булса да, мәхкәмә эше һәм панисламизм мәсьәләсе хакында минем сораган берничә сөалемә җавап бирде. Аның сөйләгән сүзләре шуннан гыйбарәт:

"Мәхкәмәдә сөйләнгән сүзләрдән Бубыйларның панисламист түгел икәнлекләре бик яхшы аңлашылды. Мин иттихады ислам хосусында уң газеталарның тараткан хәбәрләрен ялган дип уйлыйм, һәм ул фикернең Русия мөселманнарында булмавына ышанам" диде. Соңра аннан: Мөселман фракциясенең Думадагы эшләреннән панисламизм фикере аңлашылмыймы? — дип сораган сөалемә Маклаков:

— Һич тә аңлашылмый, — дип җавап бирде.

## Ишми

Бубый мәхдүмнәрнең зарарына сөйләргә барган Түнтәр ишаны Ишмөхәммәд Динмөхәммәдев Сарапулда һичкая чыгып йөрмәде. Сарапул ахуны Әбүбәкеревнең углы Түнтәр мәдрәсәсендә укый икән. Шул сәбәптән булырга кирәк: Ишми кеше күрмәгән вакытта гына ахунд хәзрәтнең өенә миһман булып барган. Аларның ике арадагы мөнәсәбәтләре миңа мәгълүм түгел, фәкать Ишми хакында фикерен сораган вакытта Әбүбәкерев миңа:

— Мин Ишмөхәммәд хәзрәтне "урман әүлиясына ошатам" – дигән иде.

Суд көнне мәхкәмә янына халык иртәнге сәгать 7 дән үк җыела башласа ди, Ишминең килгәнен күргән кеше булмады.

"Ишми бик кайгыра икән, бүген иртә белән сәгать 4 тән үк әллә кая китеп югалган" дигән хәбәр халык арасына таралган иде. Кешегә күренмәс өчен мәхкәмәгә иртә үк килгән булырга кирәк.

Мин аны мәхкәмәдән чыккан вакытта күреп калдым. Яшь вакытта Шиһаб хәзрәт Мәрҗани белән тарткалашуы һәм хәзерге көндә ысуле җәдидкә каршы килүе белән шөһрәт тапкан ишанны күргәч тә, минем хәтеремә казаныйларга бик мәгълүм "Сыйпама ишан" килеп төште.

Казанга кайткан вакытта миңа аның белән бер пароходка утырырга туры килде. Ул беренче класснын каютына бикләнгән иде. Бер мәртәбә тәрәзәсе яныннан узып барган вакытта пароходның идәненә утырып торганын күрдем. Сарапулда вакытта миңа бер кеше "Ишми ысуле җәдидкә каршы килү өчен урындыкка утырмый икән" дигән иде. Аның пароход идәненә утыруы да шуннан булырга кирәк. Ләкин ул ни өчен ысуле җәдид пароходының беренче классына утырып йөри икән? Аңа кадимчә генә җәяү, яки ат белән генә барса ярамаган микәнни? Зарурәт җәһәтеннән пароходка утырырга туры килсә дә, тарикать юлындагы кешегә беренче класста баруга караганда фәкыйрьләр илә бергә 3 нче яки 4 нче классында йөрү артыграк, саваплырак булмас микән?

Берничә пристаньне узгач, Ишминең палубага чыгып утырганын күрдем. Үзе һаман як-ягына ялт-йолт карана. Мөселманнар килә дип курка, ахрысы. Кайчакта кашынып та куя. Башына мескен бүрек, өстенә сырган бишмәт, аягына биек үкчәле саурыйлы кәвеш кигән. Чалбар-фәлән юк.

Шул арада аның янына, мөселманмыдыр, русмыдыр, эшләпә кигән бер адәм килеп русча:

— Кая бардыгыз?-дип сорый.

Ишми русчаны бераз аңласа да, сөйләшә алмый икән, шулай булса да, бераз җавап бирергә маташа.

— Сарапул хадил. Тимкин густь, — ди. Ахры Сарапулга Тимкинга кунакка бардым димәкче була торгандыр.

Теге адәм аннан суд эшләре хакында сорагач, Ишми:

— Да, да мин судка бардым, — ди. Русча сүзләр арасына татарча катыштырып бетерә. Эшләпәле адәмнең, кемнәрне хөкем иттеләр? — дип сораган сөаленә каршы Түнтәр ишаны:

— Бубый муллаларын. Новый метод, новый метод, — ди. Ысуле җәдид өчен димәкче була торгандыр, ахры. Мескен Ишми судка барып та, мәхдүмнәрнең ни өчен хөкем ителгәнлекләрен белмичә кайткан.

Теге адәмнең күпмегә хөкем иттеләр диген сүзенә каршы Ишми алты бармагын күрсәтә. Бәлки телсез кеше белән сөйләшәм дип белгәндер.

Сонра ул "Миңа Катанов кирәк иде" дип эзләргә тотына. Ләкин профессор Катанов җәнабләре аннан алдагы пароходта кайтып киткән иде.

Сарапулда вакытта "Мизан" исемле китабында ысуле җәдид тарафдарларын үтерергә димләп язган өчен Ишми судка биреләчәк икән" дигән хәбәрләр халык арасында сөйләнгән иде. Бәлки Ишми шул хакта сөйләшер өчен Катанов җәнабләрен эзләгәндер.

Пароход Алабугага җиткәч, Ишми төшеп калды.

## Килмәгән шаһитләр

Мәхдүмнәрнең зарарларына сөйләүчеләрдән Әхмәдфаиз Даутов, әүвәлдә Казанда Юнусовлар приютында учитель булып торган Гафиятуллин һәм Казан сәүдәгәрләреннән Ишморатов мәхкәмәгә килмәгәннәр.

Г. Латыйф. "Йолдыз".- 1912.- 27 май, 31 май, 3 июнь (№№ 837, 839, 840).

мәсләк — фикер
максуд — максат
мөсадәрә кылу — конфискацияләү
хәбес — кулга алу
имди — инде
зурлар — хөкүмәт
бәгъзе — кайбер
игътираз кылу — каршы килү
иснад итү — аудару
ихтилал — 1905-07 еллардагы революция хәрәкәтләре күздә тотыла
мәхкәмә — суд

мәел итеп — авышып
низам — тәртип, закон
мәэмүр — чиновник
иттихад вә тәрәккый — берлек һәм прогресс
мөттәһим булып — гаепләнү
сигаять кылу — донос
гадәләт низамы — юридик законнар
тарикъ — юл
мәзкүр — бу
Дахилия вәзараты — Эчке эшләр министрлыгы
мөхбир — хәбәрче
мөрәкабәгә киткән хәлдә — уйланып
иттихады ислам — панисламизм
һәйәт — коллегия
сабикъ — элекке
кәшиш — поп, монах
мөкаддәм — элек
иҗтиһад итү — тырышу
сәясендә — нәтиҗәсендә
хосуста — хакта
мөхаләфәт — каршылык
дәхел — катыш
хәбесханә — төрмә
муаффәкъ булу — ирешү
нәзарәт — контроль, җитәкчелек
мөсафә — ераклык
мәхбүс — тоткын
мөдафигъ — адвокат
мөдафәга итү — яклау
хәфия — яшерен полиция кешесе, шымчы
мәхкәмәгә тәгаллекъле — судка бәйләнешле
тәсадефи уларак — очраклы буларак
миһман — кунак
могтәдил — уртача
гасаби авыру белән мөбтәля —нерв авырулы
мәнбәгъ — чыганак
иттиһамнамә — гаепләү акты
мөсагадә — рөхсәт
мәфһүм — эчтәлек
мәхкәмә мөфәттише — суд тикшерүчесе
мәхкәмә мөзакәрә итә торган — суд процессы була торган
мәзкүр — югарыда әйтелгән
мөгаувин — ярдәмче
мөсагадә — рөхсәт
тәхкыйрь кылу — мыскыллау, сүгү
тәхминән — якынча
казаныйлар — казанлылар
зарурәт — зарурыйлык
тарикать — ишанлык
хәдд — чик
нәрсәләр — әйберләр
мосахәбә — сөйләшү

## Бубыйлар эше тирәсендә
### (Хосусый мөхбиребездән)

26 нчы май

Пароходта барганда Бубыйлар эшенә даир күп мәгълүмат алып булмады. Очраган мөселманнар арасында эшнең хакыйкатен белми: "Түнтәр хәзрәтенең эшенә барасызмы әллә?" — дип сораучылар да булды. Шулай да Бубыйлар эше хакында газеталардан укып һәм болай ишетеп белгәннәр мәхдүмнәрне бик кызганалар.

Бәгъзеләре аларның төрмәгә утыруларын гакылларына сыйдырмыйлар:

"Алар арестантлар утыра торган төрмәгә утырмаслар, аларны бер-бер җиргә ябып кына тота торганнардыр" — диләр.

Сарапулга килеп төшкәч тә тиз генә номер табып булмас дип, багажларыбызны пристаньда калдырып киттек. Вакыйган да шулай булып чыкты. Һәммә номерлар тулган, һичберсендә буш бүлмә калмаган. Шунлыктан безгә номердан-номерга йөрергә туры килде. Бу бер җәһәттән безгә файда да булып чыкты. Номердан-номерга йөри торгач, без Бубый мәхдүмнәренең якыннарыннан күп кешеләрне күрдек, аларның араларында түбәндәге мөһим мәгълүматны бирүчеләрне дә очраттык.

## Мәхдүмнәр хәбесханәдә ничек торалар?

Сарапул хәбесханәсендә мәхдүмнәрдән башка руслардан ике генә сәяси мәхбүс бар. Мәхдүмнәр икесе аерым бер бүлмәдә утыралар. Яз кергәч, үзләренә хәбесханә бакчасында бәрәңге, суган утыртып, аларга һәм куакларга су сибәргә һәм дә шул эштә башка мәхбүсләргә назирлык итәргә мөсагадә иткәннәр. Хәбесханә көтепханәсендә русча әсәрләр күп икән. Мәхдүмнәр русча әсәрләрдән истифадә итәрлек русча мәгълүматлары булганлыктан, күп вакытлар русча әсәрләр моталәга итү белән дә мәшгуль булалар икән. Фәкать русчага башка телдәге әсәрләр укырга гына рөхсәт итмиләр. Сәламәтлекләре хәзерендә һәр икесенең дә яхшырган. Һәр чәршәмбе көн яннарына хатыннары килеп йөриләр икән. Ашны үзләренә аерым пешертергә рөхсәт иткәннәр.

Боларны сорашып бетергәч тә безнең хәтергә Ишмөхәммәд мулла килеп төште.

— Соң ул килгәнме?

Кичә иртә килеп төшкән дип җавап бирәләр, пароходта бергә килгән кешеләрнең сөйләүләренә караганда, ул юлда мөселманнардан һичбер кешегә сәлам бирмәгән һәм сүз кушмаган. Хәзрәт Сарапулга җомгага кадәр килеп җиткән булса да, җомга намазына чыкмаган. Бу кадәре мөсафир булганлыктанмы, әллә гайре сәбәптәнме, белеп булмый.

— Соң ул кая төшкән?

— Үзенең белешенә,- дип җавап бирәләр.

— Барсак, кабул итәр микән, мөриде усал кеше түгелме, барсак кудырып чыгармасмы?

— Ул кадәресенә кәфил була алмыйбыз, күрсәтергә җөрьәт иткән кеше йомшак булмас инде ул, — дигән җавапны бирәләр.

Шулай да барып карыйк әле дип йорты кайсы урамда икәнен сорашып китәбез. Ләкин ничек табарга? Капкаларга йорт хуҗаларының фамилияләре язылмаган. Ә, менә бу түгелме, тәрәзә төпләренә "Сәламәтил-инсани фи хифзыльлисани" дигән язулар һәм төрле шамаильләр бар. Бу йорт булырга бик охшый. Ни булса да булыр дип, керәбез. Йортта безгә таза гына ир уртасы кеше очрый. Без аны күргәч, беркадәр куркып та киткән идек. Ләкин "без газета мөхбирләре" дигәч, аның каушап киткәнен күреп йөрәкләндек.

— Хәзрәтне күрергә мөмкинме?

— Ник мөмкин булмасын, мөмкин булыр, дип карточкабызны алып кереп китә.

Безгә байтак кына көтеп торырга туры килә. Ниһаять, әлеге кешебез чыгып: хәзрәт йоклый икән, ди. Безнең, "тиз торырмы икән, без соңрак булса да килер идек" дигән сөалебезгә каршы: "бер дә әйтә алмыйм", дип җавап бирә.

Соңгы елларда Русия мөселманнары арасында шактый ук исеме чыккан бу хәзрәтне безнең бик күрәсебез килгән иде, һәм аңардан Бубыйлар эшенә даир күп мәгълүмат алырга уйлаган идек. Һәм дә якын мөриденең, күрергә мөмкин булыр дигән сүзләрен ишеткәч, бик шатланышкан да идек. Ләкин, йоклый дип чыгып әйткәч, бик озак киңәштеләр, ахрысы кабул итмәскә булганнардыр, дип өметебезне өзеп китәргә мәҗбүр булдык. Шуннан соң Казан судебный палатасы, күчмә һәйәтенең секретарен барып күрдек, ул суд мәҗлесенең ачык булып-булмавын әйтә алмады, анысы рәис ихтыярында, диде.

Инде безгә шаһитләр хакында мәгълүмат җыйнарга кирәк. китәбез тагын номердан-номерга йөрергә.

## Шаһитләр

Мәхдүмнәрнең зарарларына сөйләүче шаһитләрнең араларында иң әһәмиятлеләре Түнтәр ишаны мәшһүр Ишми һәм Бубый кешесе, мәхдүмнәрнең шәхси дошманы Шаһимәрдан Аппаков вә аның улы.

Ишмөхәммәд хәзрәт моннан өч сәнә мөкаддәм Бубый мәхдүмнәрендә кунакта булган икән. Шул вакыт мәхдүмнәр: "Хәзрәт, без һичбер зарарлы нәрсә укытмыйбыз, рәхим итеп программабызны укып карагыз", дигәннәр. Ишмөхәммәд хәзрәт шуңар каршы "Мин сезнең үзегездә зарарлы нәрсә юк икәнен беләм. Ләкин сезгә ияреп күп кешеләр юлдан язалар. Ташлагыз сез ул эшегезне", дип җавап биргән. Мәхдүмнәр хәбескә алынгач, жандарм мәэмүрләре Ишминең авылына барып допрос алганнар. Допроста аның ниләр сөйләгәнен белеп булмый. Фәкать халык арасында Ишми Бубый мәхдүмнәре шәригатькә вә Коръәнгә хилаф йөриләр. Шәригатькә, Коръәнгә хилаф кеше хөкүмәткә дә хилаф буладыр, дип сөйли, имеш, дигән хәбәрләр бар.

Шаһимәрдан Аппаков Бубый кешесе һәм мәхдүмнәрнең шәхси дошманнары икән. Мәхдүмнәр бу кешегә бурычка акча да биргәләп торгалый булганнар. Ихтимал, шуның сәясендә дә араларында бәгъзе бер низаглар чыккалагандыр. Бубыйда ваба елында араларында низаг чыккан. Мәхдүмнәр халыкны бәладән коткару касды илә докторлар китертергә булганнар. Аппаков шуңарга каршы килеп, "докторлар алар әһалине үлемнән коткармыйлар, бәлки үзләре агулап йөриләр" дип, низаг чыгарып йөргән. Аннан соң Бубый мәдрәсәсендә аның бер малае укый булган. Мәхдүмнәр аны, укуының да рәте юк, тик тәртипсезлек итеп, башкаларга гына тыгызлап йөри дип мәдрәсәдән чыгарганнар. Аппаков шуның өчен дә мәхдүмнәргә бәйләнеп йөргән. Димәк, Шаһимәрдан Аппаковның мәхдүмнәрнең зарарына сөйләве фәкать шәхси дошманлыктан гынадыр.

Прокурор тарафыннан чакырылган шаһитләр арасына мәшһүр шагыйрьләребездән Нәҗип Думави да эләккән. Ул үзе моңарга гаҗәпләнә, мин хәзергә кадәр үземне мәхдүмнәр тарафыннан чакырылганмын дип йөри идем, ди.

***

Мәхдүмнәрнең хатыннары бер атнадан бирле Сарапулда яталар. Алар бик кайгырмыйлар, нахак эләктеләр, коткарырлар дип уйлыйлар.

Сәүдә эшләрен хәзергә Зыя әфәнде карап тора икән.

буенча аларны һәрвакыт башкалардан аерым тотарга тиеш", дип җавап биргән. Шул вакыттан бирле Бубый муллаларын мөселман мәхбүсләренә якын җибәрмиләр икән.

Бубый муллалары файдаларына сөйләүче шаһитләр арасында руслардан да берничә кеше бар. Боларның берсе сабикъ земский управа рәисе вә икенчесе дә Сарапул уездный училищный советның әгъзасы поп Ананьин. Бу кешеләрнең шәһадәтләре гаять әһәмиятле булачактыр. Алар Бубый муллаларының иректә вакыт кылган эшләрен мәгъкул күрә булганнар һәм Бубый мәдрәсәсенә земстводан пособие алып бирергә дә тырышып йөргәннәр.

28 нче май

Хәзергә кадәр ел ярымшар төрмәдә утырганнары өстенә Гобәйдулла мулла ике ай һәм Габдулла мулла алты ай крепостька хөкем ителделәр.

Иртә сәгать җидедән үк Сарапул төрмәсе янына халык җыелган. Ләкин бер кешене дә төрмә капкасына якын җибәрмиләр. Халык урамның ике ягына тезелеп тора. Сәгать тугызынчыларда Бубый муллаларын төрмә капкасыннан алып чыктылар. Алларыннан, артларыннан һәм яннарыннан кылычларын чыгарып конвой солдатлары килә. Муллалар үз киемнәрендә. Без аларга сүз кушмакчы булабыз. Ләкин солдатлар якын җибәрмиләр. Урамнарда руслар да күп, алар да муллалар хакында ишеткәләгәннәр булырга кирәк. Күбесе артларыннан да баралар. Окружной суд каршысына килсәк, анда да халык әллә кайчан җыелып җиткән. Муллалар суд бинасына якынлашкач, халыкны атлы сакчылар куалар. Без халык арасына керәбез. Анда кызык-кызык сүзләр ишетелгәли. Кайсылары шатлыкларын изһар итәләр: "Муллалар үз киемнәрендә йөриләр икән", диләр. Ишмөхәммәд мулланы сорашалар.

— Ишмөхәммәд үтмәдеме, күрмәдегезме?

— Юк, күрмәдем.

Арада берсе:

— Ишмөхәммәд мулла үтсә, таныр идек, ул кешегә охшап тумагандыр, башкалар төсле булмас, — дип көлдереп тә куя.

Гомумән, халык мәҗлеснең ябык булуына бик уңайсызлана. Һәркемнең судка керәсе килә. Ләкин суд мәҗлесенә керергә аналарына һәм хатыннарына гына рөхсәт итәләр. Алар керми. Башка якыннары үтенсәләр дә, кертмиләр, чит кешеләр хакында сөйләп торырга да юк инде. Шулай да халык суд бинасы алдыннан китми. Хатын-кызлар да кичкә кадәр судның карарын көтеп торалар. Суд карар чыгарыр алдыннан урамнардагы халыкны куалар. Озак та үтми, урамнардагы халык ара-

сында: Габдулла мулла алты ай крепостьта утырырга, Гобәйдулласы ике айга хөкем ителгән, дигән хәбәр тарала.

Берничә вакытка кадәр үзләрен хәбестән чыгарып торачаклар икән, диләр. Шуны ишеткәч бәгъзе кешеләр "Бүген үк чыгармасłармы?" дип, муллалар артыннан төрмәгә китәләр. Ләкин муллалар үз ихтыярлары белән төрмәдә кунып, иртәгесен чыгарга калалар.

Судның карары буенча хәзергә кадәр ел ярымышар төрмәдә утырганнары өстенә Габдулла мулла тагын алты, Гобәйдулла мулла тагын ике ай крепостьта утырырга тугры киләчәк. Гадәттә судебный палатаның карары Сенатка җибәрелә. Аннан тасдыйк ителеп кайткач суд карары буенча хәбестә утыруның срогы хисаплана башлыйдыр. Муллаларны судның карары Сенаттан әйләнеп кайтканчыга кадәр чыгарып торырга ясаганнар. Судның карарына протест бирмәделәр. Мондый сурәтләрдә Сенат, судның карарын күбесенчә, һич туктаусыз тасдыйк итәдер. Димәк, суд тарафыннан муллалар тәгаен ителгән җәзаны Сенат арттырыр, яки киметер дип уйларга урын юк. Эш Сенаттан кайткач, мөттәһимнәрне тәкрар хәбескә ябарлар. Ләкин бу мәртәбәсендә аларны шул ук Сарапул төрмәсенә япсалар да, крепостька утыручыларны тотканча тотачаклар. Крепостьта утыруда төрмәдә утыруга караганда берничә җиңеллекләр буладыр. Төрмәгә хөкем ителгән кешеләргә арестант киеме кидерәләр, әмма крепостька хөкем ителгәннәр гади арестантлардан аерым торып, үз киемнәрендә йөриләр. Аннан соң крепостька хөкем ителгәннәр илә хәбесханә мәэмүрләре дә яхшы мөгамәлә итәләр.

Бубый әтрафында төрле мөгаллимнәрдә һәм муллаларда тентү булган вакыт кулга алынган китапларны жандарм мәэмүрләре зарарсыз табып, сахибләренә кайтарып бирергә ясаганнар.

И. Бикчурин. "Бәянелхак".- 1912.- 1, 3 июнь (№№ 1056,1057).

даир — кагылышлы
вакыйган — чыннан
мәхәлли әһали — җирле халык
дәкыйка — минут
тәэссеф — бик кызганыч
гарыз итү — җиткерү
изһар итү — белдерү
тасдыйк ителеп — расланып
сахиб — ия
истифадә итәрлек — файдаланырлык
моталәга итү — уку
кәфил була — ышандыра
касд — ният

# Бубыйлар эше хакында

## Сарапулга сәфәр

...Алабугага җиткәндә мәшһүр Ишми дә үзенең бер иптәше илә пароходка керде. Беренче класска җирләштеләр. Теләп вә тырышып карасам да, аның илә күрешә алмадым. Иптәше судта аның өчен тәрҗеман булачак имеш (?). Сарапулга җитәр алдыннан иртә берлә, иптәшен түбән гаммә классында очраттым. Кухня янына килеп, безгә чәй, су бирегез дия әмер итеп тора иде. 1 нче класстагы кешеләрнең, шулай кухнядан килеп чәй сорап йөрүенә мин, билгеле, бик гаҗәпсенгән булыр идем, әмма электрик звонокларының алар гыйндендә хәрам вә бидгать эш икәне хәтеремә төште дә, әйе шул бидгать пароходта утырып барсалар да, бидгать звонок илә истифадә итүне күңелләре күтәрмәгән булыр, дидем.

27 май Сарапулга төштек. Номерлар тулы, халык күп булырга охшый. Менә бу мәктүпне язганда Маклаковның да килеп җиткәнен ишеттем, күрешеп булмады, йокларга яткан диделәр. Шаһитләрнең барчасы да җыелып беткән диярлек, чөнки иртәгә 28 нче май, ягъни суд булачак. Казаннан газета мөхбирләре кичә килделәр. Судның ачык яки ябык булачагы хәзергә мәгълүм түгел. Хәзрәтләрнең сәламәтлек вә кәефләре яхшы диләр. Көндез төрмә бакчасына чыгып агач, чәчкәләр арасында байтак кына вакыт уздырырга вә шунда эшләүче мәхбүсләргә нәзарәт итеп торырга, ягъни бакча эшләрен күргәзеп, өйрәтеп торырга мөсагадә бирелә икән. Киемнәре вә ашамлык нәрсәләр үзләреннән, төрмәнең көтепханәсе яхшы вә бай булганга, хәзрәтләр кебек моталәгә сөюче кешеләр өчен, аны да бер юанычтан хисапларга ярый. Судны күрергә килүчеләр пароходтан вә корыдан агылып тора диярлек. Кичә окружной судка кереп чыктым. Судның залы кечкенә күренде. Судның составын бик яманламыйлар. Алар шәхсияткә бирелмичә, мотлакан гадәләтне күзләүләре өмет ителә. Хәзрәтләр файдасына сөйләүчеләр арасында бер кәшиш тә бар. Экспертлык итәр өчен Казаннан Катановның хәзер Сарапулга килеп җиткәненнән хәбәр алдым.

Шаһитләрнең күбесе тәрҗеман аркылы сөйләшерләр кебек сизелә. Питердан килгән Маклаков. Казаннан Бать һәм Сарапулда дәгъва вәкиле Егоров хәзрәтләрне акларга тырышачаклар. Шаһитләр мәҗмугы 44ләп бар. Бинаән галәйһи судны бер көндә генә бетмәс диләр.

Хәзер Аллага тапшырып, иртәге сәгать 9 ны көтәбез.

## Суд көне

28 нче май. Суд бинасына барудан әүвәл, хәзрәтләрне ничек алып киләчәкләрен белер өчен төрмәгә таба йөрдем. Көн иртә сәгать 7 иде. Төрмә урамында төрлесе төрле җирдә җыелып утырган, байтак кына халык күзгә чагылып кала. Колакка ишетелгән сүзләреннән аларның да хәзрәтләрне алып чыкканны карар өчен, ягъни хәзрәтләрне күрер өчен килгәнлекләре аңлашыла иде. Сәгать 9 ларда 44 солдат, хәзрәтләрне төрмәдән алып чыктылар. Электән үк извозчиклар хәзерләнгән булса да, җәяү алып киттеләр. Хәзрәтләрнең тышкы күренешләре яхшы, үзләрен гүя бер нәрсә дә булмаган кебек тоталар, ягъни чырайларында борчылу галәмәтләре юк иде.

Сәгать 9 ярымда суд башланачак иде. Шунда кадәр судның ачык яки ябык булачагы мәгълүм түгел иде. Карарга керер өчен җыелган халык урамда тулган. Һәркаюсы керергә форсат көтәләр иде. Повестка килгән шаһитләр генә керсеннәр дип әмер иттеләр. Шаһитләр керде, шуннан соң судның ябык булачагы да бәян ителде. Халык тилмереп калды.

Суд кичке сәгать 12ләрдә тәмам булыр дигән хәбәр, судның янына җыелган гаскәр кебек халыкка мәгълүм булды. Сәгать 11ләр җитте. Халык суд каршысында булган площадь вә урамга тәмам тулган. Узып йөрүчеләргә дә урын юк, ягъни тротуарлар да тыгыз иде. Сәгать 11ләрдә атлы вә атсыз полиция заһир булып, халыкны куа башладылар. "Таралыгыз, фатирыгызга кайтыгыз" диеп куалар иде. Эчтән бөтенләй хәбәрсез халык, эчнең тышка тәэсире бардыр диептер инде, кайгыга калдылар. Арада "мескен мәхдүмнәрне каты хөкем итәләр икән" дигән сүзләр дә ишетелгәләде.

Сәгать 12 җитте. Суд тирәсендә халык калмаган, һәммәсен таратканнар иде. Алай да беркадәр читтә, төрлесе-төрле җирдә җыелып, нәтиҗәне көтәләр иде. Монда шуны да әйтеп китәргә кирәк: карарга җыелган халык арасында эшләпәле, җиләнлеләр булган кебек, белмим ни өчендер, бөтенләй суд белән танышлары булмаган хәерче сыйфатындагы берникадәр түбән эшче халык та бар иде. Соңыннан ишетелүенә караганда, Ишминең якыннарыннан бер бай, Бубый хәзрәтләрнең зарарына хөкем итсәләр, илле яки йөз сумнар чамасында садәка таратырга вәгъдә иткән, имеш. Газета мөхбирләре вә шулар арасында мин дә, судның ишек төбендә көтеп тордык.

Габдулла мәхдүмгә 6 ай, Гобәйдулла мәхдүмгә 2 ай утыруга хөкем ителгәннәре мәгълүм булды. Приговор тасдыйк кылынганчы 2 ай мөддәт илә хәзрәтләр иреккә чыгачаклар.

Бик каты хөкем итмәсәләр ярар иде дип куркуда көтеп торучы халыкка бу хәбәр бер җиңеллек бирде. Халык куанды вә хәзрәтләрнең төрмәдән чыгачакларына шатлык илә сөйләшә-сөйләшә таралдылар.

Судка газета мөхбирләрен дә кертмәделәр. Шаһитләрне сорап бетергәннән соң экспертларны чыгардылар. Судның ни өчен ябык булганы безгә мәгълүм булмады.

29 нчы май. Думавый. "Вакыт".- 1912.- 3 июнь (№ 981).

дия — дип
гыйндендә — аларча
күргәзеп — күрсәтеп
мөсагадә — рөхсәт
мотлакан — һичшиксез
мәҗмугы — барысы
бинаән галәйһи — шуңа күрә
заһир булу — килеп чыгу
мөддәт — вакыт

## Из отношения
## педагогического совета Троицкой женской гимназии директору народных училищ

декабрь 1912 г.

Родители учениц Троицкой женской гимназии - мусульманок докладной запиской на имя госпожи начальницы гимназии ходатайствуют о введении в число учебных предметов преподавания сим ученицам мусульманского вероучения с установкой 3-х часов занятий в неделю и со своей стороны рекомендуют на должность вероучительницы госпожу Бобинскую - преподавательницу существующей в г.Троицке начальной женской школы "мектебе" Ахмарова...

## Из ответа
## директора народных училищ председателю
## Троицкой женской гимназии

8 января 1913 г.

... к назначению вероучительницей г-жи Бубинской в Троицкую женскую гимназию с моей стороны препятствий не встречается.

Государственный архив Оренбургской области.
Ф.73. Оп.1. Д.219. Л.8,9.

## Выдающийся центр мусульманского просвещения

Особенно благоприятное положение для развития и надлежащей постановки учебного дела занимало Иж-Бобинская медреса, основанная или преобразованная в новометодную двумя братьями Габдуллой и Губайдуллой Боби (Нигаматуллинами). Эти два брата, сыновья деревенского муллы. Один из них учился в Константинополе, где изучал высшие богословские науки и получил светское образование. По возвращении на родину, он вместе с братом основал медресу. На помощь им пришел богатый татарин Мухамеджан Ахмеджанов, жертвовавший ежегодно на содержание медресы до десяти тысяч рублей в качестве положенной магометанским законом милостыни — закат. Сверх этого медреса пользовалась субсидией сарапульского земства в размере семисот рублей. В медресе основательно изучались богословские предметы и восточные языки: арабский, турецкий, турецкая литература. Но, что очень важно и что редко бывает в медресах даже новометоднаго направления здесь — сравнительно основательно и широко изучались и светские науки общеобразовательного характера: математика, физика, химия, всеобщая история — главным образом история мусульманских народов и французский язык. Преподавание велось всецело на татарском и турецком языках. И хотя при медресе существовали классы русского языка, в самой медресе русский язык не преподавался, поэтому и мугаллимы с русским языком были знакомы очень мало. Иж-Бобинская медреса пользовалась широкою известностью среди магометанского населения. Сюда приезжали учиться магометане из разных губерний, навещали Иж-Боби любители магометанского просвеще-

ния из среднеазиатских владений и из Турции. Вообще эта медресе была выдающимся центром мусульманского просвещения. Здесь, по мысли представителей новометодного направления, должны были получать образование мугаллимы, вполне достойные и пригодные для занятия должностей учителей, могущие поставить образование в национальном духе. До той высоты, на которую поднялась Иж-Бобинская медресе в период своего расцвета, не доходила ни одна медреса приволжского края.

Коблов Я.Д. Конфессиональные школы казанских татар // Инородческое обозрение. Приложение к журналу «Православный собеседник» за декабрь 1915 г. Т. II, № 1 - Казань: Центральная типография, 1916.-С. 94-95.

## Габдулла Бубый

Соңгы көннәрдә татар ярлыларының сәгадәте өчен татар һәм урысларның кара көчләре — кадимчеләр, миссионерлар, монархистлар вә идарәи мөстәбидәнең палачлары, бөтен полиция, җандармнар һәм болар кулында зур корал булган татарның үз наданлыгы белән күп еллар көрәшеп килгән кешеләребездән Габдулла Бубый 7 нче февральдә 51 яшендә вафат булды.

Габдулла хәзрәт Бубый үзенең тудырган Бубый мәдрәсәсе белән татар мәдәният һәм инкыйлабы тарихында зур урын алачак, чөнки ул мәктәп хәзерге көндә инкыйлаб мәйданында армый-талмый көрәшеп килүче бик күп татар сәяси эшчеләренә вакытында рух биреп чыгарды. Инкыйлаб булу белән бу рух изелгән татар ярлыларының ярдәменә ашыкты, Бубый шәкертләрен көрәш мәйданының беренче сафына ыргытты.

Хәзерге көнне татар арасында эшләүче мәсьүл татар эшчеләренең күп өлеше Бубыйда тәрбия алган, Бубыйда рухланган егетләр дисәм, хата әйтмәгән булачакмын.

Урал буенда, Вятка, Пермь әтрафында кадимлек белән көрәшнең авырлыгы Габдулла Бубый белән Хәялетдин Хәсәнкәев хәзрәтләр башына төшә. Заманасында үзенең яңалыгы, тәрбия ысулларының куелышы ягыннан алгы сафта торган мәктәбе белән ул үз янына эчке Русия, Төркестан, Кыргызстан өлкәләренең һәр почмагыннан укырга, мәдәниятә, яңалыкка сусаган күп кешеләрне җыйган иде. Мәгънәсез тормышларын ташлап килгән, гыйлемгә сусаган егетләргә Габдулла Бубыйлар, Бубый мәктәбе вакытына күрә тулы аң-фикер биреп чыгарырга тырыша, шул максат белән фән, телләр укыла, хөр тәрбия бирергә, белем һәм иҗтимагый

тормышы белән укучыларның үзләрен зәвыкландырырга тырышыла иде.

Бубый мәктәбе үзенең атна саен ясалган җыелышлары, бу җыелышларда вакытына күрә сәяси нотыклары (кара истибдадка каршы) белән шәкертләрнең фикерен ачуда күп хезмәт итте.

Ләкин мәлгунь идарәи мөстәбидә бу яктылык утын күтәреп чыгучы затка, күп көчләр сарыф ителеп оештырган мәктәбен дәвам иттерергә ирек куймады. Татарларның үзләре эченнән Ишми мулла, Фаиз Даутов, Шаһимәрдан Апакаев кебек бик күп безгә фамилияләре беленми калган провокаторларны эшләтеп, 1912 елда Бубый мәктәбен япты. Габдулла Бубый вә аның ярдәмчеләрен һәм күп укытучыларны төрмәгә утыртты. Габдулла Бубый судка кадәр берничә айлар ятып, нәтиҗәсендә крепостька хөкем ителде.

Җае килгәндә без татар гаммәсенең башыннан кичергән бу тарихи вакыйгаларга, әлбәттә, ныклап тукталуга, сүз ахырында татар ярлысына хөләса итеп әйтергә тиешбез.

Габдулла Бубый сезнең якты киләчәгегез өчен зур бер мәктәп тәрбия иткән, җәдид юлында бик күп көрәшкән бөек дини реформатор иде. Царизм һәм аның сине чукындырырга йөрүче миссионерлары белән көрәшкә бөтен көчен, белемен, каләм куәтен сарыф итүче бер зат иде дибез. Үзенең авыруына карамастан, үләсе минутларына кадәр көн-төн язды һәм авылдагы крестьяннарга киңәшләр биреп, сәяси әхвальләр белән аларны таныштыра торды. Менә, рухани булса да, без, коммунистлар өчен аның кыйммәте дә шунда.

Габдулла Бубыйның хезмәтләре газета сәхифәләрендә генә язып бетерерлек түгел.

Габдулла Бубый артык тырышучан, яхшы администратор һәм киң фикерле бер җәмәгать хадиме иде.

Габдулла Бубыйның кулъязмалары күп булырга кирәк. Ләкин мәрхүмнең үзенә генә хас булган бер йомшак ягы бар иде. Ул язган нәрсәләрен ни өчендер матбугатка чыгарырга җөрьәт итми иде, Габдулла хәзрәт үзе үлсә дә, аның исеме һәрвакыт татар эшче һәм крестьяны тарафыннан мәдәният, ирек юлында көрәшчеләр рәтендә саф бер матурлык белән яд ителәчәк һәм аның шәкертләре иҗтимагый инкыйлабның ышанычлы көрәшчеләре булып калачаклар.

Гасыйм Мансуров. "Татарстан хәбәрләре". - 1922. - 15 февраль (№38).

сәгадәт — бәхет
мөстәбидә — тирания
мәсьүл — җаваплы
хөләса итеп — нәтиҗә ясап

## Габдулла Бубый

25) «Кәнәскә сәяхәт»— Голҗа тирәсендәге Кәнәс дигән казакъ җиренә сәяхәт язмалары. (99а-110б кгз).- Казакъ халкының тормыш-көнкүреше, гадәт-йолалары хакында күп кенә фактлар китерелгән, кашгарлыкларга карата да фикерләр әйтелгән. Әдип пассив күзәтүче генә булып калмаган, кайбер мәсьәләләрдә боларның тормышына тәэсир итәргә, үз мөнәсәбәтен белдерергә тырышкан. Мәсәлән, ул казакларда вафат булган кешене зур матди чыгымнар белән җирләү йолаларын (аш-су үткәрү, ат чаптыру) күзәткәннән соң, шул рәвешчә белдергән: «Мин аларга шул исрафларның тиешсезлеген, ул акчаларны милләт юлына, мәктәпләр файдасына сарыф кыйлуның лязымын бик озак итеп сөйләдем. Сүзем әсәрсез калмаган. Соңра ишелде: болар ат чаптырудан ваз кичеп мәктәпләргә иганә кыйлырга карар биргәннәр» (100а кгз).

26) «Мөхтәрәм Сөембикә әбкәм» — Яркәнд шәһәһәрендә кызлар мәктәбе оештырган Фатыйма исемле мөгаллимәнең вафат булуы мөнәсәбәте белән язылган әдәби парча (113-кгз).

27) «Мөхтәрәм хуҗамыз Исмәгыйль бәй рухына»— Исмәгыйль Гаспринскийның үлүенә багышланган әдәби парча. «Исмәгыйль бәйнең вафаты мөнәсәбәте белән Голҗада кызлар мәктәбендә сөйләнгән нотык» (114а-119б кгз). Бу парча мәктәптә укыту ысулларының тарихы буенча фактик материалларны эченә ала.

Әсәр басылган: Г. Бубый. Мөхтәрәм хуҗамыз Исмәгыйль бәй рухына // «Сөембикә», 1914, ноябрь, № 2. 5—7 бит.

28) «Кашгар кадинлары»— Кашгар хатын-кызларының уен мәҗлесләре хакында язма (120а-124б кгз).

29) «Гомум Төркестан Чини вә Магулстан Чини әһле мөслимәсе тарафыннан Хилафәте исламия мәркәзе Истанбулда булган мәҗлесе мәбгусәндә укылмак өчен бер гариза»— Кытай Төркестанындагы халыкларның мәгариф хәле турында (127а-130б кгз). Азагына: «Бу гаризага Шәех-Сәгыйть Гасәли меңнәрчә адәмнәрне имза кыйлдырмакчы булды. Бу адәм бик инабәтле кеше булмаса да, аны хезмәт иттерүдә мин бер зарар да күрмәдем»,—дип куелган.

30) «Шәех Сәгыйть Гасәли кем ул?»— Шами дамелланың яман эшләрен фаш итә торган хатирә язмасы (131а-132б кгз).

31) «Хөрмәтле әфәндем хәзрәтләре»—Шами дамелланың ялган фәтва биреп йөрүенә карата Хәйдәр исемле кеше тарафыннан язылган. Г. Бубый тарафыннан төзәтелеп, өстәлеп «Вакыт» газетасы редакциясенә җибәрелгән. Азагына болай дип куелган: «Максатым шушы фәтва түгел, бәлки Шами мәсьәләсе белән (мәктәпләрне төзәтүгә) иганә хосусындадыр» (131а-132б кгз).

32) «Яңа мөгаллимә»—Голҗа тормышыннан бер әдәби парча (134а-136б кгз).

33) «Шкул, мәктәп»—ике малайның диалогы рәвешендә язылган әдәби парча (137а-138б кгз).

34) «Мазар»—таранчы-кытай сугышына бәйләнешле материаллар җыю максаты белән таранчы мазарына бару һәм карау турында хатирә язмасы (141а-150б кгз). 1914, 31 май.

35) «Бу нәкадәр ялкаулык»—таранчы һәм кашгарлыкларның экономик артталыклары һәм аның сәбәпләре хакында публицистик язма (151а-152б кгз).

36) «Эш юклыктан»—хатын-кызларга бәйләнешле әдәби парча (155а-166б кгз).

37) «Яушевлар кем» — Голҗа байларыннан Яушевларның мәктәп-мәдрәсәләргә ярдәме хакында хатирә (169а-174б кгз).

Шундый ук типтагы икенче байны мактауга багышланган язма—«Бубый Мөхәммәджан хажи» (174а-175а кгз).

38) «Бу мелламыни» — интеллигент кыз, егет һәм мулла арасындагы сөйләшүләр турында диалог формасындагы әдәби парча (175а-180б кгз).

39) «Голжа хәбәрләре» (183а-185а кгз). Тыштан үзен милләткә хезмәт итүче итеп күрсәтеп тә, эчтән шул ук милләткә каршы донос ясап йөрүче Фазылҗан аксакалның эшләре фаш ителә. Азагында болай язылган: «Моны Хөсәен-Хажи Мусабаев бер кеше исеменнән «Ил» газетасына җибәрде».

40) «Голҗада кадинлар өчен ижтиһад»— хатирә язмасы, хатын-кызлар файдасына иганә җыю хакында (185б-186а кгз).

41) «Голҗада донос». Г. Бубый өстеннән булган донос хәлен тасвир иткән хатирә язмасы (186б-196б кгз). 1914, 13 май.

42) «Потханә» — кытайларның Будда храмын-потханә карарга баруын, тәэсирләрен тасвир итә торган хатирә язмасы (197а-200б кгз).

43) «Бер картның фикере» — хорафатчан бер карт һәм аның эшләреннән көлеп язылган бер әдәби парча (201а - 203б кгз). 1914, 13 июнь.

44) «Троицкида Яушевларның кызлар мәктәбе рәсме кәшадында Мөхлисә Бубый тарафыннан сөйләнгән нотык» (206б-208б кгз). 1914, 7 август.

45) «Камил хөр бер кадин» — үз иркенчә тормыш итә торган, хөр фикерле Европалы хатынның бер мөселман белән әңгәмәсен тасвир итә торган әдәби парча (206б-208б кгз).

46) «Голҗада мөселманча-русча шкул рәсме кәшады» — Голҗада өч сыйныфлы мөселманча-русча шкул ибтидаи мәктәпне рәсми ачу хакында хатирә язмасы (211а-217б кгз). 1913, 12 декабрь.

47) «Мәзлума ана»—ана һәм кыз язмышы хакында нәсерсыман әдәби парча (218а-222б кгз). 1913, 11 декабрь.

48) «Троицкида Яушевлар тарафыннан хөкүмәт рөхсәте белән ачылган дарелмөгаллиматны рәсме кәшадда сөйләнгән нотык» (225а-228б кгз). Азагына: «Голҗада ул мәктәпнең мөдирәсе Һәмширәмә яздым»,—дип куелган. 1915, 2 июль.

49) «Яркәнд мелласы Шәмсетдин Корбангали рәфикасы Мәгърифә Вафа кызының Яркәндкә төшкәч тә, кызлар мәктәбен ачканда сөйләгән нотыгы» (229а-231б кгз). 1915, 17 август.

50) «Дүнгәннәр ахун сайладылар»—хатирә язмасы (232а-233б кгз). 1915, *27* июль.

51) Голҗа тормышында булган хәлләрдән әдәбиләштерелеп язылган мәзәксыман парчалар: «Ике мөгаллим», «Китаби мөселман», «Булган вакыйга» (234-кгз).

52) «Голҗада консул вә әдәбият кичәсе»— хатирә язмасы (237а-238а кгз). 1915, 27 ноябрь.

53) «Даргман белән ит яргычы» — бер кеше белән булган хәлнең язмасы (238б - 239б кгз). 1915, 6 декабрь.

54) «Мәүлуд бәйрәмендә кадинлар мәҗлесендә кызлар тарафыннан әфәндемез салалаhе галәйһиссәламның тарихы сөйләнгәннән соң укылган нотыкның копиясе» (240а-241б кгз). 1915, 12 декабрь.

55) «Икенче Сәлахетдин Әйүби» — 1914 елгы бөтендөнья сугышы, империалистик дәүләтләр һәм шәрык илләре арасындагы мөнәсәбәт хакында публицистик парча (242а-243а кгз). 1915, 27 декабрь.

56) «Консул белән яки Ел башы ничек» — 1916 елны каршылау хакында мемуар язма (243б-244б кгз). 1916, 2 гыйнвар.

57) «Әле дә бар микән»—хатын-кызлар азатлыгы хакында публицистик парча (245-кгз). 1916, 1 февраль.

58) «Сугышмы, сәгадәтме»—җәбер-золым астындагы халыкның өметләре хакында нәсерсыман бер парча (246-кгз).

59) «Җир тетрәү»—яшь буынның яңача яшәргә омтылуы һәм аңа каршы хәрәкәтләр хакында әдәби-публицистик парча (247а-248б кгз).

60) «Мөхтәрәм әфәнде хәзрәтләре»—Г. Бубыйның «Шура» журналы исеменә җибәргән хаты (251а-252а кгз). 1914, 3 март. Г.Бубыйның «Тәүхид» исемле тәрҗемә китабына карата журналның 1914 елгы 3 санында басылган тәнкыйть мәсьәләсе турында.

61) «Исәнме син, сөекле Сәгыйдәкәем». Хат рәвешендә язылган, нәсерсыман бер әдәби парча (252б-259б кгз). «Мин сиңа бу хатымда бер сарт кадинның — кардәшемезнең мәэюс калебеннән чыккан аһ авазларын аның үз авызыннан язмакчы булам», — дип әйтеп киткән. 1914, 26 март.

62) «Хөрмәтле ханым һәм туташлар... Голҗада кызлар имтиханында 17 майда Хөснефатыйма Бубый тарафыннан сөйләнгән нотыкның күчермәсе» (260а - 262б кгз). 1914, 17 май.

63) «Хөрмәтле ханымнар һәм туташлар... Йосыф белән Фатыйма туенда Хөснефатыйма Бубый тарафыннан сөйләнгән нотык» (265-кгз). 1914, 19 апрель.

Голҗада 8 сыйныфлы кызлар мәктәбе салуга керешелү уңае белән мәктәпне салышу—ярдәм итү кирәклеге хакында. Сүзен шушы рәвешчә тәмамлый:

«Әйдәгез, хөрмәтле ханымнар һәм туташлар, шушы сәгадәт юлында аякларыгызны озынрак, зуррак атлагыз. Нечкә хәссас калебләреңездән купкан иганә вә садакаләрегезне туктатмагыз, бирегез, ыргытыгыз! Җыелсын бу иганәләр, зур бер диңгез булсын! Ул зур диңгез безнең өстебездәге гөнаһларның, наданлык керләренең һәммәсен юып китсен, тазартсын!..»

64) 1914 елның 12 маенда кызлар имтиханында укылган дога (266-кгз).

65) «Голҗада сабан туе»—хатирә язмасы (267а-275б кгз).

66) Г. Бубыйның «Ил» газетасы редакциясенә җибәргән хатының күчермәсе (276-кгз). 1914, 26 апрель.

Хатта Г. Бубыйның Голҗадагы мәгариф эшчәнлегенә карата «Ил» газетасында басылган мәкаләләрнең асылы тикшерелә, яңалыкны күрә алмый торган кешеләр тарафыннан язылуы фаш ителә.

**III** том — Г.Бубыйның 1911—1912 елларда Сарапул төрмәсендә утырганда күргәннәрен тасвирлый торган хатирә язмалары һәм төрле әдәби парчалар җыентыгы. Җыентыктагы һәр материалның кайда һәм кайчан язылуы күрсәтелгән.

Эчендә: 1) «Бубыйлар галиһендә шаһитләр»—Габдулла һәм Гобәйдулла Бубыйлар өстеннән кузгатылган суд эше буенча мәгълүмат биргән 42 шаһитнең округ судына биргән мәгълүматларының язмасы (2а-49б кгз). Г. Бубый тарафыннан судның «Эш кәгазьләре»ннән—русчадан тәрҗемә итеп күчерелгән. 1912, 21 март.

Беренче шаһит − искелек тарафдары Әхмәт Мифтах улы Тимкин шундый мәгълүмат биргән: «Яңа укыту безгә ошамый, чөнки алар голуме диниягә аз вакыт куялар һәм мәктәпләрендә рус лисаны да укыталар. Хосусан, Бубый мәдрәсәсендә тәкмил кыйлган шәкертләр Аурупа фурмысында киенәләр. Без, картлар, менә шуннан куркабыз: бу яңа күренеш, бу яңача тәрбия алган татарлар яңа фурмыда хөкүмәт эсти күрмәсеннәр». Калган 41 шаһитнең сүзләре дә шундый ук рухта. Шаһитләрнең күрсәтүләреннән кадимчелекнең бөтен асылы, үсенте җибәргән яңалыкны бууга хөкүмәт тарафыннан булышлык көтүе ачык аңлана. Бубыйлар өстеннән кузгатылган процессны аңлау өчен бу материал зур тарихи кыйммәткә ия.

2) «Милләтенә хыянәт итүчеләр» — доносчының рухи дөньясын тасвир итә торган әдәби әсәр (50а-60б кгз).

3) Г. Бубыйның Сарапул төрмәсеннән кызы Галиягә язган хаты. (61а-65б кгз). 1912, 26 март.

4) «Җәдитләргә казылган чокыр» — Г. Бубыйларга суд эше кузгалуга төп сәбәпче, доносчы Ишми ишан тормышыннан

алынып язылган әдәби хикәя (66а-100а кгз). Сарапул төрмәсе, 1912, 4 апрель.

5) Г. Бубыйның Сарапул төрмәсеннән кызы Галиягә язган хаты. (100б-103б кгз). 1912, 8 март.

6) «Бубыйларны иттиһамнамә»—Бубыйлар эше буенча прокурор тарафыннан төзелгән гаепләү актының татарчага тәрҗемәсе (104а-111б кгз). Сарапул төрмәсе, 1912, 8 апрель.

7) «Бөркет. Русча, Салтыковтан» — М.Е. Салтыков-Щедриннан Г.Бубый тарафыннан тәрҗемә итеп күчерелгән бер хикәя (112а-121а кгз).

8) «Бахмутинның рәсемен алу»—Сарапул төрмәсе хәлләреннән бер хикәя (121б-123а кгз). Сарапул төрмәсе, 1912, 8 апрель.

9) «Тәҗрибәле никах». — «Коры мәхәббәт». — «Ирләр фәхешханәсе» — Сарапул төрмәсендәге фахишлек хәлләрен фаш итә торган өч хикәя (123а-126а кгз). 1912, 8 апрель.

10) «Төрмәдә экипаж»—төрмә хәлләреннән бер хикәя (126а-127б кгз).

11) «Мужик дус. Салтыковтан»—тәрҗемә хикәя (128а-135б кгз). Сарапул төрмәсе, 1912, 15 апрель.

12) «Абразаунай бай баласы»—«укымышлы» егетнең буш тормышын тасвирлый торган хикәя—русчадан тәрҗемә. (136а-143б кгз). Сарапул төрмәсе, 1912, 18 апрель,

13) «Судта»—хаким (судья) белән бер саңгырау карт арасындагы сөйләшүне тасвир итә торган көлкеле хикәя (144б-145б кгз).

14) «1913 елда 20 апрельдә Троицкида кызлар имтиханында сөйләнгән нотыкның сурәте» (146а-147б кгз).

15) «Кәҗә тәкәсе» — көлке хикәя (148а- 153б кгз). 1913, 10 апрель.

16) «Сәвекле, бердәнбер шагыйребез Тукай» — Г. Тукайның вафат булуына багышланган бер әдәби парча (154а кгз). Троицк, 1914.

17) «Күргән, ишеткән» — ишанлык һәм хорафатчылыкны фаш итә торган хикәя (155а- 161б кгз). Троицк, 1913, 13 апрель.

18) «Фаиз әфәнде белән» — Г. Бубыйларга карата суд процессында ялган күрсәтмәләр биргән Фаиз Гафиятуллин белән Г. Бубыйның әңгәмәсе тасвир итә торган хатирә язмасы (162а-165б кгз). Троицк, 1913, 20 апрель.

19) «Хөр кияү белән» — Г. Бубыйның Вәлид исемле кеше белән хатын-кыз мәсьәләсе буенча әңгәмәсен тасвир итә торган хатирә язмасы (166а-175б кгз).

Көтепханә пагинациясе буенча 143-144 кәгазьләр арасында килә торган берничә бит — Г. Чыгытай һәм аның «Исабәт» китабы турында бер мәкалә язылган кәгазьләр китапханәгә кергәнче үк берәү тарафыннан кисеп алынган, мәкаләнең 144а кагазьгә язылган ахыры гына калып, ул да карандаш белән сызгаланган. Г. Бубыйның бу өч томлык сайланма әсәрләре китапханәгә Гыйльми Үзәк материаллары белән кергән.

## II. Ислам фәлсәфәсенә бәйләнешле әсәрләр

### 524 т. (э. №3184) Җыентык. Россия, 1902. Габдуллаҗан бине Мансур әл-Болгари; Йосыф бине Хөснетдин. Тәгъликъ. 34 кгз. 13x21.

Эчендә: 1) «Тәүхид яхуд Мөдәфәгаи исламия» — ислам догматикасына һәм исламның хатын-кызга мөнәсәбәтенә караган әсәр (2-10 кгз).

Әсәрнең бүлекләре: — Аллаһының варлыгыны исбат. Тәгаддөде зәүҗат. — Мөхәммәд галәйһиссәламның нөбүвәтене исбат. — Христианнарда шәнкернең күплегенә сәбәп. — Тәгаддөде зәүҗате мөслимин. Фәхешханә ачуларның сәбәбе.

Әсәр басылган: Бубый Габдулла. Тәгаддөде зәүҗәте хифзы сихәтә тәтбыйк. Оренбург, 1901. 20 бит.

2) Бер поп, миссионер кызы һәм татар укымышлысының ислам дине, аның әдәп-әхлакка, хатын-кызга карашы хакындагы полемиканы тасвир итә торган хикәя (10-22кгз).

Азагына әсәрнең һәм иҗат ителү урыны шушы рәвешчә күрсәтелгән: «Әсәре Габдулла мәхдүм Нигъмәтуллин. Сарапул өязе, Бубый карьясендә». Аннан соң күчерүчесе һәм күчерелү вакыты күрсәтелгән: Йосыф бине Хөснетдин. 1320, мөхәррәмнең 27 се (1902, 22 апрель). Җыентыкның калган кисәкләрендә башка авторларның әсәрләре күчерелгән.

3) Яңа елны тәбрикләү шигыре (22-23 кгз). Башына: «1320 нче сәнәнең ел башының бәйрәмендә укылмак өчен дамелла Галимҗан Баруди хәзрәтләренең тәртибе кәрдсидер» («Нәүруз мөбарәк бад») бәетләре үлчәмендә һәм стилендә язылуы белән кызыклы. Шигырь:

«Мөхәррәм ае тугъды,<br>Иске елымыз тулды,<br>Яңа ел башы булды,<br>Аллаһ кыйлсын мөбарәк.

Мөселманнар шатланды,<br>Мәдрәсәләр нурланды,<br>Шәкертләр һәм хушланды<br>Аллаһ кыйлсын мөбарәк»,-

дигән строфалар белән башланып китә.

4) «Мәгълүмат. Дин хакында» (24-34 кгз). Татар мәктәп һәм мәдрәсәләре, аларга хөкүмәтнең мөнәсәбәте хакындагы бу мәкалә русчадан Фатыйх Кәрими тарафыннан тәрҗемә ителгән.

Мәкаләнең эчтәлеге: Татар мәктәп-мәдрәсәләре һәм аларның кыскача тарихы. Уку-укыту тәртибе, укытыла торган фәннәр. Татар мәдрәсәләрен Мәгариф министрлыгына кертү, алар янында рус класслары ачу, күзәтчелек итү турында Дәүләт Советының 1874 ел 26 ноябрь карары. Татар җәмәгатьчелегенең ризасызлыгы. Татар мәктәп-мәдрәсәләренең хәлен яхшырту мәсьәләләре.

Автор татар җәмәгатьчелегенең ризасызлык чыгышларының сәбәбен мәктәп-мәдрәсәләрнең халык хисабында тотылуында, хөкүмәт тарафыннан материаль тәэмин итү булмауда күрә. Мәкаләнең азагында татар мәктәпләрен яңарту, яхшыртуга кагылышлы фикерләр әйтә, тәкъдимнәр кертә.

Мәкаләнең авторы татар булырга кирәк, чөнки ул үзе мәкаләнең азагында мәкаләдәге фикер һәм тәкъдимнәрнең үзенең күпъеллык имам һәм мөдәррислек итеп алынган тәҗрибәсеннән чыгуы хакында искәртеп китә.

Җыентык Сәед Вахиди көтепханәсе белән кергән. № 483.

1912 елда Казан өязе (хәзерге Тукай районы) Ашыт авылында табылган.

## 1574 т. (э. № 5540) Җыентык. Россия, 1905. Закирҗан Алхани. 126 кгз. 13,5×21.

Эчендә: 1) «Могҗизате Мөхәммәдия»йә тагыннан җавап». «Мөхәммәд галәйһиссәламның нөбүвәтене исбат». – «Вахданийәте бари тәгаләне исбат». – «Иҗабның әһле исламә улан ун бәхәсләренә җавап» – ислам мәсьәләләренә багышланган кечкенә дүрт рисалә (1б-5б кгз). Бу рисаләләр Буа шәһәрендә торучы Нургали ибне Хәсән әл-Болгари тарафыннан тикшерелгәннәр, тәнкыйтьләнгәннәр. Монда (5б-6б кгз) бу тәнкыйть язмасы да күчерелгән.

2) «Хыйфзы сыйххәт. Издиваж» — ислам шәригатенең хатын-кызга карашы, ирләр белән мөнәсәбәт мәсьәләләре тикшерелә торган әсәр (7а-16а кгз).

Бүлекләре: «Исламият буенча кадын алу». – «Бәян-эләкъриба. Издиваж». – «Кадинларда ноксан». – «Җәндә уйнашчы илә улан тәэсир».

Әсәрдә хатын-кызның табигатенә, холкына, хокукларына карата фикерләр әйтелгән. Әдипнең теле җанлы, образлы. Еш кына «Яшь кадинларның күңелләреннән яшь егетләрнең

күңелләренә делсез телеграф вардыр», «Ата вә ана нәзараты улсын, — кызларның гыйшык бауына тота алмас» (15б кгз) шикелле гыйбарәләр очрап китә. Әсәр басылган: Бубый Габдулла. Тәгаддөде зәүҗәте хыйфзы сыйххәтә тәтбыйк. Оренбург, 1901. 20 бит.

3) «Рәддия галә рәддия» - Г. Бубыйның «Хакаикы исламия» исемле китабында куелган кайбер мәсьәләләргә карата Байгужа авылы кешесе Мөхәммәдзыя Ильясов тарафыннан язылган рәддиягә (кире кага, юкка чыгара торган тәнкыйтькә), каршы тәнкыйть (16а-22б кгз).

Г. Бубый, дөньяның яратылышы, материя һәм аң арасындагы мөнәсәбәт мәсьәләләрен тикшергәндә, башка философларның, мәсәлән, юнан философы Арасту - Аристотельнең карашларына да туктала (19а кгз).

Әсәрдә М. Ильясов рәддиясеннән күп кенә өзекләр китереләп, аның фикеренең нигезсезлеге исбат ителгән.

Г. Бубый тәнкыйтен шундый сүзләр белән тәмамлый: «Безем кычкырышып, өстәл сугып моназара заманнарымыз узып барадыр. Фарабилар, Ибн-Синалар белән мөхарәбәләрне куегыз — анлар каберләрендә рәхәт-рәхәт ятсыннар. Заманнарында исламнар аркасында тәрәккые голумә күп хезмәт итмешләр. Бу заманда да татардан анлар кеби адәмләребез булса, бик гүзәл булыр иде, ләкин юк. Сезнең кеби сафсата ияләре күп. Сезнең бу рәддиягездә язмыш сүзләрегез вә бәхәсләрегез безем дилемезә дәгел, үзегезнең фәһемегезә, аңлауыгыза киләдер».

3) «В. Доронкин хатына рәддия» — православие миссионеры, Касыйм шәһәрендәге миссионерлык җәмгыяте рәисе Василий Доронкинның Касыйм татарларын христианлыкка чыгарга пропагандалау максаты белән бастырып таратылган хатына (1901, 12 июль) тәнкыйть (23а-37б кгз).

Г. Бубыйның әсәрендә В. Доронкин хаты җентекләп тикшерелә һәм аның фикерләре юкка чыгарыла. Тәрҗемә итеп күп кенә өземтәләр китерелгән.

Автор В. Доронкинның һәм тарафдарларының бу чыгышын «чабалану» дип бәяли. «Истикъбалыгыз нуре мәгариф алдында тетрәмәктә вә сүнмәйә йөз тотмактадыр, сезең бу кадәр чабалануыгызга сәбәп тә ошбу куркынычларны бераз сизмәклегегездер» (37а кгз).

4) Н. Григорьевның «Богдан Колостовның татарлар белән моназарасы» исемле рисаләсенең (2 нче басма. Оренбург, Духовный хөкем мәҗлесе матбагасы, 1901. 13 бит) татарчага тәрҗемәсе (40-67а кгз) һәм аңа рәддия (67а-70а кгз). Бу күчермәдә Г. Бубыйның рәддиясе төгәлләнеп җитмәгән.

Әсәрдә һәм аңа рәддиядә Инҗил һәм Коръән мәсьәләләре тикшерелә.

5) «Тәкъва ганел-кайед» (75в-68а кгз). Шунда ук русча исеме дә бирелгән: «Наилучшие очерки обстоятельства мусульман в России». Эчтәлеге: Россиядәге мөселман татарларының рухани хәле, аларга хөкүмәтнең мөнәсәбәте. Мөселманлыкны бетерү максатында чыгарылган хөкемнәр, мөселман халыкны рәхимсез эзәрлекләү-кысу, православие миссионерлыгы һәм аның идеологы Н.И. Ильминский. Әсәр 1900 елда язылган.

6) Ислам догматларын тикшерүгә багышланган әсәр (89а-98б кгз).

7) Тәурат һәм Инҗилдәге төрле мәсьәләләрнең кайсы баб, кайсы аятьтә икәнен күрсәтә торган таблица (99а-104а кгз).

8) «Образованный»- тәрбия мәсьәләләренә багышланган рисалә (104б-114б кгз).

Әсәр уку-укыту, тәрбиядә яңа ысул белән иске ысул арасындагы бәхәсләр кузгалган дәвергә карый. Әсәрдә әдип Европа мәгарифе, тәрбия итү методлары, татар яшь буынын ничек тәрбия итү хакында фикерләр әйтә:

«Европаның бу кадәр күз камаштыра торган һөнәрләрне кайсы гакыл инкяр идәр? Моңа инкяр идән адәм иң ахмак вә исламиятнең хакыйкатеннән иң гафил бер адәмдер» (105а кгз). Шуның белән бергә автор Европа культурасын аңсыз күчерүгә, бозык да йоктыруга каршы чыга. Татар мәдрәсәләрендә укыту-тәрбия эшенең тиешле дәрәҗәдә куелмавы хакында да фикерләр әйтелгән.

9) «Рәдде насари» − христиан динен кире кагуга багышланган рисалә (115а-126а кгз). Диннең нигезендә яткан мәсьәләләр аерым-аерым, җентекләп тикшерелгән.

Җыентыкның күпчелек кисәкләре Закирҗан Алхани тарафыннан, ә соңгы ике кисәге Сабирҗан Алхани тарафыннан күчерелгән.

Җыентык Хәсән Гали кулында булып, аннан 1935 елның июлендә Фәнни китапханәгә кергән.

Альберт Фәтхи. Татар әдипләре һәм галимнәренең кульязмалары. Икенче бүлек. - Казан, 1962. - Б. 11-20.

## Габдулла Бубыйның басылып чыккан хезмәтләре

1. Мөкяләмәи гарәбия. - Казан: Чирков хатыны вәрәсәләренең табыгханәсе, 1899.- 99 б.

2. Фәраиз. - Казан: Чирков хатыны вәрәсәләренең табыгханәсе, 1899.- 47 б.

3. Логия, яхуд Мантыйк фәне.- Казан: матбагаи Кәримия, 1901.- 64 б.

4. Тәгаддөде зәүҗате хифзы сыйххәтә татбыйкь. - Оренбург: Гыйльман Кәримев матбагасы, 1901.- 20 б.

5. Мохтәсар нәхүе гарәби.- Казан: матбагаи Кәримия, 1901.- 31 б.

6. Тәзәүвеждә сәгадәт.- Оренбург: Гыйльман Кәримев матбагасы, 1902.- 35 б.

7. Тәрәкъкые фөнүн вә мәгариф динсезлеке мөҗибме? - Казан: И.Н. Харитонов матбагасы, 1902.- 40 б.




Тәрәкъкые фөнүн вә мәгариф динсезлеке мөҗибме? - Казан: И.Н. Харитонов матбагасы, 1902.




Хакыйкать, яхуд Тугърылык. 3 җөзъә. - Казан, 1904.

8. Вөжди Мөхәммәд-Фәрид. Диянәте Исламияне кавагыйде мәдәниягә татбыйкъ, яхуд Борһане сатыйгъ: гарәпчәдән / Мөтәрҗиме Габдулла Бубый. - Казан: Харитонов матбагасы, 1904.- 164 б.

9. Хакыйкать, яхуд Тугърылык. 8 кисәк. - Казан. (ягъни 8 кечкенә китапчык булып 1904-1910 елларда басылган).

10. Татарча хотбә уку дөрестме? - Казан: Үрнәк, 1908.- 35 б.

11. Замане иҗтиһад монкарыйзмы, дәгелме? - Казан: Милләт, 1909.- 69 б.

12. Гыйльме хаљь.- Казан: Миллэт, 1909.- 44 б.

13. Сарфы гарәби. - Казан: Еремеев матбагасы, 1910.

14. Габдеһү Мөхәммәд. Тәүхид / Мөтәрҗиме Габдулла Бубый. - Казан: "Үрнәк" матбагасы, 1911. - 124 б.




Тәгаддөде зәүҗате хифзы сыйххәтә татбыйкъ. - Оренбург: Гыйльман Кәримев матбагасы, 1901.

## Гобәйдулла Бубыйның басылып чыккан хезмәтләре

1. Мөхтәсар җәгърафияи гомуми.- Казан: ун-т матбагасы, 1898.- 95 б. (1905, 1908, 1912 нче елларда кабат басылган).

2. Мөхтәсар гыйльме халь.- Казан, 1898.- 54 б. (1908, 1913 нче елларда кабат басылган).

3. Мөфассаль гыйльме халь.- Казан, 1898.- 188 б. (1907, 1909, 1914, 1917 елларда кабат басылган).

4. Кавагыйде төркия.- Казан: Чирков хатыны варислары матбагасы, 1898.- 42 б. (1907, 1911 елларда кабат басылган).

5. Кыйраәте төрки. Беренче җөзъэ. Казан: Чирков хатының вәрәсәләренең табыгъханәсе, 1899.- 80 б. (1907, 1908, 1912, 1917 нче елларда кабат басылган).

6. Кыйраәте фәнния. Мәкятибнең соң ике сәнәсенә махсус. Беренче һәм икенче җөзъэләр.- Казан. 1909, 1911, 1912, 1918 нче елларда чыккан.

7. Кечек җәгърафия: Ибтидаи мәктәпләрә махсус.- Казан.- 1910, 1913, 1915 елларда чыккан.






Кыйраәте фәнния. Мәкятибнең соң ике сәнәсенә махсус. Беренче җөзъэ. - Казан, 1909.

## Бубый мәдрәсәсе һәм бертуган Бубый-Нигъмәтуллиннар хакында библиография


1. Латыйф Г. Бубыйлар эше хакында. // Йолдыз. - 1912. - 27, 31, май, 2 июнь (№№ 837, 839, 840).

2. Бикчурин И. Бубыйлар эше тирәсендә // Бәянелхак. 1912. - 1-3 июнь (№№1056, 1057).

3. Думави. Бубыйлар эше хакында. // Вакыт. 1912. - 3 июнь. (№ 981).

4. Мансуров Гасыйм. Габдулла Бубый // Татарстан хәбәрләре. -1922. - 15 февраль. (№ 38).

5. Вәлиди Җәмал. Габдулла Бубый // Татарстан хәбәрләре. - 1922. 20 февраль (№ 42).

6. Валидов Дж. Очерк истории образованности и литературы волжских татар (до революции 1917 г.). - М. - Петроград: "Госиздат", 1923. - С. 66 -70, 77- 81.

7. Мансуров Г. Татар провокаторлары. - Мәскәү. 1927. - Б. 68-69.

8. Нуруллин Ә., Аппакова И. Иж-Бубый мәктәбенә 100 ел тула. // -Җинү юлы. - 1965 - 15 август (№ 50).

9. Аппакова Ә. Әгерҗе якларында үткән көннәрем // Җинү юлы. -1966 - 5 октябрь (№117).

10. Рөстәмева А.Б. Иж-Бубый кызлар мәктәбе һәм татарларда укытучылар әзерләү // Из истории педагогики в Татарии. - Казан, 1967. - 148-154.

11. Мәһдиев М. Бубый мәдрәсәсе // Казан утлары. - 1969. № 12. — Б. 167-179.

12. Махмутова А.Х. Становление светского образования у татар. -Казань, 1982. - С. 56-66.

13. Мәһдиев М. Тарихның бер тармагы // Әдәбият һәм чынбарлык. - Казан: Татар. китап нәшр., 1987. - Б. 144 -172.

14. Хәлиуллина Р., Мәрданов Р. Мәдрәсә: мәгърифәт учагымы, наданлык оясымы? // Татарстан яшьләре. - 1989. - 1 август.

15. Бубыйлар эше хакында // Әгерҗе хәбәрләре. - 1989. - 8 август (№94).

16. Шәймәрданова Г. Туган телем—татар теле. // Җинү юлы. - 1990. - 2 июнь (№66).

17. Үтәбай-Кәрими Р., Рәхимкулова М. Мәгариф тарихыбыз каһарманнары // Кызыл таң. - 1990.- 5, 6 июнь (№№129 - 130).

18. Шәймәрданова Г. Эзләнүләрдән соң очрашу // Социалистик Татарстан. - 1990. - 14 октябрь.

19. Хуҗин Фәйзи. Иж буендагы Бубый // Социалистик Татарстан. - 1990. - 14 октябрь.

20. Бубый мәдрәсәсе тарихы: җыентык / Төзүчеләре: Раиф Мәрданов, Сөләйман Рәхимов. - Казан, 1991. - 203 б.

21. Хәлиуллина Р. Мөхлисә Бубый. // Әгерҗе хәбәрләре - 1991. 4 апрель (№ 39).

22. Иж-Бубый авылында мәдрәсә оештырылуга - 210 ел // Әгерҗе хәбәрләре. - 1991. - 20 июнь.

23. Мөслимов А. Иж-Бубый үзе тарих // Социалистик Татарстан. -1991. - 5 июль.

24. Әхмәтҗанов М. «Бубый шәкертләре дөньяга туп-туры карыйлар // Татарстан хәбәрләре. - 1992. - 6 май.

25. Третий век медресе // Советская Татария. - 1992. - 18 июля.

26. Мәһдиев М. Бубый мәдрәсәсе // Мәдрәсәләрдә китап киштәсе: Мәшһүр мәгърифәт үзәкләре тарихыннан. - Казан: Татар. китап нәшр., 1992. - Б. 38-70.

27. Максудова З. Бубыйда беренче спектакль // Мәдрәсәләрдә китап киштәсе: Мәшһүр мәгърифәт үзәкләре тарихыннан. - Казан: Татар. китап нәшр., 1992. - Б. 71 - 73.

28. Госманов М. Ябылмаган китап, яки Чәчелгән орлыклар.- Казан: Татар. китап нәшр., 1996.- 206 б.

29. Шафиков Я. Как живешь Буби? // Республика Татарстан. - 1997. - 11 июня.

# Педагоги Бобинские и Иж-Бобинское медресе

В период существования советского государства народы, ее населяющие, фактически были лишены права изучать и знать свою национальную историю и культуру. У советского народа целенаправленно формировали отрицательный стереотип к дореволюционному культурному наследию. Не избежала классового ранжирования и система национального просвещения, и ее научно-педагогическое наследие, которое было объявлено буржуазным, а значит и антинародным.

История национального просвещения татарского народа остается пока малоизученной областью в контексте единого взгляда на его прошлое. За исключением нескольких статей в республиканской периодике за последние десять лет в свет вышли лишь один сборник научно-популярных статей* тиражом 1000 экземпляров, посвященный известным татарским учебным заведениям — медресе начала XX века, и одно методическое пособие для учителей** малым тиражом в 200 экземпляров. В 1998 году издательство "Магариф" опубликовало учебную программу 1913/1914 года казанского медресе "Мухаммадия"*** в виде отдельной брошюры, сопроводив ее обстоятельной статьей историка Р.Амирханова. К сожалению, составители переиздали программу медресе без научно-справочного аппарата, что методически усложняет работу специалистам с данным изданием.

В 1991 году в связи с празднованием в Агрызском районе юбилея медресе "Иж-Боби" незначительным тиражом в 50 экземпляров был издан сборник на татарском и русском языках "Бубый мәдрәсәсе тарихы" (История медресе Боби), куда впер-

---

* Мәдрәсәләрдә китап киштәсе. Сб.ст. на тат.яз. Казань, 1992.-238 с.

** Р.А.Утебай-Карими. По следам просвещения (на баш.яз.) Уфа, 1991.-87 с.

*** Мөхәммәдия мәдрәсәсе ( на тат.яз.) Казань, 1998.-98 с.

вые была включена ранее неиздававшаяся работа Абдуллы Бобинского. В новом издании сборника значительно расширилась ее документальная и библиографическая часть, куда вошли не только документы разных архивов, но и выдержки из исследований прошлых лет. Историко-документальное издание посвящено в первую очередь истории татарского дореволюционного учебного заведения, медресе Боби, располагавшегося в дер. Иж-Боби Сарапульского уезда, Агрызской волости Вятской губернии (ныне Агрызский район Республики Татарстан). В книге нашли отражение материалы, освещающие жизнь и деятельность ее ведущих педагогов и руководителей в начале XX века — братьев Губайдуллы (1866-1938), Абдуллы (1871-1922) и их сестры Мухлисы (1869-1937) Нигматуллиных - Бобинских.

Деятельность семьи Бобинских была значительным вкладом не только в формирование среднего и высшего звена в системе обучения и образования татарского народа, но и стала неотъемлемой частью общероссийского педагогического наследия.

Они родились в деревне Иж-Боби в семье муллы Абдулгалляма, который по долгу службы учил мальчиков и старших школьников в медресе. Жена же Бадрельбанат обучала грамоте деревенских девочек. Дети росли в трудолюбивой и дружной семье, в обстановке любви и добра. Они рано научились читать и много времени проводили за книгами. Одна из комнат в доме целиком была отведена под домашнюю библиотеку. Высокие нравственные идеалы, гуманизм, стремление к духовному совершенствованию стали основой мировоззрения будущих педагогов, ученых и общественных деятелей, получивших известность в России под псевдонимом Бобинских.

Старший сын Губайдулла после деревенского медресе продолжил обучение в Стамбуле, где с 1890 по 1895 годы весьма успешно учился в султанском лицее "Игдадия", учрежденным французами и работавшем по французской системе обучения. Его одноклассниками были также Фатих Каримов, впоследствии видный татарский публицист, редактор газеты "Вакыт" и Харис Файзи-Чистопольский, педагог и методист.

За незаурядные способности в изучении точных дисциплин ему было предложено продолжить образование в Парижском университете, однако, зная что дома его ждет престарелый отец, чтобы передать медресе в руки сына, Губайдулла вынужден был отказаться от заманчивого предложения и вернулся домой.

В лицее Губайдулла проявил особый интерес к физике. Верность к этому предмету он сохранил в течение всей своей жизни, создавая учебники и методические пособия для школь-

ников. Перечень изданных им работ публикуется в данном издании.

Пятилетнее обучение за границей старшего сына обошлось семье имама в немалую сумму, поэтому учеба младшего сына ограничилась лишь отцовским медресе. Однако природный талант Абдуллы, умело направленный и развитый педагогом-отцом, позволили ему на учебной базе медресе Иж-Боби получить глубокие знания по восточной философии, логике и юриспруденции.

Вернувшийся из Стамбула осенью 1895 года Губайдулла был полон идей и знаний по введению новых учебных дисциплин. Абдулла же, уже успевший к этому времени основательно изучить исламскую философию, проработать реформаторские сочинения турецкого ученого и писателя Ахмеда Мидхата, египетского философа Мухаммеда Абдо и других, стал не только единомышленником старшего брата, но и главным инициатором и организатором реорганизации медресе.

Под медресе было отведено два больших деревянных одноэтажных здания. В одном размещалось само училище, другое было отдано под общежитие для иногородних шакирдов (учащихся), которые составляли больше трети, а в последние годы до половины учащихся.

Все дореволюционные татарские учебные заведения существовали за счет благотворительных пожертвований как прихожан, так и отдельных лиц. Самое первое здание для школы построил в 50-е годы XIX века Ахмеджан Ахмади, однако вскоре испугавшись возможных гонений со стороны официальных властей, разобрал это здание. Самую большую бескорыстную материальную помощь и моральную поддержку мулле Абдулгалляму с середины 50-х годов прошлого столетия оказывал меценат Мухаммедсадык Гайса, который в 1857 году заново построил здание школы, а в следующем году пристроил помещение под школьную столовую.

После разорения М. Гайсы эстафету благотворительности продолжил хаджи Мухаммеджан Ахмеджанов и его доверенное лицо купец Абдрахман Ибрагимов. В 1881 году взамен старых зданий были построены два просторных помещения. С этого дня вплоть до официального закрытия медресе все строительные работы в нем финансировались за счет средств купца М.Ахмеджанова, чье имя неотделимо от истории этого учебного заведения. Свою достойную лепту внес и Ахмеджан Абдулкаримов, подаривший большой участок земли под медресе, куда в 1883 году были перенесены школьные здания.

В 1895 году Абдулгаллям хазрят, дав благословение на реформы, передал руководство училищем в руки сыновей. В том же году младший сын муллы Абдулла Бобинский получил указ имам-хатыба и вместе с братом приступил к постепенной модернизации медресе, начав ее с начальной школы. Для изучения методики нового способа преподавания Абдулла направил Минлешаеха Галимова в Бахчисарай, где действовали трехмесячные курсы по подготовке молодых учителей, сторонников звукового метода обучения. Вскоре в деревне было построено и отдельное здание для начальной 4-х летней школы.

Процесс реформирования продолжался поэтапно в течении десяти лет. Менялись старые учебные пособия на новые, отвечающие современным требованиям педагогической науки. Первыми педагогами- новаторами были сами братья Бобинские и вернувшийся с курсов новометодистов М.Галимов. Губайдулла вел курс естественных дисциплин, а Абдулла с М.Галимовым - гуманитарный цикл. Постепенно в медресе были привлечены способные молодые кадры, в основном из числа бывших воспитанников этого же учебного заведения.

В 1905 году Абдулла совершил хадж и в течение года путешествовал по арабским странам, внимательно изучая систему обучения и образования этих стран. Возвратившись в 1906 году на родину, он вместе с братом всю свою энергию направляет на формирование финансового фонда медресе. В дни ежегодных ярмарок в Нижнем Новгороде и Мензелинске Абдулла Боби специально отправлялся в эти города на встречу с купцами и фабрикантами, убеждал их делать пожертвования в фонд медресе.

С 1907 года в деревне заработала и реформированная шестилетняя школа для девочек. С этого года началась активная педагогическая деятельность Мухлисы Бобинской. Это учебное заведение фактически стало первой женской гимназией для мусульманок. Братья оказывали полную поддержку сестре во всех ее начинаниях. В школе девочки изучали татарский язык и его грамматику, арабский, персидский, русский, турецкий языки, арифметику, геометрию, алгебру, всеобщую историю, географию, санитарию, химию, зоологию, ботанику, рукоделие, уход за детьми и их воспитание и другие предметы. В это учебное заведение родители привозили своих дочерей со всей России.

Благодаря упорству, организаторскому таланту и бескорыстному служению делу просвещения семьи Бобинских и их соратников медресе Боби превратилось в центр подготовки педагогических кадров, деятелей науки и культуры не только татар-

ского, но и других тюркских народов Российской империи. В эту далекую от центра деревню стала стекаться молодежь со всей страны. Если в 1904 году здесь обучалось 150 учащихся, то в 1908-1911 годах уже ежегодно занималось около 500 шакирдов. Помимо татар, знания получали казахи, киргизы, башкиры и другие народности.

Особое место за медресе Боби признавали и чиновники Министерства народного просвещения России. В секретном докладе на имя попечителя Казанского учебного округа инспектор народных училищ Елабужского уезда Яков Коблов 6 июня 1908 года подчеркнул: "Иж-Бобинское медресе занимает выдающееся место среди других магометанских школ, оно служит центром просвещения...". Однако при этом инспектор делает неожиданное предложение, что "...полезно было бы это медресе иметь всегда под особым надзором как неблагонадежное в смысле распространения панисламистских идей. По этой же причине полезно было бы затруднить доступ на должность мулл, кончающих курс в Иж-Бобинском медресе".*

Известный в России чиновник Министерства народного просвещения Александр Горячкин в своем письме на имя попечителя Казанского учебного округа 4 сентября 1909 года также отмечал, что "Медресе Боби" является одним из видных медресе с новометодным направлением, выпускающим мугаллимов для новометодных татарских мектебов. "**

Медресе Боби попало в поле зрения органов жандармерии в начале 1908 года. В обстановке секретности стали собираться материалы в виде донесений, анализов, оценок. По всей видимости перед полицией была поставлена задача - найти обоснование пропаганды панисламизма в Иж-Бобинском медресе. Все донесения повторяют друг друга в своей оценочной части, в каждом из них есть предложение, что педагоги Бобинские занимаются пропагандой панисламизма, т.е. полиция с видимым упорством выдавала желаемое за действительное. В ночь с 29 на 30 января 1911 года Вятское губернское жандармское управление пошло на крайний шаг, конный отряд жандармов нагрянул с обыском в медресе, преподаватели были арестованы и заключены в Сарапульскую тюрьму. Вся литература была опечатана и увезена на досмотр к специалистам. Начался беспрецендентный в истории дореволюционной России процесс над преподавателями одного из лучших мусульманских учебных центров России. В работу включились опытные следователи,

* НА РТ. Ф.92. Оп.2. Д.8777. Л.58об.-61.
** НА РТ. Ф.92.Оп.2. Д.10735. Л.68.

предварительное следствие продолжалось больше года. За это время в разных городах проходили обыски и изъятия рукописей, писем, книг у представителей татарской интеллигенции. Свыше ста человек в разных уголках России подверглись унизительной процедуре обыска. К работе по обработке изъятых рукописей были привлечены ученые-профессора Н.Катанов, П.Жузе, Н.Ашмарин и другие. Материалы предварительного следствия достигли объема одиннадцати пухлых томов. Просматривая том за томом, невольно приходишь к мысли, что следователи работали по заказанной схеме, к делу приобщались лишь материалы и данные показаний тех свидетелей, кто подтверждал наличие антигосударственной пропаганды в медресе дер. Иж-Боби, отрицающие этот тезис свидетельства либо к делу не приобщались, либо просто не брались во внимание. Материалы следствия были переданы в Казанскую судебную палату, которая 28 мая 1912 года в Сарапуле провела выездное закрытое судебное заседание по делу педагогов медресе Боби. Суд признал братьев виновными лишь по 132 статье Уголовного уложения о неуважении к властям и распространении литературы бунтовщического характера. Речь шла о 9-й части философско-полемического сочинения Абдуллы Бобинского "Хакыйкать" (Истина), в которой и были усмотрены антиправительственные выпады автора. Абдулла Бобинский был приговорен к шести месяцам, а Губайдулла к двум месяцам тюремного заключения. Пункты обвинения в пропаганде панисламизма судом были отвергнуты за недостаточностью улик.

К сожалению, приходиться констатировать, что органы жандармерии решили поставленную перед ними задачу — медресе было разгромлено и закрыто навсегда. Попытки вновь открыть медресе закончились безрезультатно. Закрыто было и женское медресе. Мухлиса Бобинская была вынуждена осенью 1912 года уехать в Троицк, где стала фактически руководителем школы для девочек, а с января 1913 года преподавала вероучение в Троицкой женской гимназии.

После освобождения из тюрьмы в 1913 году Абдулла Буби уехал в Китай в город Гульджа, где возглавил татарскую школу и где проработал вплоть до мая 1917 года. В последние годы Абдулла Бобинский часто болел, он умер 7 февраля 1922 года в родной деревне Иж-Боби.

Губайдулла Бобинский, выйдя из тюрьмы, уехал в Уфу, последующие годы он работал в Казани, затем в Средней Азии до 1930 года в Коканде руководил школой, затем переехал в Ленинград, где в 1938 году скончался.

Мухлиса Бобинская в мае 1917 года на Всероссийском мусульманском съезде была избрана духовным судьей (казыя) в Центральное духовное управление мусульман России, которое располагалось в Уфе. В ЦДУМе она ведала, в первую очередь, вопросами семьи, женского образования, дополнительно исполняла обязанности секретаря. Это были тяжелые годы для священнослужителей. Коллектив работников ЦДУМ во главе с муфтием Ризой Фахретдиновым, несмотря на развернутую в стране антирелигиозную пропаганду, делали все возможное, чтобы обеспечить функционирование мусульманских приходов России. После смерти муфтия в 1936 году начались репрессии и против работников ЦДУМ. Мухлиса Бобинская была арестована в ноябре 1937 года, ложно обвинена "в организации повстанческого движения в Башкирии..." и через месяц, 23 декабря, расстреляна* . Так трагически оборвалась жизнь единственной в истории исламской цивилизации женщины, которая носила авторитетное звание казыя.

Переосмысление прошлого процесс долгий, во многом для нашего поколения мучительный, но одновременно и поучительный. Сегодня настало время более подробного изучения того научно-педагогического наследия, которое оставила необычайно талантливая семья Нигматуллиных-Бобинских. Особо бережного отношения заслуживают философско-педагогические работы Габдуллы Бобинского, статьи и выступления Мухлисы Бобинской.

Вне сомнения их работы следует собрать, научно обработать и переиздать. Думается, что это наш долг перед памятью людей, чья жизнь была исключительно посвящена служению народу. В истории всех народов такие личности были объектом поклонения и подражания. Понять, изучить и правильно оценить богатое наследие прошлого, благие деяния, поступки наших именитых соплеменников важно, в первую очередь, нам, ныне живущим, чтобы уверенно смотреть в будущее нашего народа.

Сулейман Рахимов

---

* Архив Министерства безопасности Республики Башкортостан. Д. В-7012. Л. 13,14,180.

## Эчтәлек

"Калын караңгылык эчендә беренче шәм... " .............................. 3

*Р. Үтәбай-Кәрими, М. Рәхимкулова.* Мәгариф тарихыбыз каһарманнары .............................. 6

*Габдулла Бубый.* Бубый мәдрәсәсенең кыска тарихы .............................. 14

Искәрмәләр .............................. 90

Мөхлисә Бубый мәкаләләре .............................. 106

Садрый Максуди нотыгы .............................. 113

Иж-Бубый авылы, мәдрәсәсе һәм бертуган Бубыйлар турында мәкаләләр, чыганаклар .............................. 129

"Бубыйлар эше" буенча хөкем материалларыннан .............................. 180

Мөхлисә Бубыйның хөкем эшеннән.1937 ел. .............................. 208

Библиография .............................. 213

– *А. Фәтхи.* Габдулла Бубый кулъязмаларының тасвирламасы .............................. 213

– Габдулла Бубыйның басылып чыккан хезмәтләре .............................. 227

– Гобәйдулла Бубыйның басылып чыккан хезмәтләре .............................. 229

– Иж-Бубый мәдрәсәсе һәм бертуган Бубый Нигъмәтуллиннар хакында библиография .............................. 230

Педагоги Бобинские и Иж-Бобинское медресе .............................. 232

Бу китапны дөньяга чыгаруда ярдәм иткән өчен
авторлар коллективы "Рухият" фондын оештыручылар -
"Татнефть" акционерлык җәмгыятенә, "Татех",
"Татойлгаз" уртак предприятиеләренә,
"Чулпан" иминият компаниясенә, "Девон-кредит",
"Зенит" коммерция банкларына рәхмәт белдерә.

Историко-документальный сборник

# Педагоги Бобинские и Иж-Бобинское медресе

*(на татарском языке)*

Ответственный редактор: Ильсияр Хайруллина
Художественный редактор: Шамиль Насыров
Компьютерная верстка: Василий Порсев

Налоговая льгота - общероссийский классификатор продукции ОК-005-93;
т.2; 95300 - книги, брошюры.

Издательство «Рухият»
Лицензия № 190 от 30.05.1997 Министерства информации и печати РТ.
г.Альметьевск. Тел./факс (85512) 98555, 25540
г.Казань. Тел./факс (8432) 380202

Формат 84x108 1/32. Печатных листов 7.5. Цветная вклейка 0.5 п/л.
Тираж 2000 экз. Зак. 3-371

Отпечатано в типографии Татарского газетно-журнального издательства.
420066, г.Казань, ул.Декабристов, 2